20. Клёнов (Котов), Ю. Радуга над КамАЗом?: Стихи / Ю. Клёнов. – Москва: Современник. 1982.
21. Кучумов, Ю. Странноприимный дом: Стихи / Ю. Кучумов. – Нижний Новгород, 2000.
22. Лимонова, И. В час предутренний...: Лирика / И. Лимонова. – Казань: Татар. книж. изд., 1984.
23. Литературный энциклопедический словарь / Под общей редакцией В. Кожевникова, П. Николаева. – Москва: Советская энциклопедия, 1987.
24. Лоншаков, О. По обе стороны окна: Стихи / О. Лоншаков. – Наб. Челны, 2009.
25. Морозенко, Л. О любви давай поговорим: Стихотворения / Л. Морозенко. – Наб. Челны, 2002.
26. Неуймина, Н. Природа и мы / Н. Неуймина. – Ленинград: Лениздат, 1982.
27. Первова, Н. Прапамять: Книга стихов / Н. Первова. – Санкт-Петербург, 2016.
28. Платонова, З. Люблю до боли: Стихотворения / З. Платонова. – Москва: ООО «Мейлер», 2009.
29. Попова, С. Татьянин день: Стихи / С. Попова. – Казань: «Идел-Пресс», 2016.
30. Поспелов, Е. Крылатый ковчег: Стихи / Е. Поспелов. – Елабуга. 2010.
31. Природа и литература (сборник статей). – Москва: Знание, 1979.
32. Прихожан, П. Дума о раде Китеже: Стихи, поэмы / П. Прихожан. – Казань: ПИК «Идел-Пресс», 2011.
33. Прохорова, М. Избранное: Стихотворения / М. Прохорова. – Елабуга, 2014.
34. Салихов, Р., Валиев, Н. Әдәби Алабуга (Литературная Елабуга) / Р. Салихов, Н. Вәлиев. – Елабуга, 2005.
35. Сафин, М. Система пейзажных образов в татарской поэзии / М. Сафин // Научный Татарстан. – 1999. – №1. – С. 11-25.
36. Сафин, М. Ода Мамадышу. Мамадышка мәдхия. Стихотворения, поэмы (на русском и татарском языках) / М. Сафин. – Наб. Челны, 2007.
37. Сафин, М. Челны мои былинные: Стихотворения, поэмы, песни / М. Сафин. – Наб. Челны, 2007.
38. Солнцев, Р. Письмо на Родину: Книга новых стихотворений / Р. Солнцев. – Наб. Челны, 2002.
39. Тагилин, С. Между белым и чёрным: Стихотворния / С. Тагилин. – Наб. Челны, 2006.
40. Тарасов, А. Ночной звонок: Стихи / А. Тарасов. – Казань: «Идел-Пресс», 2005.
41. Уткин, Е. Венок Поэту: Стихотвореиия / Е. Уткин. – Наб. Челны, 2008.
42. Федосенко, М. Рубикон: Стихи / М. Федосенко. – Москва: «Прометей», 1991.
43. Шишкина, Н. Стихи для Тебя / Н. Шишкина. – Набережные Челны, 1993.
44. Шатрова, Л. Избранное: Стихотворения / Л. Шатрова. – Наб. Челны, 2001.
45. Шилободин, А. В тени скворечника: Стихотворения / А. Шилободин. – Санкт-Петербург, 2010.
46. Юлаев, П. За окном метель: Стихотворения / П. Юлаев. – Москва: «Молодая Гвардия», 1981.
47. Ясавеев, Р. Своей дорогой: Стихи / Р. Ясавеев. – Казань: «Слово», 2015.

***Мансур САФИН,***
*член Союза писателей России и Республики Татарстан,*
*лауреат премий имени Шайхи Маннура,*
*Егора Уткина и Эдуарда Касимова*

# СРАВНИТЕЛЬНАЯ ХАРАКТЕРИСТИКА СИСТЕМ ПЕЙЗАЖНЫХ ОБРАЗОВ В РУССКОЙ И ТАТАРСКОЙ ПОЭЗИИ НИЖНЕГО ПРИКАМЬЯ

«Хорошее воспроизведение природы отличает две особенности: благородная смелость – дабы высосать мозг из костей природы и достигнуть всей силы её размаха, но в то же время и робкая застенчивость – чтобы в наших миниатюрных изображениях смягчить разные черты, какие природа разрешает себе на гигантских фресках» – писал когда-то известный немецкий поэт Фридрих Шиллер. Это не совсем простое, но весьма точное определение принципов использования пейзажных образов в творчестве писателей.

Да, каждая национальная литература, поэзия, в частности, имеет свою систему устойчивых, традиционных пейзажных образов. Стоит отметить, что в мировой культуре существуют целые исследования об образе леса – в немецкой литературе, об образе ручья – во французской поэзии. В татарской поэзии есть успешная исследовательская работа профессора Талгата Галиуллина об эволюции пейзажных образов в творчестве поэта Хасана Туфана (книга Т.Галиуллина «К новым вершинам», Казань, 1972). К сожалению, русская и татарская литературы в этом отношении изучены недостаточно. Мы своими исследовательскими работами, представленными на этой конференции, внесём, пусть и небольшую, лепту в этом направлении литературоведения.

«Климат, образ правления, вера дают каждому народу особенную физиономию, которая более или менее отражается в зеркале поэзии», – писал А.Пушкин в определении народности, причём здесь «климат» стоит на первом месте: то есть, если подвижные черты народа – вера и правление изменяются, то климат, ландшафт, флора и фауна накладывают на «лицо народное» постоянный оттенок. Связь человека с природой имеет важное значение в творческлм процессе любого писателя, поэта.



Возьмём для рассмотрения по 7 русских и 7 татарских поэтов Нижнего Прикамья, в творчестве которых более, чем у других применяются различные пейзажные образы: из русских поэтов – набережночелнинцы Пётр Прихожан (книга «Дума о граде Китеже»), Светлана Попова (книга «Татьянин день»), Наталья Первова (книга «Прапамять»). Зинаида Платонова (книга «Люблю до боли»), Людмила Дорженковская (книга «Календарь души»), нижнекамец Михаил Федосенко (книга «Рубикон»), менделеевчанин Роберт Ясавеев (книга «Своей дорогой»);

Из татарских поэтов – Разиль Валеев (книги «Зәңгәр кабырчыклар», «Определение любви», «Зимние яблоки»), Ямаш Игеней (книги «Сәфәр чыгам», «Хәзинәләр иле», «Игелекле төбәк»), Газиз Кашапов (книга «Мәхәббәт сүрәләре»), Назип Мадьяров (книги «Рәшәле офыкларым», «Әкәмәт»), Кадыйр Сибгатуллин (книги «Таңнар, кичәләр.. », «Әйтте шагыйрь», «Полёт радуги», «Осенняя весна»), Айдар Халим (книги «Курай», «Йөрәк тавышы», «Тилергән сирень»), Рахмай Хисматуллин (книги «Яшенле тау» «Ак догалар», «Тәүбә»).

Применим метод межтекстуального анализа. Сделаем подборку пейзажных образов в обобщённых русских и татарсих текстах (мегатекстах) и проведём их частотный анализ.

Проанализировав частоту применения поэтами различных пейзажных образов, составив соответствующий каталог, мы условно соберём их в следующие основные группы:

а) в татарском мегатексте:1) деревья – 21, в т.ч. яблоня – 5, берёза – 4, рябина – 2; 2) цветы – 6; 3)птицы – 9, в т.ч. – 3 соловей; 4) образы, связанные с водой (ключи, озёра, родник, ручей, святой родник) – 8; 5) явления природы (снег – 4, дождь – 8, гроза -2, ветер, вьюга – 7, облака – 3); 6) образы космических тел (звёзды – 4, луна – 7, солнце – 7); времена года (зима – 2, осень – 2, весна – 2. лето – 2). Кроме этого, часто встречаются и другие группы образов: животные (конь-лошадь-жеребёнок – 4, собака – 1, змея – 1), рельефы местности (горы – 1, дороги – 2).

Причём, у некоторых талантливых поэтов, как, например, у Айдара Халима есть и такие ***нетрадиционные древесные образы,*** как чёрная берёза, лунная сковорода, сумасшедшая сирень, а у Рахмая Хисматуллина – цветок землетрясенья, колдовская заря, ключи предков, дедовский родник...

б) в русском мегатексте наблюдается следующая частота образов: 1) деревья – 7, в т.ч. карагач (Дорженковская) – 1, рябина – 2; 2) цветы – 15; 3)птицы – 9, т.ч. воробей – 2, кукушка – 2; 4) образы, связанные с водой (река, озёро, родник, колодец) – 4;

5) явления природы (снег – 8, в т.ч. первый снег – 3; дождь – 6; ветер – 6, в т.ч. метель -2; облака – 3); 6) образы космических тел (звёзды – 2 луна, полнолуние– 3, солнце – 3); времена года (осень – 3, зима – 2, весна – 3. лето – 6). Кроме этого, часто встречаются и другие группы образов: животные (конь – 1, лошадь – 1, жеребёнок – 1; змея – 1, и другие), мотивы рельефа местности (горы – 1, дороги – 4).

Следует отметить, что татарские поэты *мотивы деревьев* употребляют намного больше: тат – 21, рус – 7; Традиционно самым употребляемым в русской поэзии является берёза, а в татарской – дуб. Причём, берёза имеет множество родственных, однородовых мотивов на обоих языках: каенсар, каенлык – березняк, каен гөмбәсе – подберёзовик, каен суы – берёзовый сок, каен тузы – береста, каен җиләге – земляника.

Интересно, что для Л. Дорженковской татарское дерево *«карагач»* в одноименном стихотворении становится оптимистическим символом:

*У дороги карагач,*
*Как напоминание,*
*Что у бед и неудач*
*Будет окончание.*

А у Разиля Валеева *образ коня* до того национален, что видится батыром: майдана жизни (здесь и далее – переводы М. Сафина):

*Мчатся кони – ветра сабантуя!*
*Мы с мальчишками рядом стоим,*
*И ликует майдан, салютуя*
*Новым, храбрым батырам своим!*

*(«На майдане жизни»)*

Для ярко-национального поэта Айдара Халима конь – олицетворение благородства, верный друг:

*В этих гривах – птицы вольной кровь!*
*В кручах века – их копыт следы.*
*В этом ржанье – мужество, любовь*
*И спасенье друга в час беды…*

*(«Ода коню»)*



С этими строками восторженно перекликаются «русский» конь нижнекамского поэта Михаила Федосенко:

*Упругость взмыленного ветра.*
*Костра гуляющий огонь.*
*Несётся рыжим сгустком света*
*Из дали в даль – ах, солнце-конь!*

*И в сердце удаль полевая*
*Влетает вместе с новым днём:*
*Полцарства за коня давали.*
*Всю жизнь отдам, чтоб стать конём.*

*(«Конь»)*

Без сомнения можно утверждать, что всех людей-россиян очаровывает *первый снег* и окликается в сердце каждого, заставляет задуматься о жизни. Вот как резонансно происходит это у наших прикамских поэтов:

*Неспешно, очень грустно*
*Падает первый снег –*
*Взяв снежинку в руки*
*Задаю вопрос за всех:*
*Первым бывает трудно?*
*Легче идущим вслед…*

*(Ямаш Игеней «Первый снег»)*

*Завершает ноябрь*
*их короткий роман.*
*Первый снег – обновленья*
*невинный обман.*
*Очищение душ,*
*возвышение чувств*
*Только я в это чудо*
*поверить боюсь.*

*(Л. Дорженковская «Первый снег»)*

А вот ещё одна перекличка сердец, стоящих на холодных *ветрах* эпохи:

*Ветры сильные. Ветры печалей*
*Так нередко в лицо мне били, –*
*Нет, Судьба ты бы так не дичала,*
*Если б чуточку, всё же, любила…*

*(Газиз Кашапов «Дуют ветры»)*

*Не рыдай ты, ветер!*
*Не тревожь мне душу!*
*Плохо жить на свете*
*Никому не нужной.*

*(Зинаида Платонова «Ветер»)*

Из этих примеров нетрудно понять, как тесно переплетаются значения пейзажных образов (мотивов) *коня, первого снега и ветра* в поэтике русских и татарских писателей Прикамья. И это не единичные случаи.

И порой души русских и татарских поэтов даже сливаются в одинаковом видении природы, в одинаковых ощущениях пейзажных образов, как бы один продолжая на свой лад строки другого (может быть, это и оттого, что они многие годы жили рядом, и «варились в одном котле творчества»):

*По глади вод пошли морщины…*
*Легко взбугрились на ходу.*
*И белопенная вершина*
*Уже взлетает в высоту.*

*(Пётр Прихожан «Волна»)*

*Река серебрится излукой.*
*Да, ноша её нелегка:*
*Льётся, почти без звука,*
*Волнами льнёт к берегам.*

*(Кадыйр Сибгатуллин «Воды текут…»)*

В связи с ограниченностью во времени, я здесь умышленно не привожу традиционные характеристики пейзажных образов: среди *древесных мотивов,* например, дуб ассоциируется с жизненной мощью, силой прорастания и жизнестойкостью; тополь характеризуется благородством, одухотворенностью; клён похож на кряжистого мужика с царскими замашками, и даже на героя лёгкого романа своими осенними багряными листьями, напоминающими трепетное сердце… В берёзе сочетаются нежные и печальные свойства женской натуры с её девической чистотой, застенчивостью и открытостью; а в рябине таится огненная страсть, удалое веселье; липа же обычно навевает сладкие воспоминания о прошлом и вызывает элегические размышления о будущем. И так далее. Но, конечно же, эти аналогии условны. В жизни они менее формализованы и и в живом употреблении могут приобретать самые разные, далёкие от традиционных, значения как в русской, так и в татарской поэзии. Тем они и привлекательны.

***Алсирә МӨХӘММӘТҖАНОВА,***
*Чаллы шәһәренең*
*муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе*
*«15 нче гомуми белем бирү мәктәбе»*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## ЧАЛЛЫ ТӨБӘГЕ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ ИҖАТЫНДА ТУГАН АВЫЛ ТЕМАСЫ

Һәр кешенең йөрәгенә якын, җанына җиңеллек бирә торган яраткан урыны була. Минем өчен ул – туган авылым. Туган ягын, авылын яратмаган кешеләрне мин күз алдыма да китерә алмыйм. Һәркем үз ягын матур итеп, аны үз мәхәббәте белән баетып, шигъри бизәкләргә төреп, ямьләндереп күрә. Аның гүзәллегенә, кешеләренә соклана, алар белән хаклы рәвештә горурлана. Яшьлекләрендә авылын ташлап чит җирләргә киткән кешеләр, туган туфракларын сагынып, аның табигатенә сокланып, җырлар, шигырьләр язалар. Мин дә, читтә яшәүче авыл баласы буларак, үземнең туган авылыма багышлап шигырь яздым.

*Кайтып киләм туган авылыма,*
*Бер әйләнер өчен урамын.*
*Чишмә юлын эзләп хыялымда*
*Су буйларын ничә урадым.*
*Җәйләүләре тарта, тугайлары,*
*Сагындырган тургай җырларын.*

*Таш калада күккә ашкан йортлар*
*Алмаштырмый авылым кырларын.*
*Басуларда бодай-арышлары*
*Хәтерләтә диңгез дулкынын.*
*Иртәнге бер тамчы чыгың җитә*
*Басар өчен сагыну ялкынын.*
*Талларым да юлга текәлгәннәр,*
*Болын тулы гөлләр сипкелле,*
*Миләүшәләр зәңгәр күзен кысып*
*Мин кайтканны көтә шикелле.*
*Шау чәчәктә алмагачлар быел,*
*Ак күлмәктән шомырт, миләше.*
*Чалланса да чәчләр кирәк әле*
*Авыл картларының киңәше.*
*Кайтып киләм туган авылыма,*
*Гомер атларында юыртып.*
*Бала чагым чыккан каршыларга,*
*Башларымнан сыйпый юатып.*
*Озата барма мине үткәннәрем,*
*Минем бүген кайтып килешем.*
*Тау башыннан төшәм тыңлый-тыңлый,*
*Авылымның йөрәк тибешен.*

Туган як! Бу темага багышлап күп шагыйрьләребез шигъри әсәрләр иҗат иткәннәр.

Чаллы төбәгебез язучыларга, шагыйрьләргә бай як. Аларның иҗатында туган авыл гүзәллеген ачучы әсәрләр зур урын алып тора. Хәзер шуларның иҗатына күзәтү ясап, туган авылларына багышланган шигырьләренә анализ ясап үтик. Кадыйр Сибгатуллин, Газиз Кашапов, Факил Сафин, Зөләйха Минһаҗева, Айрат Суфиянов, Рәзинә Мөхияр, Сирень Якупова шигырьләрендә мәдхия җырланган иксез-чиксез тугайлары-кырлары, урманнары матур, талгын гына агучы инешләре, елгалары, авылдашлары, балачак хәтирәләре кабатланмас.

Газиз Кашапов үзенең «Үзилем» шигырендә туган авылын ташлап китүенең сәбәпләрен аңлатырга тырыша.

*Мәрхәмәтсез чорга туры килдек,*
*Ташлап киттек сине, Үзилем, –*

дип яза. Әйе, «мәрхәмәтсез чор» күпме кешене туган авылыннан аерып, таш пулатлар әйләндереп алган калаларга китәргә мәҗбүр итә. Чаллыда төзелгән КамАЗ заводы күпме авыл балаларын үзенә суырып алды, аларны йортларыннан аерды, бик күпләрне тамырсыз калдырды. Тормышның үз кануннары бар. Телибезме, теләмибезме без шул кануннарга буйсынырга мәҗбүрбез. Адәм балалары гомер-гомергә бәхет эзләп, рәхәт тормышка өметләнеп әллә кайларга чыгып киткән. Нигъмәт – ләззәт тулы, мул ризыклы ил-җирләрдә бәхетемне таптым дип ышанып яшәгән, әмма кайсыдыр бер мизгелдә җанындагы бар күзәнәкләрен тетрәндереп еракларда калган газиз туган авылының басу капкасы, капка янында озатып калган әнкәсе, әткәсенең җанга уелып калган берәр сүзе исенә төшә. Чылтырап аккан чишмә сулары, адашып калган сарык бәрәнен эзләп йөргән кыр-болыннары, җиләккә бай булган урманнары сагындыра башлый. Шул вакыт аның күзләренә мөлдерәп яшьләр тула. Сагына, җирси.. Сагыну-сагышлардан үрелгән була шул ул туган як бишеге. Халкыбызның «Шахта» көйләре дә шулай туган, әле һаман да безнең күңелләрне тетрәндерә, безне уйланырга мәҗбүр итә бит.

*Җир тирәли күпме әйләнсәк тә,*
*Син барыбер безгә үз идең,*

диеп дәвам итә үзенең фикерен Газиз Кашапов. Шагыйрь күңеле туган ягында үскән имәнгә дан җырлый, йөзьяшәр имән аның тормышының мәгнәсе, яшәешнең мәңгелеген искә төшерә:

*Байтак кына йөрдем чит җирләрдә,*
*Кайтышларын күрдем, гүзәлен…*
*Минем өчен барыбер күпне күргән,*
*Шул карт имән – җирнең үзәге.*

Сирень Якупова өчен туган авылының төтене дә, көле дә пешкән бәрәңгесе дә якын.

*Көлдә тәгәрәп пешкән бәрәңге,*
*Мич авызында алсуланган коймак,*
*Чишмә суыннан кайнаган чәй*
*Тәме исемдә…*
*Йөдәтә керәп төшемә*
*Моржабыздан чыккан төтен юлы…*

Шагыйрә шәһәрдәге йолдызларны бары тик авылга кайтып килгәч кенә күрә башлый.

*Авылга кайтып килдем,*
*Җанны уятып килдем,*

дип тә өсти ул. Бу инде авыл баласының шәһәрдә торып, гомере буе авыл дөньясы белән яшәвен искәртүе...

Туган ягыбызның кырларына, җиренә гашыйк шагыйрә Рәзинә Мөхияр. Аның өчен туган ягының басу-кырлары иҗатында рухи азык булып тора. Аңа туган якта үскән чүп үләннәре дә якын, кадерле. Аның өчен алар туган җирдән аерылгысыз, бербөтен булып яши. Бирердә кеше туган авылының бер өлеше итеп карала, аның холык-фигыле туган җиренә булган мөнәсәбәтеннән чыгып ачыла.

*Йөрәгемне чеметтереп ала*
*Әллә әрем, әллә кычыткан.*
*Кышлар үтте! Беләм:авылымда*
*Кычыткан да исән кыш чыккан.*
*Бәбкә үләннәре аягымны*
*Йомшак кына сыйпый шикелле.*
*Балачакта җыйган алабута*
*Ераклардан шундый сөйкемле...*

*(«Кайтсаң иде»)*

Зөләйха Минһаҗева иҗатында да авыл темасы читләтеп үтелми. «Авылым» шигырен укыгач, үзеңне кичә генә ташлап киткән авыл өендә итеп хис итә башлыйсың. «Син мине тудырдың, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләдең, динле-телле иттең, канатлар үстердең, очырдың», дигән фикерләр белән очрашабыз без аның шигырендә.

*Сине һәрчак үзем белән йөртәм:*
*Язгы ташуларым – холкымда,*
*Җәйләреңнең җылысы – күңелдә,*
*Шәмаилең – түрдә, йортымда.*
*Моңсу чагым – айлы кичләреңдәй,*
*Назлы чагым – сандугачлы таң...*
*Җитез-уңганлыгың – хезмәтемдә,*
*Тыйнак, гадилегең – кыйблам.*

Айрат Суфиянов – лирик шагыйрь. Аның лирик герое инде туган авылы алдында «гаепле» булуын аңлаган, туган җире белән кавышу турында да уйлана башлаган олыгаеп килгән герой. Авылы балаларыннан башка моңланып яши, күзләре яшьле авылының, шуңа күрә үткән буыннар, борынгы бабаларыбыз алдында да җаваплы аның лирик герое..

*И-и-и туган ягым, безләрсез сине*
*Кем генә саклар, кем соң кадерләр?*
*Ошбу сөялгә җавап эзләпме,*
*Кузгалып куйган кебек каберләр.*
*Авылның яшьле күзенә карап,*
*Күкрәктә йөрәк сулкылдый кадап,*
*Хәлсезләнә дә салынып төшә*
*Кайчандыр күккә талпынган канат.*
*Китеп өлгермим туган ягымнан*
*Ашкынып кабат кайтасым килә.*
*Нигә яшерим, инде тынгач та*
*Туфрагын кочып ятасым килә.*

Шагыйрь туган җире кешеләренең йөрәк тибешен тоеп, шулардан илһам алып яши. Аның һәр шигырендә туган җиребезнең моңы, җылысы, шул җирне бизәүче хезмәт кешесенең сулышы тоела.

Туган авыл темасы һәр шагыйрьнең йөрәк түрендә сакланган тема ул. «Шагыйрьләр бит авылларда туа, шәһәрләргә китеп үләләр», – дигән иде кайчандыр бөек шагыйребез Әнгам Атнабаев. Шагыйрьләр барысы да тумышы белән авылдан. Туган якта ерак яшәү, сагыну хисе аларны шагыйрь итә дә инде. Туган авылларның йөрәге шагыйрьләр күкрәгендә тибә. Якташ шагыйребез Факил Сафинның «Әмәкәй күңелемдә» шигырендә дә җирсүлек хисләре ярылып ята:

*Кошларның да үз оясы*
*Кайталардыр ашкынып.*
*Сагындырдың, туган авылым,*
*Очып кайтам кош булып.*

Кадыйр Сибгатуллинның «Авылым» шигырендә шагыйрь туган нигезләрен ташлап киткән, авылны файдасы өчен кенә яратучы кешеләргә үпкәсен белдерә.

*Катык белән каймакларын гына*
*Яратабыз мәллә без аның?*

Үз фикерен дәвам итеп, шагыйрь «...барыбыз да аның күкрәгеннән аерылмый торган бала без», – диеп, тамырларын онытканнарга кайдан чыкканлыкларын исләренә төшереп үтә. Туган авыл төшенчәсен ул Ана исеме белән янәшә куярга өнди:

*Һавасы бар, суы, чишмәләре,*
*Тагын нәрсә бар соң, дисезме?*
*Ана исеме белән бер үк рәттән*
*Йөрсен иде авыл исеме.*

Кеше туа, яши, нәрсәдер кора, таштан һәйкәл сала. Ләкин таштан салынганы гына һәйкәл була алмый әле. Шагыйрьләр килә, китә тора.. Аларның мирасы – шигырьләре, җырлары яши, туган авылларында музейлары ачыла, китаплары басыла. Туган җир үзенең улларын һәм кызларын онытмый. Тормыш дәвам итә.

*Кеше китә. Җирдә нәрсә кала?*
*Баскан эзе, эздә – туфрагы.*
*Шул туфракка төшкән орлык кала –*
*Җир-ананың бәбәй тулгагы.*
*Кеше китә, җирдә сагыш кала,*
*Җыры кала, җырда – моңнары.*
*Туган нигез, торган җире кала,*
*Атмый кала туар таңнары.*
*Кеше китә, кала нәсыйхәте,*
*Улы, кызы – нәсел хәтере.*
*Балаларга әйткән васыяте,*
*Үтәлергә тиеш нәзере.*
*Кеше китә, истәлеккә кала*
*Хәтирәләр – кеше әйтере.*
*Ак кәгазьгә язган сүзләр кала,*
*Ноктадан соң кала өтере.*
*Кеше китә. Җирдә нәрсә кала?*
*Кабер ташы, ташта – исеме.*
*Салкын ташны кочкан җилләр кала,*
*Туфрак була кеше җисеме.*
*Кеше яши бары мизгел генә:*
*Яшәү белән үлем арасы.*
*Онытмасын җирдә калган җаннар,*
*Мәңгелеккә һәркем барасы!*



**ӘДӘБИЯТ:**


1. Журналның шагыйрь К. Сибгатуллин иҗатына багышланган махсус саны // Мәйдан. – 2002. – №2. – 206 б.
2. Минһаҗева, З. Урман фасыллары: шигырьләр / З. Минһаҗева. – Чебаксар: «ИПК» «Чувашия», 2013. – 32 б.
3. Мөхияр, Р. Күңел тәрәзәләрем: шигырьләр / Р. Мөхияр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 207 б.
4. Сафин, Ф. Галәм күзе: шигырьләр, балладалар, поэмалар / Ф. Сафин. – Казан: «Идел-пресс», 2011. – 464 б.
5. Сибгатуллин, К. Бер ноктада: шигырьләр, поэмалар, баллада / К. Сибгатуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 560 б.
6. Суфиянов, А. Кылычлы җил: шигырьләр / А. Суфиянов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 207 б.
7. Якупова, С. Кар юлы: шигырьләр / С. Якупова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 223 б.



***Рәзинә МӨХИЯРОВА,***
*Яр Чаллы педагогия университеты доценты,*
*филология фәннәре кандидаты*


## ШАГЫЙРЬ АЙРАТ СУФИЯНОВ ПОЭЗИЯСЕНДӘ АКЛЫК КОНЦЕПТЫ

Табигать һәм кешелекне бик күп төрле төсләрнең чагылышы дип кабул итәргә мөмкин. Ул төсләрнең, төсмерләрнең иге- чиге юк. Салават күперендә аларның җидесен күрәбез:

*Бер очы урманга тоташкан,*
*Бер очы сыенган елгага.*
*Соклангыч җиде төс тарата*
*Салават күпере дөньяга.*

*(«Салават күпере»)*

Төсләр ярдәмендә психологлар кешенең холкын, халәтен дә ачыклый алалар. Шагыйрьләр, язучылар, рәссамнар төсләр аша дөньяны ничек кабул итүләрен, үзләре яшәгән тирәлеккә мөнәсәбәтләрен, рухи байлыкларын, әйтергә теләгән фикерләрен дә чагылдыралар.

Айрат Суфиянов шигырьләрендә төрле төсләрне файдалана. Мәсәлән, яшел: яшел бәйрәм, яшел гамь, яшел диңгез, яшел җил, яшел көз, яшел моң, яшел үлән, яшел яз, яшел яр, ямь-яшел бәрхет, ямь-яшел бөре, ямь-яшел күзләр, ямь-яшел өмет, ямь-яшел тирә-юнь, ямь-яшел хыял. Зәңгәр: зәңгәр ай, зәңгәр җил, зәңгәр көз, зәңгәр нур, зәңгәр төн, зәңгәр чишмә, зәңгәр шатлык, зәңгәр яктылык. Сары: сары иртә, сары сагыш, сары яфрак... Алсу: алсу бәхет, алсу сагыш... Соры: соры көз, соры көн... Кызыл: кызыл томан һ.б. Югарыда аталган төсләрнең күпчелеге – яктылык, матурлык чыганагы булып тора. Кара сүзен шактый гына кулланса да (кара болыт, кара елан, кара җир, кара йорт, кара кайгы, кара көнчелек, кара кул, кара сөрем, кара табын, кара төер, кара тузан, кара уй, кара ук), бу төс Айрат шигырьләрендә ак төскә контраст буларак файдаланыла. Шагыйрьнең иҗатында иң еш кулланылган төс – ул ак төс. Лирик герой җәмгыятьтәге проблемаларны, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне аңлап, үз җанындагы каршылыкларны да ак һәм кара төсләре аша оста тасвирлый:

*Һәркемнең дә күңел төпкелендә*
***Агы** да бар һәм бар **карасы.***
*Ике каршылыкның җимеше бит*
*Бу дөньяның адәм баласы.*
*«Эчемдәге **аклык** тышымда» – дип,*
*Ялгыш уйлап азмы йөрдем мин.*
*Рухи дөньям, сине өйрәнгәндә,*
*Күме тузан, чүп-чар күрдем мин.*
*Шайтан да бит анда исән икән,*
***Кара** төер булып укмашкан.*
***Ак** тән сакчым ялгыш күрми калган,*
*Күпме күзәнәккә тоташкан.*

*(«Бетә алмамдыр ла ачылып»)*

«Каршылык» дигән шигырьдә бу фикер фәлсәфи югарылыкка күтәрелгән:

*Каршылыкта минем акыл төшем,*
*Каршылыктан туган тереклек.*
***Акта** яши, яши **карада** да*
*Сулыш булып тиңсез бөеклек.*

*(«Каршылык»)*



Кешенең кешелеклелеге, иманы әнисенә мөнәсәбәтендә ачык чагыла.

А. Суфияновның әниләргә багышланган ике шигыреннән өзек китерәбез:

*Әнкәй көлсә, бөтен дөнья көлә.*
*Җирдә бәхет, бәхет күктә дә.*
*Әнкәйләр сау чакта иңнәр көчле,*
*Тау кадәрле йөкне күтәрә.*
*Тик аларны **ак** бәхеткә төреп*
*Яшәтергә соңлый күбебез.*
*Уянабыз, әнкәйләрне алгач*
*Кочагына туган җиребез.*

*(«Тугрылык»)*

*Сызланса да, йөзен чыткані юк,*
*Кыенсына безне яралаудан.*
*Әнкәй бәгърем, **ап –ак** фәрештәм син,*
*Аралаучым бәла- казалардан.*

*(«Газиз әнкәемә»)*

Лирик герой әнисен ап-ак фәрештәгә тиңли, исән вакытында «ак бәхеткә төреп яшәтә» алмавына көенә. А. Суфияновның шигырьләрендә лирик герой табигать сулышын тоеп, аңа дан җырлый:

*Әкияттәге кебек кышкы бер төн.*
*Бәс каплаган **ап- ак** каеннарны.*
*Әйтерсең лә күрәм тәүге кабат*
*Учлап-учлап*
*Җиргә энҗе сипкән тулган айны.*
*Көлә-көлә мамык карга батып*
***Аклык** кочагына егылганда,*
*Кышкы төннең **ак** уйларын данлап,*
*Җыр ярала чыңлап минем җанда.*

*(«Кышкы төн»)*

Шагыйрьгә табигатьнең һәр мизгеле якын, серле, сокландыргыч, хәтта бака тавышлары да аклыкка үрелеп, «ап-ак төнбоеклар арасыннан күтәрелә»:

*Зәп- зәңгәр төн, зәңгәр шатлык ага*
*Ерак йолдызларның карашыннан.*
*Күтәрелә бака тавышлары*
***Ап-ак** төнбоеклар арасыннан.*

*(«Егылдым мин ярга»)*

Шагыйрь җаны, аның лирик герое гел аклыкка омтыла, гел аклык эзли:

***Аклыкка** сусап, сафлыкка,*
*Кочаклыйм каеннарны.*
*Хәсрәтләнсәм, сорый алар:*
*«Әллә зур кайгың бармы?»*

*(«Рәнҗетә калсам ялгыш»)*

А. Суфияновның «Үлгән күбәләк» шигырен кош-кортларны, күбәләкләрне кыерсытучы балаларга уку, күп сүзле әңгәмә-лекцияләрне алыштыра алыр иде:

*Уч төбемдә **ак** күбәләк ята,*
*Күзгә яфрак кебек корып кипкән,*
*Көчкә-көчкә аны күтәрәм мин,*
*Шулкадәрле нигә авыр икән?*
*Әйтерсең лә тотып басып торам*
*Уч төбемә салып бер дөньны.*
*Терелмәсме? Кайнар сулышымны*
*Өрә-өрә мин җылытам аны.*

«Яшьлек тамыры» шигыренең башыннан азагына кадәр ак, аклык сүзләрен кулланып, шагыйрь яшәешкә гимн җырлый:

***Ап-ак** чәчле, ак сакаллы*
*Килсә дә картлык чорым,*
*Йөрәгемдә чыңлар иде*
*Үлемсез яшьлек җырым.*
***Ап-ак** дөнья, еракта тау*
*Күренсә дә **ак** булып.*
*Кышкы дисәм, түгел язгы–*
*Түбәсендә **ак** болыт:*
*Урманнар **ак,** һәр тарафта*
*Күпереп ята **ак** кар.*



*Кар астында күз күрмәгән,*
*Күңел тойган, юк, үлмәгән*
*Яшьлекнең тамыры бар.*

Айратның «Бәйләнеш» шигырендә, Җир шарындагы тереклек кебек, һәр сүзе, һәр җөмләсе бер-берсенә тыгыз бәйләнештә. Монда кешелекнең бик күп проблемалары чагылыш тапкан: кеше һәм табигать, илләр-кешеләр арасындагы мөнәсәбәт, сугыш һәм солых, әхлаки һәм экологик тәрбия…

*Яфрак сулый, сулый сайрар кошлар,*
*Бер-берсенә бәйле сулышлар.*
*Төшләр, өннәр, хыял-кичерешләр,*
*Бөек, гади, түбән язмышлар.*

*Туфрак сулый, һәр күзәнәк сулый,*
*Һәр күбәләк сулый, һәр бөҗәк.*
*Сулыш алган һәммә җан иясе*
*Бер тамырга бәйле игезәк…*

*Бер йөрәктән чыккан бер аһәңне*
*Йөзгә бүлде кеше акылы.*
*Кисәк белән кисәк сугышканда,*
*Заман ача тәмуг аркылы.*

***…Ак** чәчәккә бастым, башкалары*
*Ни булыр дип карап торалар.*
*Бу мизгелдә юлларыннан язып*
*Адашкандыр кебек торналар.*

*Шуннан күрдем **ап-ак** торналарның*
*Ямьле язга соңлап кайтканын.*
*…Тарих белә, бер алманы бүлеп,*
*Ике дәүләт канга батканын.*

Еш кына автор ак белән кара төсне бергә үреп биреп, фикерен укучыга үтә дә образлы итеп җиткерә:

*Изгелек, дип авыз суы корый*
*Икейөзле әллә кемнәрнең.*
*Ә үзләре бар **карасын** яга*
***Ак** көннәргә айсыз төннәрнең.*

*__Кара__ йөзгә __ап-ак__ бәйлек киеп*
*Үрмәлиләр өскә андыйлар.*
*Фанилыкны алдый алсалар да,*
*Ахирәтне алдый алмыйлар.*

*Тик __аклыктан__ гына __аклык__ туа.*
*Юк __карадан аклык__ туганы.*
*Кешелекнең олы фаҗигасе –*
*Чаккач кына күрә еланны.*

*(«Күргәнем бар чәчәк астыннан да...»)*

Лирик герой тормыш ваклыклары, каралыклар белән очрашса да, җаны һаман югарыга, аклык-пакьлеккә омтыла:

*Тарайса да дөньям, каралса да,*
*Югалса да эреп __ак__ төсләр.*
*Һаман әле күктән __аклык__ көтеп,*
*Киңлек көтеп, бәхет-шатлык көтеп,*
*Уяналар җанда __ак__ хисләр.*

*(«Тарайса да дөньям, каралса да...»)*

Айрат Суфияновның «Мин Ходайдан шундый язмыш сорыйм» дигән шигыре ак һәм аклыкка гимн. Анда аклык, ак төс сафлык, бәхет, мәңгелек символы булып гәүдәләнә:

*Мин Ходайдан шундый язмыш сорыйм,*
*Кайтып кергән чакта сагынып:*
*Туган якка егылыйм да сүним,*
*__Ак__ чәчәкләр калсын кабынып.*
*__Ак__ хыялым булган __ак__ болытлар*
*__Аклык__ юллап йөзеп йөрсеннәр.*
*Ул __аклыкны__ хөрмәт итә иде,*
*__Ак__ теләкле иде, дисеннәр.*
*__Ак__ бәхеткә __ап-ак__ юл күрсәтеп,*
*Фәрештәләр кайтсын дөньяга.*
*Пар канатлы булып, һәрбер сабый*
*Шат елмаеп баксын дөньяга.*
*__Ак__ чәчемә __ак__ күбәләк кунсын,*
*__Ак__ каеннар шау-гөр килсеннәр.*
*__Аклык__ өчен җанын фида кылып*
*Яши белде җирдә, дисеннәр.*



*Күтәрелсен җирдән күккә кадәр*
*__Ап-ак__ җырым, соңгы нур булып.*
*Чыңлый-чыңлый саф чишмәләр аксын,*
*__Аклык__ ватанына ургылып.*
*__Ак__ торналар очсын, __ак__ җил кочсын*
*Торналарның __ап-ак__ чылбырын.*
*Һәм табылсын __ап-ак__ шул чылбырда*
*Җаным сыялырлык буш урын.*
*Ләйсән яңгыр яусын, тамчылары*
*Ачык күзләремә керсеннәр.*
*Дөнья хәзер тоташ __аклык__ инде,*
*Борчылмыйча йокла, дисеннәр.*

Күп кеше башкаларның кимчелеген беренче чиратта күрә, яхшы сыйфатларын күрмәмешкә салыша. Айрат Суфияновның лирик герое исә хәтта кара болыттан да аклык эзли:

*Кара болыт күкне капласа да,*
*__Аклык__ эзлим кара болыттан.*
*Кулны тешләсә дә, эт малаен*
*Куеныма тыгып җылытам.*
*Кавыштырам __ап-ак__ роза белән*
*Хыялымда кара еланны.*
*__...Ак__ биләүдә балалары үсеп,*
*Нурлар диеп уйлыйм дөньямны.*

*(«Нәфрәттән дә мин мәхәббәт эзлим»)*

Ак сүзе гөнаһсызлык символы буларак та кулланыла:

*...Һәркемнең дә килә үзен __ак__ итәсе*
*Һәм күпертеп яхшы ягын күрсәтәсе.*
*Мин дә беләм: ялган-татлы, хаклык-ачы,*
*Хак Тәгаләм, гөнаһлымын, ярлыкачы.*

*(«Хак Тәгаләм, ярлыкачы»)*

Күренүенчә, Айрат Суфиянов шигырьләрендә ак сүзе төрле формаларда бик актив файдаланыла. Ул гади бер сыйфат – эпитет буларак та («ак төс», «ак күбәләк», «ак чәчәк», «ак каен», «ак кар», «ак кыш»...) образлы метафора буларак та («ак бәхет», «ак биләү», «ак болыт», «ак җил», «ак көн», «ак өмет», «ак теләк», «ак тынлык», «ак уй», «ак хыял»...) кулланыла.

Ак сыйфаты кайчагында исемләшә, мәсәлән: «актан акка», «агы да бар», «ак итәсе», «ак –карасы», «акта яши». Ак сыйфатыннан ясалган аклык дигән абстракт исем Айратның шигырьләренә пакьләнү, чистарыну, гөнаһлардан арыну символы буларак килеп керә («аклык кочагы», «аклык көтеп», «аклыкка сусау», «аклык табу», «аклык эзлим»). Гомумән, ак, аклык сүзләре аша лирик герой укучыны аклыкка, пакьлеккә өнди, югары әхлакый сыйфатларга бары үзеңнең җаныңны чистартып кына ирешергә мөмкин икәнлеген искәртә.


**ӘДӘБИЯТ:**

1. Суфиянов,А. Кылычлы җил: шигырьләр / А.Суфиянов. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2006. – 207б.



***Дания НИГЪМӘТҖӘНОВА,***
*Яр Чаллы педагогия университеты доценты,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан республикасының*
*атказанган мәдәният хезмәткәре*


## РӘШИТ БӘШӘР ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ БАЛАЛАР ОБРАЗЛАРЫ

Татар балалар шигърияте исемнәргә бай. Аларның һәркайсы үзенчә яза, тормыштагы матурлыкны үзенчә тоя. Әйтик Ш.Галиев иҗатына тапкырлык, шаянлык, көтелмәгән борылышлар хас булса, яшьрәк буын шагыйрьләрдән Р.Миңнуллин вакыйгаларны юмор белән сыгылмалырак итеп бирергә тырыша. Р.Бәшәр исә үзенең иҗат манерасы белән берсенә дә охшамаган. Аның шигырьләрендә балаларча сафлык, дөньяга гаҗәпләнеп һәм яратып карау хисе өстенлек итә.

Балалар язучысы, шагыйрь һәм прозаик Рәшит Гафар улы Бәшәр (Бәшәров) 1949 елның 7 октябрендә Татарстан Республикасының Кукмара районы Янил авылында колхозчы гаиләсендә туган. Урта белемне туган авылында алганнан соң, 1967-1972 елларда Казан университетының татар филологиясе бүлегендә укый. Университетны тәмамлагач, өч ел Ленинагорск районы Куакбаш авылы сигезьеллык мәктәбендә тел-әдәбият укытучысы һәм укыту бүлеге мөдире булып эшли. Аннары Лениногорск шәһәрендә 32 нче номерлы һөнәри-техника училищесының директор урынбасары вазифасын үти. 1977-1979 елларда тимер-бетон җиһазлары заводында мастер хезмәтләрен башкара. 1979 елда Чаллы шәһәренә күчеп килә. 1987 елга кадәр КамАЗның пресс-рам һәм запас частьлар заводларында инженер-диспетчер, автомат линияләр операторы булып эшли.

1987-1989 елларда Р.Бәшәр Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы икееллык Югары әдәби курсларда укый. Укуын тәмамлап кайткач, Чаллы шәһәрендәге «Таң йолдызы» газетасында бүлек мөдире, «Аргамак» журналында җаваплы сәркатип һәм 2001 елдан «Аргамак»ның дәвамы булган «Мәйдан» (Чаллы) журналында әдәбият бүлеге мөхәррире булып эшли.

Р.Бәшәрнең татар балалары әдәбиятындагы шигъри иҗаты укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде: 2000 елда «Сандугачлы бишек» китабы өчен Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиягә, 1989 елда Эдуард Касыймов исемендәге премиягә, 1997 елда «Аргамак» журналының Саҗидә Сөләйманова исемендәге премиясенә лаек булды. 2005 елда ТР мәдәният министрлыгы «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» билгесе һәм «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнде.

Рәшит Бәшәр укучыларга балалар язучысы буларак яхшы билгеле. Аның балалар өчен язган шигырьләре һәм хикәяләре республика матбугатында 60-нчы елларның ахырларында күренә башлый. Һәм шул вакытларда ук ул «Яшь ленинчы» газетасының «Нинди иркен минем туган илем!» девизы белән узган әдәби конкурсында җиңеп чыга. 1967 елның гыйнвар ае тагын бер сөенеч алып килде: «Сентябрь», «Арыш һәм сарут», «Истәлекле рәсем», «Аҗаган» исемле шигырьләрем «Ялкын» журналы оештырган «Чаткы» конкурсында беренче бүләккә лаек булдылар.

Шагыйрь Р.Бәшәр мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен яратып яза. Аның 1975-2003 еллар арасында басылып чыккан китапларының күпчелеге нәниләргә багышланган. Шагыйрьнең шигърияте тулысынча сурәтлелеккә нигезләнгән. Нәниләр өчен язган шигырьләрендә ул заманча тормыш күренешләрен, вакыйгаларны балалар күңеленә, аңына җиңел барып җитәрлек, аларда хыялый кызыксыну уятырлык шигъри образлар, маҗаралы детальләр аша бирергә омтыла. Шул рәвешчә, турыдан-туры үгет-нәсыйхәтсез генә, балаларның аң-белем, әхлакый тәрбиясенә педагогларча уңай йогынты ясый. Кечкенә генә шигырьләрендә дә хәрәкәт, вакыйгалар агышы өстенлек итә, бу исә укучыны фикер йөртергә, уйланырга этәрә.

Шагыйрьнең иҗаты турында язучы Галимҗан Гыйльманов бик матур фикерләр әйтә: «Р. Бәшәр шигърияте тулысынча сурәтлелеккә нигезләнгән. Тере, якты, хыялый төсләрдә сурәтләнгән табигатьтә, балачак күренешләрендә, әлбәттә, нәни геройларыбызның якыннарына, дус-ишләренә дә урын җитәрлек. Аның үз гаме, үз кыйбласы – Балачак иле. Ихлас, иманлы, талантлы каләме һаман нык, тоемчан һәм игелекле».

Тәнкыйтьче Рифат Сверигинның Р. Бәшәргә карата әйткән сүздә дөреслек ята: «Әдәбият аның өчен үзеңне Кеше, Шагыйрь, Рәссам икәнлегеңне белдерү, раслау чарасы. Ул балалар дөньясын искиткеч яхшы белә – аның әдиплек таланты шушы сфера-тирәлектә калку ачылып килә».

Р. Бәшәр шигырьләрен укыган бала шигърият арбасына утырып шигырь дөньясына кереп киткәнен сизми дә кала. Бәлки, нәкъ менә шунда чагыладыр да инде шагыйрьнең таланты. Бер шигырь арасы үткәнче, шагыйрь сабыйның күңеленә кешелек тудырган күркәм сыйфатлар орлыгын салырга өлгерә.

Ни сәбәпле сез нәкъ менә балалар өчен шигырь язасыз? дигән сорауга ул: «Яшь чакта балалар турында язармын дип һич тә уйламаган идем. Мәктәптә укыта башлагач, балалар белән аралашкач, яшьләр өчен болай да күп язалар, ә балалар өчен язучы бик юк, иҗатымны балаларга багышларга уйладым. Бала күңеле бик сизгер, ул алдашу, ялганны сизмәсен өчен бик күп көч куярга кирәк. Минем максат баланы алдамаска, тормышны ничек бар, шулай күрсәтергә – бөтен авырлыгы, бөтен кырыслыгы белән. Нәрсә языйм микән дип аптырап тормыйм. Үземнең янәшә-тирәдәге кешеләр, оныкларым – Рамил белән Ралиф геройлар булып киләләр дә керәләр».

Р. Бәшәр балалар дөньясын читтән генә күзәтеп тормый, әйтерсең, ул үзе малайлар, кызлар арасында йөри. Шуңа да автор белән балаларны аерып булмый. Шагыйрьнең «Уйнаганда» шигырендә качышлы уенында балалар кача, Әнисә аларны эзләп табарга тиеш. Ә тегеләр шундый нык качканнар, табылмыйлар да табылмыйлар. Ниһаять, үзләре теләп табылырга булалар, ләкин эзләүче үзе югалган. Ялгызлыктан качып, Әнисә куак төбендә йоклап киткән. Бала чагында кем белән булмаган мондый хәл?

Ә «Мин бит татар малае» шигырендә җитди, иманлы, игелекле, акыллы, фикерле малайны күреп сокланабыз:

*Һаваның да ае бар.*
*Мәчетнең дә ае бар,*
*Үземнең дә аем бар –*
*Айнур минем исемем –*
*Мин бит татар малае.*

Әлеге татар малаебыз әти-әнисенә ярдәм итә, чәй эчәргә утырганда, маэмайны сыйлаганда һәрвакыт «бисмилла» әйтә. «Догалар да белә ул, түбәтәй дә кия ул» – татар егете шундый булырга тиеш ди. Чыннан да, гади генә шигырьдә, гади генә сүзләр белән мөһим мәсьәләне күтәрә. Айнур бүгене көн татар егетләренә үрнәк булырлык.

Айнур Рәшит Бәшәрнең күп кенә шигырьләрендә очрый. Ул героебыз шәһәрдән. Һәр шәһәр малае кебек, ул, әти-әнисенә ияреп авылга гына түгел, диңгез тарафларына да, тау тарафларына да сәяхәт итә, әле Себер якларына, әле тайгага бара. Шигырьләрдә Айнурның күзәтүләре, кичерешләре. Мәсәлән, «Әкият сөйлә» шигырендә кояш, ай, җилләр, йолдызлар аңардан әкият сөйләвен үтенәләр. Малай аларга «Шүрәле»не укый, әбисе дә көйләп әкият сөйли. Ләкин Айнур үзе дә бик кызыксынучан малай, аның йокларга яткач Зөһрә кызны күрәсе, кыз турында күбрәк белергә тели. Ләкин әбисе генә инде йокыга киткән, Айнур аны уятырга кыймый. Күргәнебезчә Айнур әкиятләрне белә, геройлары турында да күп мәгълүматлы булырга тели.

Шагыйрь еш кына балаларга үтә дә таныш берәр күренешне яисә образны кулланып мөһим һәм кискен проблема да күтәрә. «Танышу» шигырендә нәкъ шундый очрак – автор монда уйнап-шаярып кына тел дәресе биреп куя:

*Күрсәтим дигән идем*
*Русча белгәнемне,*
*Әтәч тә аңламады:*
*– Привет! – дигәнемне*
*– Ки-ки-ри-күк! – диде дә,*
*Очты кунды киртәгә.*
*Акбай әйтә: – Татарча*
*Исәнләш, ди, иртәгә!*

Бу шигырь дә Р. Бәшәр хәзерге көн өчен актуаль булган мәсьәләне – рус һәм татар телен катнаштырып сөйләүне күтәрә. Фикер шигырьдә күзгә ташланып тормаса да, шагыйрьнең әйтәсе килгәне шул: сөйләшсәң, татар телендә генә яки рус телендә генә сөйләш, бу ике телне дә яхшы бел, ләкин икесен бергә катнаштырып, телләрне бозма. Бозып сөйләшкәнне хәтта хайваннар да тыңлап тормас.

Нәни героебызның абыйсы да («Керпе», «Төш», «Курай»), әнисе әтисе, әбисе («Сандугачлы бишек», «Бүген», «Кич»), бабасы («Таган», «Бал аертучы аю», «Яшен»), Фәнис, Әнис кебек дуслары, якыннары бар. Гомумән, авылда кызык маҗаралы тормыш белән яши ул. Мисалга түбәндәге шигырьләрне генә карыйк. «Джунглида» шигырендә кечкенә героебыз джунглида сәяхәт итә. Анда маймыллар белән чикләвек ашый, крокодил сыртына ятып ятып елгадан су да эчә, футбол да уйный, герой чыннан да джунглида йөри диярсен. Аның белән бергә джунглида йөргәндә, шигырь ахрында кечкенә геройның бары тик китап буенча гына сәяхәт итүен аңлыйбыз. Нәкъ тә менә шунда балаларның никадәр фантазиягә бай, көчле булуын аңлыйбыз. Һәм Р. Бәшәрнең балалар психологиясен бик яхшы аңлавына, тагын бер тапкыр инанабыз.

«Таган» дигән шигырьдә автор тупыллар арасында балаларны ымсындырып торган таган хакында яза:

*Йөгереп барасың да,*
*Кочаклап аласың да,*
*Атылып китәсең бер,*
*Мәтәлеп китәсең бер...*

Малай шулкадәр тиз атына, хәтта егылып та төшкәли икән, ләкин бу гына аның кәефен бозмый. Онытгы янына таганда атынырга бабасы да чыга һәм оныгын кошлар кебек очарга чакыра. Ләкин автор көтмәгәндә традицион дүртьюллык строфаны үзгәртеп, ике генә юлда көтелмәгән нәтиҗә ясап куя:

*Мин дә кош булам диеп,*
*Сөенеп куйды тагын.*

Димәк, бала фантазиясе җансыз әйберләрне, предметларны да җанландыра һәм алар уйлый башлыйлар.

Шул ук «Бал суыртучы аю» шигырендә бала күңеле, фантазиясе кешеләрне кыргый хайваннар белән дуслыкта яшәтә. Менә аю геройның бабасына бал суыртырга ярдәм итә:

*Бабай әйтә аюга:*
*– Талчыккан идем, ярый*
*Син булыштың әле, – ди.*
*Аю әйтә бабайга:*
*– Бал суырткан чагында*
*Тагын чакыр, яме! – ди.*



Хыяллана башласаң, хыялның иге-чиге юк бит ул. «Дөяләр» шигырендә герой да безнең якка килеп чыккан «Дөяләр» турында уйлана.

*Киләләр дә өркәчкә*
*Җилләр болыт өяләр,*
*Болытларны күтәреп*
*Китеп бара дөяләр.*
*Ерак микән юллары,*
*Барысы да саулар микән?*
*Дөяләр диеп торам,*
*Ә алар... таулар икән.*

Кайсыбыз гына балачакта герой кебек хыялланып күккә карап ятмаган да, андагы күренешләрнең берсен икенчесенә әйләндереп, яңадан үз фантазиясеннән рәхәтләнеп көлмәгән?!

Ә хәзер «Торналар» шигырендәге бик кызык малай белән танышыйк. Ул малайның иң яраткан һөнәре – кәгазь торналар ясау. Ләкин гади кәгазь торналар түгел, ә:

*Кая очкан торналар?*
*Өстәлемдә юк алар-*
*Минем кәгазь торналар.*
*Чыктым ишегалдына:*
*Күренмиләр торналар.*
*Еракларга мөгаен,*
*Очканнар инде алар-*
*Минем кәгазь торналар.*

Димәк, малайның торналары очарга сәләтле, алар чын торналар кебек әллә кайларга очып бара ала. Малаебыз торналарны очып киткәнгә юкка борчыла, чөнки ул урамнан керүгә алар өсәлгә кунганнар, үзләренең кечкенә хуҗаларын ташлап китмәгәннәр.

Бәйрәм җитсә, без әти-әниләр белән бергәләп урамга чыгабыз. Ә урам шундый матур – уенчык урам, диярсең. Бар кешеләр көләч, шат күңелле, кемгә генә дәшсәң дә, елмаеп җавап бирәләр. Безгә таныш малай да бар алар арасында.

*Беренче Май көнендә*
*Мин бәйрәм карап йөрдем,*
*Урамда мин орденлы*
*Бик күп абыйлар күрдем.*

*Их, минем төшемдә дә*
*Орденнар чылтыраса!*
*Иптәш малайларымның*
*Күзләре елтыраса!*

Күргәнебезчә, кайберәүләр кебек, аллы-гөлле шарларны гына күзәтеп йөрми бу малай. Өлкән буынга лаеклы алмаш буласы, батыр булып үсәсе килә аның. Шулай буласына чын күңелдән ышанып калабыз да.

Кем генә «болай эшләсәм, бу булачак» дип, әле эшләнә дә башламаган эшнең нәтиҗәсе турында хыялланмый. Өлкәннәр генә түгел, хәтта сабыйлар да яхшыны уйлап, эшне уңайга юрый. «Прәннек» дигән шигырьдәге бер малай да бабасы бакча казыганда хыялланып басып тора. Ягъни казылган җирдә түтәл ясыйсы, ашлыйсы, кишер чәчәсе, су сибәсе, чүбен утыйсы, ул кишерне тартып аласы, чистартасы, юасы. Шунысы кызык: бу эшләрдән ул читтә тора, ягъни абыйсы белән әтисе эшләргә тиеш. Ә менә кишер сатып эшләнгән акчага базарга барып прәннек алуда, ул турыдан-туры катнаша. Кызганычка каршы, малаебыз уйларын төгәлләргә өлгерми кала: аның борынын бал корты чагып ала:

*Прәннек булды борын,*
*Кишерне чәчмәс борын.*

Бу шигырьдә Р. Бәшәрнең күзгә бәреп тормаган алымы сизелеп тора, ягъни үзең эшләп ашарга кирәк. Бәлки малай ул эшләрне үзе эшләп үзе башкаруын күз алдына китерсә бал корты да чакмаган булыр иде дигән нәтиҗә ясый алабыз.

Айнурның дуслары Фәнис һәм Әнис белән «Коймаклы таба» шигыреннән танышыйк. Алар бик тә уңган, бик тә булган малайлар. Ник дисезме? Фәнис белән Әнис коймак пешерергә булганнар. Фәнис пешерсә, Әнис әлеге коймакларны ашап тора. Ләкин таба бик кызган, һәм

*Яңгыр эзләп очты ул*
*Эссе дә пешеп туйгач.*

Ә малайларга күктән кояш елмаеп куя, һәм алар кояшны табадан төшеп калган зур коймакка охшаталар. Бу шигырьдә язучының балалар дөньясы белән нык тыгыз бәйләнештә торуы, аны аңлавы сизелә. Өлкән кеше кояшны, бәлки, янып торучы түгәрәккә охшатыр иде, ә бала күңелендә кояш – әле генә табадан



төшкән коймакны хәтерләткән. Бу бары тик тагын бер кат балаларның фантазиягә бай булуларын күрсәтә.

Бала чакта һәр җимеш тә тәмле була, җитешкәнме, юкмы, кызылмы, яшелме. Үз бакчабызда булмаса, күрше бакчасында була, шунда керергә туры килә. Капкадан түгел, ә койма башыннан кереп, хуҗалар күрмәгәндә генә берәр тәлгәшен өзү – бер батырлык. «Шомырт тотты якадан» шигырендәге героебызның да үзен ымсындырып торган шомыртны ашыйсы килә, әле күршенекен түгел үз бакчасындагысын. Ләкин тәлгәшне өзгәндә шомырт аны якасыннан эләктереп ала һәм кычытканга чактыра, бу карак малайга карарга кешеләрне чакыра. Бакчага песи керә, телгә килеп:

*– Синең мондый икәнне*
*Белмәгәнмен, ди, элек.*
*Чыкты сызды бакчадан:*
*– Тор инде, ди, эленеп.*
*Сузыла да кычыткан*
*Тәпиемне пешерә...*

Димәк, авторның әйтергә телләгән фикере: рөхсәтсез бернәрсәгә тияргә, каракланып йөрергә ярамый. Хуҗалар күрмәсәләр дә, йорт хайваннары һәм әйләнә-тирә сине күзәтеп тора.

«Иртән» шигыре герое бакаларны күзәтә. Аларга нидер булган, борчулары йөзләренә чыккан, нәрсәдер киңәшләшәләр. Малаебыз исә бакаларның борчуларын бик тиз аңлап ала:

*Бит юарга сабыннары*
*Юк икән бит аларның.*

Р. Бәшәрнең бу шигырендә дә диалектика көчле, ярылып ята, автор әйтәсе фикерен малай авызыннан әйттерә. Ягъни иртән, йокыдан торгач һәркем юынырга тиеш. Һәм бу гадәт балаларга бәләкәйдән салынсын.

Кечкенә героебыз авылга бик еш кайта дидек. «Безнең кайсыбыз кунак?» шигырендә авылга кайтуы, капка төбеннән үк үз көчекләренең аны каршы алуы, сагынып көткән булуы күрсәтелә. Алар икәүләп әбисе пешергән коймактан бик озак авыз итәләр. Шуннан соң сандугач килеп кунак малаен өйгә чакыра. Шунда героебыз уйлап куя:

*Безнең кайсыбыз кунак?*
*Монда әллә мин кунак,*
*Әллә кунак Акмуйнак?*

Әлбәттә, малай – кунак кеше, шуңа да Акмуйнак аның тирәсендә бөтерелә, «әби бар дип тә оялмый”, чөнки кунак тиздән китәчәк тә әле. Кайсыбызны авлда этләребез, песиләребез шулай каршы алмый?!

Шигырьдә гәүдәләндерелгән геройлар табигатькә гашыйк сәяхәтчеләр генә түгел, ә шул сокландыргыч дәрьяга хуҗаларча караучылар, табигать яраларын үз яралары итеп кабул итүчеләр буларак та күз алдына килә:

*Бер урманда минем зур бер*
*Аю буласым килә,*
*Мылтык тотып абыйларны*
*Ерак куасым килә...*
*Тизрәк үсеп бик-бик әйбәт*
*Кеше буласым килә.*

Күргәнебезчә, шагыйрь балаларда табигатькә карата мәхәббәт тәрбияләүгә геройларның үз уйланулары һәм аның яшеллек дөньясына үз мөнәсәбәте аша якын килергә омтыла.

«Сандугачлы ак инеш» шигырендә Ак инешнең киләчәге кызганыч итеп сурәтләнә. Ягъни тирә-ягында агачлар бетеп, сазлыклар кимеп бара, казлары очып китә, балыклары диңгезгә кача, сандугачлар кунып сайрасын өчен таллар да калмаган, һәм үзе дә кибеп кешеләргә үпкәле. Бу хәлләр булмасын өчен шигырьдә геройларыбыз утыртырга куаклар алып килгәннәр, аның гел агып торуын, яшел булуын, сандугачлар сайравына күмелүен телиләр.

Героебыз күп тапкыр язмыш, тормыш турында уйлана. Мәсәлән, «Әгәр» шигырендә малай җир булмаса, чәчәк тә үсмәс, күк булмаса, йолдызлар янмас, су булмаса, балыклар йөзмәс:

*Җир һәм һава*
*Су булмаса,*
*Үзем дә булмас идем.*
*Кояш астында болай*
*Елмаеп тормас идем, –*

дип уйлана. Димәк, бала тормышның, яшәешнең чыганагын җирдә, һавада, суда күрә һәм аларны саклау, чиста тоту кирәк дигән фикерне белдерә. Ләкин бала аңлаган авыр мәсьәләне зур кешеләр кайчак аңлап бетерми, завод-фабрикалар төзеп, су-һава пычырана, хайваннар дөньясына, кешелеккә зыян килә.



«Язмыш» шигырендә исә, герой алда үзен нәрсә көтәсен белми әле, чөнки беркемгә дә зыяны тимәгән чәчәкне дә арба белән таптап узалар, ә чәчәкнең елавын берәү дә күрми. Шуңа да герой үзен дә шул чәчәк кебек таптап китәрләрме икән дигән сорау белән борчыла:

*Мин дә белмим бит әле*
*Башның ни күрәчәген.*

Шигырьдә язмыш дигән фәлсәфи тема турында кечкенә кешенең уйланулары күрсәтелә. Бала чактагы хыялларның тормышка ашу-ашмавын әти-әнидән, тирә-яктан һәм, әлбәттә, инде үзебездән тора. Җәмгыятьтә яшәүнең үз законы бар: көчле кешеләр һәрвакыт тормышта үз урыннарын таба, ә көчсезләр авырлыклар алдында җиңелеп кала. Шуңа да бала үзенең алдында туган аврлыкларны җиңәргә көч таба алу-алмавын әлегә төгәл әйтә алмый. Шул сәбәпле, ул киләчәген төгәл күзалламый.

Аның һәр герое тормыштан алынган, һәр герое балалар психологиясен ачарга, аңларга ярдәм итә. Үзе дә балалар кебек беркатлы, самими, бала күңелле, шаян булмаса яза алыр идеме икән ул шундый шигырьләрне? «Бала булып калмаса, балалар өчен өчен ихлас иҗат итә алмый ул. Балалар язучысы гомер буе балалар кебек беркатлы, ярдәмчел, чиста күңелле, теләсә кем алдаганга ышанып, юк кына нәрсәгә дә сабыйларча сөенеп йөрмәсә, шәп әйберләр яза алмаячак».

Р. Бәшәрнең көчле ягы – әйләнә-тирәне рәссамча күрә, табигатькә җан өрә белүендә, һәм балалар күңелен аңлый, дөньяга алар күзе белән карый алуында. Шуңа да ул – балалар тәрбиячесе. Үз иҗатының максатын, тормыш кыйбласын да ул балаларга матурлыкны, яхшылыкны тәрбияләүдә күрә.

Шулай итеп, без Рәшит Бәшәрнең күп кенә шигырьләрендәге балалар образлары белән таныштык. Геройларыбыз шаян, акыллы, чиста күңелле, самими, беркатлы, хыялый, фантазиягә бай. Р. Бәшәрнең дә нәкъ шундый сыйфатларга ия булуын күрдек, чөнки геройлар кичергәнне үзе кичермәсә, аның шигырьләрендәге ул образлар уңышлы булмас иде.

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Бәшәр, Р. Ай кызының зәңгәр чиләге: [шигырьләр] / Р. Бәшәр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1990.
2. Бәшәр, Р. Әйлән – бәйлән: [шигырьләр] / Р. Бәшәр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1975.
3. Бәшәр, Р. Сандугачлы бишек: [шигырьләр] / Р. Бәшәр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2002.

4. Гыйльманов Г. Кыйбласы-Балачак иле / Г. Гыйльманов // Бәшәр, Р. Сандугачлы бишек [шигырьләр] / Р. Бәшәр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2000. – Б. 159
5. Даутов, Р. Балачак әдипләре / Р. Даутов. – Казан: Мәгариф, 2004.
6. Сафин, Ф. Күңелдәге кызыл миләшләр / Ф. Сафин // Нур. – 1997. – №4.
7. Хатипов, Ф. Әдәбият теориясе / Ф. Хатипов. – Казан: «Раннур» нәшрияты, 2002.

***Альбина РИЗВАНОВА,***
***Гөлназ БӘШӘРОВА,***
*Чаллы шәһәренең*
*муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе*
*«Пушкин исемендәге 78 нче пролицей» укытучылары*

## КЕШЕ КИТӘ, ЭШЕ КАЛА
## (Язучы Эдуард Касыймов иҗаты буенча)

Кыя-таулар никадәр биек булса, аның зурлыгын, мәһабәт матурлыгын тулырак күрү өчен дә шулкадәр читкәрәк, еракка-рак китеп карарга кирәк, диләр. Күренекле татар язучысы, талантлы публицист, фольклорчы Эдуард Касыймов – әнә шундый кыя-тауларның берсе иде. Инде вакытсыз вафат булуына 30 елга кадәр вакыт үтсә дә, әдипнең янә бер тапкыр узган гомер юлын, ул калдырган мирасны күз алдына китереп, соклану һәм горурлану хисләре кичерәбез. Әйе, биек кыялар, текә таулар иңендә качып торган кебек, бөек шәхесләр дә буш урында гына тумый. Аларны гасырлар дәвамында җыелып туплана килгән халыкчан рух, зур социаль һәм милли күтәрелеш дәверләре, чорлары тудыра.

Эдуард Салихҗан улы Касыймов 1930 елның 7 ноябрендә хәзерге Киров өлкәсенең Слободский районы Карино авылында укытучы гаиләсендә туа, җиде яшендә ярым ятим кала. Әтисе «халык дошманы» дип гаепләнә, кулга алына, 1937 елда атып үтерелә. 1948-1953 нче елларда Э. Касыймов – Казан дәүләт университеты студенты. Университетта уку елларында көндәлек матбугатта аның беренче әдәби иҗат тәҗрибәләре – зарисовкалары, кыска-кыска очерклары һәм хикәяләре күренә башлый. 1953 елда университетны тәмамлагач, укытучы булып эшли. 1957 елда Э. Касыймов, яңадан Казанга килеп, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага керә. Фольклорның төр һәм жанрларын җентекләп өйрәнә, диссертация яза. Әдәби иҗат эшен дә онытмый: 1959 елда яшь авторның беренче мөстәкыйль китабы – балалар тормышына багышланган «Кызыл маяклар» исемле хикәяләр җыентыгы, ә 1962 елда «Кояш көн дә чыга» исемле повесте басыла. 1964 елда әдипнең үз биографиясен һәм әтисенең фаҗигале язмышын чагылдырган «Гомер ике килми» исемле романы дөнья күрә. 1965-1967 елларда Э. Касыймов Алабуга педагогия институтында татар фольклоры һәм татар әдәбияты курсын укыта, монда аның зур күләмле әсәрләре – Кама буендагы Бондюг (хәзерге Менделеевск) химия заводы тарихына багышланган «Томан аша» романы, тормышның төрле катлауларын кузгаткан «Бир кулыңны, дустым!», «Көмеш язулы кылыч», «Сорбонна профессоры һәм без» повестьлары басылып чыга. 1971 елда әдипнең «Томан аша», «Һаваларда тургай» роман – диалогиясе, русчага тәрҗемә ителеп, «Чулман – река внуков» исеме белән 1976 елда Мәскәүнең «Современник» нәшриятында басыла.

Ул 1964 елдан СССР Язучылар Союзы члены була. 1972 елда әдип Алабугадан Чаллыга күчә. 1980-1981 нче елларда Чаллы язучылар берлеге белән җитәкчелек итә. Кама буйларына автогигант корылышы алып килгән зур үзгәрешләр, яңарышлар турында байтак кына очерклар, кыска хикәяләр һәм мәкаләләр язып бастыра. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм илле яше тулу уңае белән, Э. Касыймов 1980 елда «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә.

Әдәбият үсешендә билгеле бер эз калдырган татар язучыларның күбесе үзләренә якты йолдыз итеп халык авыз иҗатын сайлыйлар. Э. Касыймов та озак еллар дәвамында халык авыз иҗатын төп чыганактан – җанлы телдән җыйнау, туплау бастырып чыгару, гыйльми өйрәнү белән шөгыльләнә, татар халык әкиятләрендә сатира һәм юмор яшәеш рәвешен тикшереп, фәннәр кандидаты дәрәҗәсен ала.

Күргәнебезчә, Э. Касыймов – дистәдән артык китап, күп санлы романнар авторы. Аның иҗат мирасы бай, күләмле. 60-70 еллар биеклегеннән чыгып бәяләгәндә, бу мирас татар әдәбиятында лаеклы урын алып тора. Галимнәр, 1970 елларның татар прозасын өйрәнеп, күп кенә язучыларны, шул исәптән Э. Касыймовны да, заман темасы кызыксындыруы, аларның катлаулы чорның төрле якларына кыю рәвештә үтеп кереп, әсәрләрендә актуаль мәсьәләләр күтәрелүе, укучыларны тирән борчый, уйландыра торган сорауларга җавап табарга тырышулары турында язалар.

Язучының беренче әсәрләре («Кызыл маяклар», «Кояш көн дә чыга») укучы күңелен торган саен ныграк били, әдәби тәнкыйть әдәбиятка өметле прозаик килүен билгеләп үтә. «Кызыл маяклар» исемле хикәяләр җыентыгы балалар өчен язылган.

«Кояш көн дә чыга» әсәрен язучы фольклор экспедицияләре биргән бай материалга таянып язган. Әсәрнең төп герое – тумыштан сукыр булган Абдулла. Аның аянычлы язмышы, авыр халәте, аңа карата төрле кешеләрнең төрлечә мөнәсәбәте әсәрдә ышандырырлык детальләр белән сурәтләнгән. Авылдашлары, гаиләсе Абдулланы яратып, хөрмәт итеп яшиләр, чөнки ул яхшы күңелле, талантлы кеше: гармунда яхшы уйный, бик матур җырлый. Авылның фольклорын өйрәнергә килгән Якуп Сәйфи, гаиләсе, авылдашлары аңа ярдәм итәләр, ниһаять, аның күзләре күрә башлый.

Без төрле. Безнең арабызда сәламәт кешеләр белән бергә гариплэр дә бар. Җәмгыятебездә гарип кешеләргә карата мөнәсәбәт төрле: кемдер кызгана, кемдер ярдәм итә, кемдер кимсетә… Автор фикеренчә, гарипләргә, авыруларга ярдәм итәргә кирәк, чөнки алар аңа һәрдаим мохтаҗ.

«Гомер ике килми» романында Э.Касыймов Сталин режимының асылын әдәби сурәтләүдә биргән. Бу роман – аның үз биографиясен һәм әтисенең фаҗигале язмышын реалистик планда сурәтләгән иң күренекле әсәрләренең берсе. Әсәрдә бирелгән тормышчан вакыйгалар, кызыклы һәм аянычлы хәлләрукучыда кызыксыну уята. Бу әсәрдә язучының халык иҗаты белән бәйләнеше аеруча көчле сизелә. Ул фразеологизмнардан, әйтемнәрдән, бәетләрдән уңышлы файдалана. Тел-сурәтләү чаралары: метафоралар, сынландыру, чагыштырулар әсәрдәге геройларның күңел дөньясына тирәнрәк үтеп керергә ярдәм итә.

Кешегә яшәү өчен гомер бер генә бирелә. Ләкин кайвакыт язмыш кеше гомере белән рәхимсез шаяра, картлар юкка гына «Үкенечләр белән дөнья тулган», – дип әйтмиләр бит. Файдалы, заяга узмаган гомернең ахыры үкенечле булмый. Бер-берсен яратып өйләнешкән Мөнирә белән Назимның да тормышы матур булырга тиеш иде… Ләкин күпләрнең пар канатларын каерган, балаларны ятим иткән, якты өметләрне җимергән шәхес культы чоры Тимербулатовларның гаиләсен дә читләтеп үтми. Мөнирә, авырып, урын өстендә ята. «Халык дошманы» хатыны булу, ачлык, билгесезлек, авыр тормыш, гаҗизлек, юксыну, сагыну хисләре, балалар өчен борчылу аны хаста итә. Әсәр унике бүлектән – унике төннән тора. Ул хатирә рәвешендә язылган.



Төп герой – Мөнирә унике төн буена ире Назимның рәсеме белән серләшә.Романның теле гади, аңлаешлы, һәрбер укучыга барып җитәрлек, үтемле итеп язылган. Вакыйгалар шундый җанлы итеп сурәтләнгән ки, укыганда күңел тула, ирексездән күзгә яшь килә.

Мөнирә Карилегә эшкә килгәч, Гали һәм аның иптәше Назим белән таныша. Галигә кияүгә чыга. Галине дошманнар үтергәч, Мөнирә тормышын Назим белән бәйли. Бу вакытта инде аның мәрхүм иреннән бер кызы була. Өч малай табып, тыныч кына яшәп ятканда, Назимны кулга алалар. Район газетасында «Кем ул?» дигән баш астында Назим Тимербулатов турында мәкалә басылып чыга. Анда аның морза нәселеннән икәнлеге, үзенең нәсел-нәсәбеннән котыла алмаган бер бәндә, партия политикасына аяк чалучы дип, Казанда партия сафыннан сөрелгән Сабир Дүнәшев белән элемтәдә торганлыгы турында әйтелә. «Кем ул?» дигән сорау куела мәкалә ахырында һәм «аның халык дошманы булуында һичнинди шик булырга тиеш түгел» дигән җавап бирелә. Шуннан соң башлана инде авыр көннәр. Дуслары Мөнирәдән йөз чөерә. Аны, «Халык дошманы» хатыны булганга, мөдирлек эшеннән алалар. Менә шушында Мөнирәнең хатын-кыз, ана буларак көчле, ихтыярлы кеше икәнлеге күренә. Атасыз калган, рәнҗетелүгә дучар булган балаларны язмыш дулкынына ташламыйча үстерә. Авыр тормышта яшәсәләр дә, Мөнирәнең балалары югары белем алалар, гаилә коралар һәм бервакытта да әти-әниләрен онытмыйлар. Алар көткән гаделлек барыбер өскә калкып чыга: аларның әтиләре Назим Тимербулатов гаепсез дип танылa.

Мөнирәгә бу дөреслекне, гаделлекне табу, ай-һай, кыен була. Балалары белән тормыш дулкыннарына ташланган хатын язмышының бөтен ачысын-төчесен татый. Тик бервакытта да азмый-тузмый, әхлак киртәләрен узып чыкмый, намусына тап төшерми. Иренә тугры, балаларына изге ана булып кала. Әсәрдә һәртөрле каршылыкларны, авырлыкларны җиңгән, горурлыгын, вөҗданын һәм халкына тугрылыгын саклаган геройлар югары куела. «Гомер ике килми» әсәрендә язучы хөкем чыгаруны безнең үзебезгә калдыра. Кем гаепле? соравына җавапны без үзебез табарга тиеш. Бу исә безне уйланырга, бәя бирергә этәрә. Шушы романны укыгач, укучы алдына мәрхәмәтсез чор күз алдына килеп баса. Назим, Мөнирә, аларның балалары… Бик күп булганннар бит алар.. Өзелгән өметләр, киселгән бәхетләр өчен гаепле кем ул? Автор үзенең әсәрендә бу сорауны юкка гына куймагандыр.

Э. Касыймовның «Чулман – оныклар дәрьясы» («Томан аша», «Һаваларда тургай») диалогиясендә Бондюг химия заводына бәйле вакыйгаләр яктыртылган. Үткән гасырның алтмышынчы елларында татар әдәбиятында завод-фабрикалар, производство коллективлары тормышына игътибар бермә-бер арта. Табигый ки, социалистик иҗат методы белән язылган әсәрләрдә без мондый күренешне ачык күрәбез. Бу шул чорның таләбе булган. Э. Касыймов та, башка язучылар кебек, әнә шундый эшкә алына. Аны үзенең бай тарихы, данлы үткәне, матур традицияләре белән аерылып торган Бондюг заводы үзенә тарта. Әлбәттә, язучы Бондюг заводы тарихын язуны максат итеп куймагандыр, чөнки ике романда да заводның 70 еллардагы тормышы турында язылган. Ләкин шунысын әйтергә кирәк, романнарны укыганда, Менделеевскка бәйле чорлар белән дә Э. Касыймов таныштырып бара. Әлеге романнарда бирелгән төп геройлар, үз мәнфәгатьләрен икенче планга куеп, завод мохитен кайгыртып яшиләр. Автор эшче династияләрен сурәтләүгә дә игътибар итә.

Бөек шагыйребез Һ. Такташ үзенең «Киләчәккә хатлар» поэмасында болай дип язган: «Безнең бөек чорның каршылыклы кешеләрен аңлый алмассыз». Әйе, хәзерге яшьләргә бөек төзелешләр чорында янып яшәүче Э. Касыймов кебек әдипләрне аңларга авырдыр. Ләкин ул заманда эшчеләр тормышы турында язылган диалогия укучылар тарафыннан бик җылы каршы алына, рус теленә тәрҗемә ителеп «Чулман – река внуков» исемендә Мәскәүнең «Современник» нәшриятында басылып чыга, эшчеләр темасына язылган иң яхшы әсәр буларак Бөтенсоюз конкурсында ВЦСПС һәм СССР язучылар Союзы премиясенә лаек була.

Э. Касыймовның «Бир кулыңны, дустым!» повесте мәхәббәт темасына язылган. Язучы бу повестьта студент-яшьләр тормышын, аларның мөстәкыйль тормышка беренче адымнарын сурәтләгән. Әсәрнең төп геройлары – Әхсән белән Әлбинә, Роберт. Әлбинә – эшчән, тырыш, нинди генә эшкә алынса да, башкарып чыга ала торган намуслы кыз. Язмыш җилләре, аны сөйгән егете Әхсәннән, бергә укыган студент дуслары Света белән Гөлсинәдән аерып, Тигәнәкле авылына, Рабига апа йортына илтеп ташлый. Ул шушы авылда балаларга рус теленнән белем бирә. Акыллы, эшчән кызны авылда балалар да, укытучылар да тиз арада яратып өлгерәләр.

Тик шушы инсафлы, яхшы һәм нечкә күңелле кыз белән язмыш аяусыз шаяра: Әлбинә сөйгән егете Әхсән тарафыннан алдана. Аның сөйгән егете – яшьтән үк спортсмен, булачак тренер Әхсән. Бер карасаң, чын дус, тормыш иптәше булырлык бу егет хакында берәү дә начар уйлый алмас иде. Тик Әхсән Әлбинәне бөтенләй оныта, аның күңелендә бу кызга карата бернинди мәхәббәт хисе юк, хәтта ул аны кызганмый да. Ә бәлки, ул Әлбинәне яратмагандыр да… Элеккеге романтика коры мавыгу гына булган, күрәсең. Әхсән, аны өзелеп яраткан кешенең йөрәк түрендә туачак баласы булса да, аның язмышына битараф булып кала. Сөйгәненең каты бәгырьлеген белгәч, Әлбинә бик авыр хәлдә кала.

Нәкъ менә шушы авыр минутларда Әлбинәгә дуслары ярдәм кулы сузалар. Юкка гына автор әсәрен «Бир кулыңны, дустым!» дип атамагандыр!. Әсәрне укыгач, күренекле шагыйребез Х. Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы, бәйлисе бар йөрәкне?» дигән сүзләре дә искә төшә. Ышанычлы, якын дуслары булганга гына, Әлбинә тормыш упкынына төшүдән котылып кала ала. Чын, ышанычлы, тугры дус! Шулай дип аталырга Роберт хаклыдыр. Чөнки авыр хәлдә калган Әлбинәгә ярдәм кулы сузучы ул була. Бернигә карамыйча, ул Әлбинәгә мәхәббәтен белдерә һәм үзенә кияүгә чыгарга тәкъдим ясый.

Әсәр язылганга өч дистә елдан артык вакыт узган. Шулай булса да, повестьта күтәрелгән проблемалар бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмыйлар, киресенчә, һәр тарафта әхлаксызлык чәчәк аткан җәмгыятьтә мөһим роль уйныйлар. Чөнки «Бир кулыңны, дустым!» әсәрендә сурәтләнгән вакыйгалар тормышта бик еш очрыйлар…

Э. Касыймовның геройлары төрле. Күргәнебезчә, алар төрле һөнәр вәкилләре: эшчеләр, студентлар, галимнәр… Күбесе түбәндәге яхшы сыйфатларга ия: көчле ихтыярлы, тирән хисле, тырыш, әдәпле, белемле… «Сорбонна профессоры һәм без» повестен да автобиграфик әсәр дип атасак ялгыш булмас. Әсәрдә студентлар, галимнәр тормышы сурәтләнгән. Үзәктә профессор Одинцов образы. Ул дөньякүләм билгеле зур галим. Тормышында бик күп авырлыклар күрсә дә, ул бик яхшы күңелле, йомшак табигатьле булып калган. Профессор Одинцов – тирән белемле, зур эрудицияле, үз эшен ярата торган кеше. Әсәр профессорның үлеме белән бетсә дә, ул кешенең сынмас ихтыярына, аның рухи бөеклегенә мәдхия булып яңгырый дип бәяләделәр тәнкыйтьчеләр. Безнең мәгърифәтче язучыларыбыз кебек, Э. Касыймов та Одинцов образы аркылы гыйлемлелекне, мәрхәмәтлелекне мактый. Кешенең әхлакый камиллеген белем алу белән бәйли.

Эдуард Касыймовның иҗаты чаллыларга икеләтә кадерле, чөнки ул шул вакытта җырларда җырланган, зур төзелешләр шәһәре Чаллыда яши. Зурлыгы һәм әһәмияте белән бөтен дөньяга мәшһүр КамАЗ заводы эшчеләрен көн дә күреп ( ул анда эшләгән дә), алар белән сөйләшеп, хәл-әхвәлләрен белеп тора. Заводның зур проблемалары, кешелек алдына заман куйган куйган олы бурычлар үзәгендә кайный. Һәр мәсьәләнең асылына төшенеп, эзләнеп һәм табып иҗат итә. КамАЗ – республикабыз өчен яңа төр завод. Ул зурлыгы, бөеклеге белән түгел, яңалыгы белән дә сәнгать кешеләре күңелендә яңа киңлекләр тудыра, иҗат итү өчен мөмкинлекләр ача. Э. Касыймов бу елларда гигант төзелеш, КамАЗ заводы, аның эшчеләре турында байтак очерклар, хикәяләр һәм зур күләмле «Җир балкышы» исемле романын яза. Оптимистик рухта язылган бу әсәрдә шәһәр яны авыл халкы тормышында шул икътисади һәм рухи үзгәрешләр нәтиҗәсендә туган катлаулы хәлләрне әхлакый, фәлсәфи күзлектән чыгып анализлый.

Э. Касыймовның иҗатына кыскача күзәтү ясагач, тагын бер тапкыр аның укучылар күңелендә лаеклы урын алуына инандык. Язучының төп геройлары – гади эшчеләр, инженерлар, студентлар, авыл кешеләре, кайнар йөрәкле яшьләр, галимнәр, акыл туплаган өлкәннәр.Автор тормышчан образлар тудыра алган. Әдәбият белгече Тәлгат Галиуллин «Э. Касыймовның әсәрләрен чын-чынлап, объектив өйрәнү – киләчәк эше» дигән һәм «эшләнгән изге эш алда» дип өстәгән. Без, татар теле укытучылары, үзе исән чакта иҗатына тиешле бәя алмаган бу күренекле язучының әсәрләре татар әдәбиятында лаеклы урын алыр, тиешле бәягә лаек булыр дип ышанып калабыз.

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Галиуллин, Т. Сайланма әсәрләр / Т. Галиуллин. – Казан: «Хәтер» нәшр., 2013.
2. Касыймов, Э. Кояш көн дә чыга: повесть / Э. Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963.
3. Касыймов, Э. Гомер ике килми: роман / Э. Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964.
4. Касыймов, Э. Бир кулыңны, дустым!: повесть / Э. Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969.
5. Касыймов, Э. Сорбонна профессоры һәм без: повесть / Э. Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971.
6. Сафин, Ф. Еллар яктысы: [язучы иҗатын бәяләп] / Ф. Сафин // Казан утлары. – 1980. – №11. – Б. 161-163.





***Илнара ҖИҺАНШИНА,***
*Чаллы шәһәренең*
*муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе*
*«10 нчы гомуми белем бирү мәктәбе»*
*9нчы сыйныф укучысы.*
*Җитәкчесе Арсланова Зөһрә Сәми кызы*


## ТАБИГАТЬ ҺӘМ КЕШЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ (Эдуард Касыймовның иҗаты һәм тормыш юлы)

Әдәбият – тормышыбызның көзгесе. Кайсы әдипнең китабын һәм нинди әсәрне генә кулына алмасын, укучы ирексездән шул чорда, шул дөньяда кайный башлый. Матур әдәбият элек – электән кеше күңелендә иң җылы, нечкә хисләр, матурлык, нәфислек, яхшылык, яктылык уятучы, тормышны күрә, бәяли белергә, кеше булырга өйрәтүче көчләрнең берсе булган.

Татар халкының бай рухи культурасы тарихында татар язучысы, прозаик, галим, фольклорчы, тирән фикер иясе Эдуард Касыймов иҗаты аерым бер урын биләп тора.

Эдуард Касыймов татар теленең төп сөйләмнәренең берсен тәшкил иткән тарихи үзенчәлекле, бай Нократ сөйләменең үзәгендә – Нократ авылында 1930 елның 9 ноябрендә туа. Тел тоемлау, аны куллану сәләте әти-әнисеннән килә. Әтисе укымышлы, аралашучан, актив зат буларак (авыл советын җитәкли, колхоз оештыруда катнаша, укытучы була), бу сыйфатларын балаларына да йоктыра. Тик Эдуардка әтисе мәктәбендә озак укырга туры килми – мәктәп директоры Салихҗан Касыймов «халык дошманына» әйләнә, кулга алынып, 1937 елны атыла. Эдуардның әнисе, балаларын ияртеп, туган каласы Малмыжга китәргә, туган-тумачага сыенырга мәҗбүр була. Эдуард шунда татар мәктәбендә сигезне, урыс урта мәктәбендә унынчы классны тәмамлый.

Эдуард Касыймов татар фольклорын һәм әдәбиятын укытуга һәм пропагандалауга күп көч куя, гомумән, татар әдәбияты үсешенә зур өлеш кертә. Аның әсәрләрендәкүтәрелгән төп проблемалар үз укучысын таба.

Әдипнең күңелендә еллар буе җыелган каршылыклы хисләр – гарьләнү һәм әрнү, мәхәббәт һәм нәфрәтнең тәмам тулышып, ташкындай ургылып чыккан әсәре ул – «Гомер ике килми» романы. Китап язарга материал җыйганда, яшь әдип әтисе үткән юлларны барлый, әтисенең – совет хакимияте өчен тир һәм кан түгеп көрәшкән, колхозлар оештыруда активлык күрсәткән, сабыйларны белемле итү өчен тырышкан укытучының,

коммунистның чыннан да бернинди гөнаһсызга кулга алынганына, бинахак атылганына үзе инана. Ул нинди генә җан өшеткеч фактларга юлыкмый! Үзе кичергәннәре дә азмы! Автобиографик планда язылган һәм гыйбрәтле язмышларны, тормышның катлаулы, четрекле якларын психологизм алымнары белән сурәтләгән «Гомер ике килми» романында авторның бөтен эрудициясе, тел байлыгы, галимлеге, Нократ сөйләменең үзенчәлекләре гаять тулы чагылыш таба.

Эдуард Касыймов Казан университетының тарих-филология факультеты студенты чорында ук кешеләр белән мөлаем сөйләшә белү, тиз арада дуслашып китә алуы, иптәшләренең хәленә керә белүе, эчкерсез гадилеге, тыйнаклыгы һәм гаять активлыгы белән күзгә ташланып, дусларының күңеленә кереп кала.

Университетны уңышлы тәмамлагач, Э.Касыймов берничә ел туган ягы Нократ буйларында мәктәптә укыта. Аннары Татарстан радиосында хәбәрче булып эшләп ала, аннары аспирантурага укырга керә. Монда ул фольклор өйрәнә, халык иҗатының чын җәүһәрләре белән җентекләп таныша. Менә кайлардан ала язучы тормыш чын барлыгын! Фольклор экспедицияләре биргән бай материалга таянып, язучы «Кояш көндә чыга» повестен яза. Тумыштан сукыр кеше язмышының аянычлары, гаять авыр хәләте, аңа төрле кешеләрнең төрлечә мөнәсәбәте һәм чын дусларының ярдәме белән, ниһаять, күзе ачылуы – болар һәммәсе дә әсәрдә ышандыргыч итеп сурәтләнгән. Автор кешеләрнең үзара мөнәсәбәтенең ни дәрәҗәдә саф һәм ярдәмчел булырга тиешлеге проблемасын алга китереп куя. Проблема тумыштан сукыр Абдулла образы ярдәмендә чишелә. Барлык геройлар да Абдулланың кимчелегенә карамыйча, аны бик хөрмәтләп, яратып яши. Абдуллага ярдәм итәргә, аны терелтергә ниятлиләр. Повестьта саф һәм ярдәмчел мөнәсәбәтләр өскә чыга – нәтиҗәдә Абдулла күрә башлый, дөньяның матурлыгына, гүзәллегенә шаһит була. Әдипнең сафлык, ярдәмчеллек проблемасы бүген дә актуаль. Бүген дә Абдулла кебек тумыштан сукыр кешеләр бар, аларга ярдәм кулы сузу ихтыяҗы да җитәрлек.

Касыймов гаиләсе белән Алабугага күченергә дә өлгерә. Анда ул җирле халыкның яшәешен-көнкүрешен өйрәнә, янәшәдә генә урнашкан Бондюг химиклары белән якыннан аралаша, педагогия институтында лекцияләр укый – нәтиҗәдә «Томан аша», «Һаваларда тургай» роман-дилогиясе барлыкка килә. Янында гына ГЭС, автогигант калка башлаганда, анда бөтен илдән яшьләр җыелганда, бу төбәк тормышның иң кайнап торган җиренә әверелгәндә, ничек тыныч яшәп ятарга була! Каләм әһелләреннән беренчеләрдән булып Э.Касыймов шунда



күчеп төпләнә. Инде бай тәҗрибә туплаган язучы, төбәктәге халыкны борчыган мәсьәләләр белән күбрәк кызыксына. Шуңа бәйле проблемаларны ул җентекләп өйрәнә. Аларны хәл итү өчен кайгыртып, матбугатта публицистик әсәрләр яза. Бу елларда Э.Касыймовның әле телгә алган романнары рәтендә «Бир кулыңны, дустым!», «Көмеш язулы кылыч», «Сорбонна профессоры һәм без» повестьлары да басылып чыга.

«Сорбонна профессоры һәм без» повесте документаль нигезгә корылган: авторның яшь чагы, университет еллары... Үзәктә профессор Одинцов образы. Дөнья күләмендә танылган зур галим. Ләкин ул гаять катлаулы һәм драматик язмыш кичергән. Әсәрдә вамында вакыйгадан вакыйгага аның бик күп күркәм сыйфатлары: зур эрудицияле галим булуы өстенә үтә нечкә күңелле, йомшак табигатьле олы галим үз язмышында, юк, сөйгән ватаны һәм бөтен дөнья язмышында иң куркыныч, иң хәтәр чакны – фашизм дәһшәте алдында бил бөкми, баш ими, алайгынамы, көрәш юлына басып, зур фаҗигаләр кичерә... Андый кешегә чиксез ихтираму янмыйча буламы соң! Повестьтә профессор белән бергә бүтән геройларның да, аеруча студент Рифкатьнең кешелек сыйфатлары ачылганнан-ачыла бара, карашларыныгый, характерлары чыныга. Әсәр профессорның үлеме белән тәмамланса да кешенең сынмас ихтыярына, аның рухи бөеклеге генә үзенә бер мәдхия булыпяң гырый.

Чаллыда яшәү чоры Э.Касыймовның иҗатын документаль әсәрләргә баета. Байтак кына очерк, кыска хикәя, мәкаләләр язып бастыра. 1979 елда аның «Советская Россия» нәшриятында Кама буе нефтьчеләренә багышланган «На Каме-реке» дигән очерклар китабы дөнья күрә.

Э.Касыймовның «Көмеш язулы кылыч» повесте, әдәби зәвык, тирән психология белән язылганга, күңелләрне тирәнтен дулкынландыра. Анда кешенең батырлыгы мәсьәләсе күтәрелә, героеның ватанны саклап калу бәрабәренә күргән җәфа, авырлыклары тормышчан чагылдырыла. Проблема Гыйлаҗ агай образы аркылы чишелә. Агай туры мәгънәсендә телсез: улы ипи тотып ант итеп сөйләвенә караганда, әтисенең телен, әсирлеккә эләккәч, сер бирмәгәне өчен явыз дошманнар кисеп алган, бөтенләй сөйләшә алмый... Мондый «кимчелекле» геройга укучы игътибарын юнәлтер өчен «кылыч сюжетын» тәкъдим итә: ватанны саклаганда чиккән җәфалары өчен Гыйлаҗ агай кылыч белән бүләкләнгән икән. Әлеге проблема – Ватанны саклау бәрабәренә үзеңне корбан итү – хәзер дә вакытлы һәм урынлы. Бүген дә илебезне дошманнардан саклау ихтыяҗы көн кадагыннан төшмәгән.

«Бир кулыңны, дустым» повестендә Эдуард Касыймов яшьләр мәсьәләсен күтәрә. Әлбинә Әхсән исемле егетне ярата, ләкин алдана. Егет аны авырлы килеш ташлый. Әлбинәгә дуслары ярдәмгә килә. Әйтик, Роберт аны электән үк яратып йөргән икән – хәзер инде авылга барып, аның «ире» дип белдерә. Минемчә, автор бу әсәрендә яшьләрне ялгышлыклар ясамаска икәнен кисәтә, якын дусларның нинди булырга тиешлеген тасвирлый. Биредәге вакыйгалардан бүген дә гыйбрәт алырга була. Шулай да кызлар уяурак булсын, беркатлы булмасын, дусларың тугры була белсеннәр, дигән теләкне җиткерә язучы.

«Чулман – оныклар дәрьясы» дилогиясендә («Томан аша» һәм «Һаваларда тургай» романнарында) тарих белән бүгенге көннең бәйләнеше өлкән буын белән яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә, әсәр геройларының гыйбрәтле язмышларында бирелә. Нәселдән-нәселгә күчә килгән эшче горурлыгы, беренче чиратта завод язмышын кайгырту, аның мәнфәгатьләре белән яшәү, кеше тормышының зурлыгын, әһәмиятен эшкә мөнәсәбәт белән үлчәп карау – өлкән буынга хас төп сыйфатлар шулар. Закир карт, Тиунов, Григорий Афанасыч, Мирыч кебек геройларның тамырлары, гомерләре, язмышлары шушы завод белән бәйләнгән.Госман, Рива, Рәшит, Марс, Фуат, Зөлфә, Асияләр – яшь буын вәкилләре. Алар – аң-белемле, фән-техника белән коралланган кешеләр. Аларның характеры, тормышка мөнәсәбәтләре дә катлаулырак, омтылышлары һәм максатлары да зуррак.

Картлар үз тәҗрибәләре, акыллары белән яшьләргә һәрвакыт ярдәмгә киләләр. Закир карт Фуатның эшчеләр династиясенә лаеклы алмаш булуын кайгырта. Үткән тарихны кадерләп саклау, заводның үз музеен төзү, Революция тавындагы туганнар каберлегенә койма тоту кебек эшләрне дә башлап ветераннар күтәреп чыга. Романның төп герое Госман аерым цехларның технологиясен үзгәртеп кору эшенә тотынгач, пенсионер карт Муралев аңа зур ярдәм күрсәтә.

Э. Касыймовның «Чулман – оныклар дәрьясы» дилогиясендә тормыш мәгънәсе турында, узганнардан мирас итеп нәрсә алынган һәм киләчәк буынга нәрсә калдырыла, «кем ул кеше – тудыручы, барлыкка китерүче, булдыручымы, әллә тарих корбанымы», – әнә шулар турында фәлсәфи фикер йөртә автор.

Эдуард Касыймов иң катлаулы проблемаларны чишү юлларын тасвирлауга да кыю алынган, бүгенге буын укучыларга да тәэсир итәрлек итеп тасвирлауга ирешкән.



Язучының иҗат мирасы шактый күләмле. Укыган һәрбер әсәр хәтергә уелып кала. Чөнки аның һәр китабындагы төп геройлар, нәкъ тормыштагыча, каршылыклы булса да, күпчелеге татар җанлы – әдәпле вә итәгатьле кешеләр. Алар бүтәннәр хакына кереп, рәнҗетеп, үзләренә күбрәк мал төшерергә, җылырак фатирны, майлырак калҗаны эләктереп калырга ашыкмый, берәүгә дә этлек эшләргә, кемгәдер явызлык кылырга атлыгып тормый, чөнки андый максат аларның холкы-табигатенә туры килми.

Э.Касыймов көчле кешеләр, үзләренә ияртерлек, соклангыч кешеләр турында яза. Көчле кешеләр. Кемнәр алар? Сабыйларча ышанучан һәм самими күңелле профессор Одинцовмы? Бәлки «Ади-ади» кушаматлы телсез Гыйлаҗдыр? Яисә алданган кыз Әлбинәме? Болар һич тә без күз алдына китергән, тормышта күреп күнеккән көчле кешеләргә охшамаган бит. Әмма повестьләрне укып, алардагы вакыйгаларны күңелең аша кичергәннән соң, язучының үз геройларына карата булган җылы мөнәсәбәте әкренләп сиңа да күчә, уйларың үзгәрә. Әйе, алар көчле. Язучы аларны шуңа ышандырырлык итеп тасвирлый алган.

Э.Касыймов әсәрләрендә табигать күренешләренә аларның кешегә тәэсир итү очракларына зур урын бирелә. Персонажларның бөтен халәте диярлек табигатьтән аерылгысыз. Табигать күренешләре әдәби әсәрдә хәбәр җиткерү бурычын да башкара ала. Алар вакыйганың нинди төбәктә, кайсы тирәлектә баруын искәртәләр, җирле колоритны сиздерәләр.

Э.Касыймов бу сәнгати закончалыкны төгәл үти. Аның һәр әсәрендә төп герой табигать белән турыдан-туры мөнәсәбәттә: кеше аның йогынтысында яши, табигать аны сыный да. Геройның хис-тойгылары табигать күренешләре белән аерылгысыз үрелеп бара. Пейзаж әсәрдә характерның проблеманы чишү белән бәйле катлаулы халәтен ачыграк күрсәтергә дә, аны яхшырак аңларга да ярдәм итә. Сүз белән әйтеп җиткерә алмаганны табигать күренеше, пейзаж ачык итеп, өстәмә чара буларак та күрсәтә ала. Халык иҗатына якын, аны яхшы белгән иҗатчылар, гадәттә, табигатькә дә якын була икән. Эдуард Касыймовның пейзаж, табигать күренешләрен тасвирлау остасы булуын шуның белән дә аңлатып буладыр.

Әдипнең гомере 1986 елның 21 мартында чишмә юлында өзелә. Чишмә – әдәбиятта да мәңгелек шигъри-романтик образ. Эдуард Касыймовның йөрәге, шул рәвешле, чишмә типкән урында туктавы да үзенә күрә бик мәгънәле-символик образ булып кабул ителә. Аның әсәрләре дә халык күңелендә туктаусыз чылтырап торыр, дип ышанырга кирәк.

Автор мәхәббәтнең кадерен белергә, гомерләрнең бик тиз узуы турында уйланырга чакыра. Кешеләр арасында булган битарафлык, ваемсызлык, игътибарсызлык аркасында җаннарның бик тиз җәрәхәтләнүенә әрнеп сызлана... ...Кыскасы, Эдуард Касыймовның кайсы гына әсәрләрен алып карасаң да, аларда халыкның үзеннән алынган детальләр, күренешләр, вакыйгалар, гыйбарәләр... Халык педагогикасы, халык эстетикасы, халык фәлсәфәсе... Аларда язучының уйланулары, борчылулары...

Язучы иҗаты – әле тирәнтен өйрәнелмәгән хәзинә. Язучының иҗаты дәреслекләрдә аз урын алган, кызыклы әсәрләрен дәреслекләрдә күбрәк күрсәк, мин бик шат булыр идем. Кешеләргә изгелек эшләү, мәрхәмәт күрсәтү, кыйбладан тайпылмау, хыянәт юлына басмау, саф һәм ярдәмчел мөнәсәбәтләр булдыру һ.б. –бүгенге тормышта актуаль проблемалар турында язган әсәрләр булганда, безнең кебек яшьләр шул әсәрләр белән танышып барганда, безнең күңелләребезгә караңгылык, билгесезлек, явызлык урнашмас дип уйлыйм мин.

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Бәшәр, Р. Гомер ике килми шул / Р.Бәшәр // Мәдәни җомга. – 2005. – 11 нояб.
2. Вәли, Р. Гомер икекилми / Р.Вәли // Шәһри Казан. – 2000. – 1 нояб.
3. Гыйззәтуллин, Н. Эдуард дустымхатлары / Н.Гыйззәтуллин // Мәдәниҗомга. – 2001. – №13 (март).
4. Касыймов, Э. Кызыл маяклар: хикәяләр / Э.Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.
5. Касыймов, Э. Кояш көн дә чыга: повесть / Э.Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. – 199б.
6. Касыймов, Э. Гомер ике килми: роман / Э.Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – 303б.
7. Касыймов, Э. Кул малае: хикәяләр / Э.Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. – 107б.
8. Касыймов, Э. Томан аша: роман / Э.Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – 251б.
9. Касыймов, Э. Бир кулыңны, дустым!: повесть һәм хикәяләр / Э.Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. – 219б.
10. Касыймов, Э. Сорбонна профессоры һәм без: повесть / Э.Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 112б.
11. Касыймов, Э. Һаваларда тургай: роман / Э.Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. – 327б.
12. Касимов, Э. На Каме-реке: очерки о нефтяниках / Э.Касимов. – М.: Сов. Россия, 1979. – 77с.
13. Касыймов, Э. Повестьлар / ахыргы мәкалә авт. Р.Мостафин / Э.Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 368б.
14. Касыймов, Э. Чулман – оныклар дәрьясы: роман-дилогия/ Э.Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 496б.
15. Касыймов, Э. Шиңмәсен гөлләрең: роман / Э.Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 479б.
16. Касыймов, Э. Живой памятник: рассказы для детей / сост. и пер. с татар. М.Сафина / Э.Касыймов. – Наб. Челны: КамАЗ, 1995. – 32с.
17. Сафин, Ф. Еллар яктысы / Ф.Сафин // Казан утлары. – 1980. – №11. – 161-162б.
18. Сафин, М. Эдуард Касыймов / М.Сафин // Фән һәм мәктәп. – 1997. – №3. – Б.109-113.
19. Сибат, Р. Нократның чын татары / Р.Сибат // Ватаным Татарстан. – 2000. – 15 нояб.
20. Харисова, Г. Үткәннәргә илтифат / Г.Харисова // Мәйдан. – 2004. – №9. – Б.94-102.



***Алия ГАРИФУЛЛИНА,***
*Яр Чаллы шәһәренең*
*муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе*
*«35 нче гомуми белем бирү мәктәбе»*
*6 нчы сыйныф укучысы.*
*Җитәкчесе татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Сәлимгәрәева Л.И.*


## «ТУРГАЙ НӘРСӘ ДИП ҖЫРЛЫЙ?» (Фоат Садриев, Ибраһим Гази иҗатына нигезләнеп)

Туган ил, туган жир, туган төбәк. Кайсы гына язучы бу темага әсәр иҗат итмәгән дә, кемнәр генә туган җирнең газизлеген тоймаган?!

Бишенче сыйныфта укыганда язучы Фоат Садриевның «Тургай ни дип җырлый?» хикәясен укыдык һәм укытучыбыз безгә башка әдипләрнең дә тургайлар турында язылган шигырь-хикәяләре булуы турында сөйләде. Ә өй эшенә шул әсәрләрнең берәрсе белән танышып килергә диде. Эзли торгач, мин Ибраһим Газиның «Кояш артыннан киткән тургай» хикәясен таптым. Миңа бу ике хикәя дә ошады, мин аларда уртак яклар күрдем.

Хикәяләрнең икесе дә туган җир турында. Аларда кеше өчен бик кадерле булган туган якның матурлыгы темасы яктырыла, кабатланмас мизгелләрнең гүзәллеге тасвирлана. Бу гүзәллек тавышлар гармониясе аша җиткерелә.

Ибраһим Газиның «Кояш артыннан киткән тургай» хикәясендә хикәяләүче – өлкән яшьтәге кеше, туган-үскән авылын сагынып кунакка кайткан. Ул үзенең күңеленә кереп калган урыннар буйлап йөри, Олы күлгә бара, малай чакта йөгереп йөргән җирләрендә уйланып утыра, тургайларны күзәтә.Ә Фоат Садриевның «Тургай ни дип җырлый?» хикәясендә Нәсимә, көл салган чиләген чанага утыртып, басуга китә. Анда ул һавадагы тургай җырын тыңлый. Хикәяләрдә авторлар вакыйга сөйләми, ә берничә җөмләдә генә хәбәр итеп куя.

Алга таба без геройның хис-халәтләрен тургай тавышы аша тоябыз. Моның өчен авторлар тел чараларыннан даоста файдаланалар.

И.Гази тургай сайравын «гөрләшәләр», «моң», «колак төбендә челтер-челтер, турый-турый, яй-яй», «моңлы җырлары... җиргә төшеп китә», «тавышы челтерәп агып тора» – дип бирсә.

Ф.Садриев «һавада җырлаган тавыш ишетелә», «көмеш кыңгыраулар чылтырый», «өздереп-өздереп сайрый», «сихри моң», «җыры моңлыйде, күңелләрне кузгатырлык дәртле иде» дип сурәтли.

Хикәяләрдә шушы кечкенә генә кошлар сихри моңнары белән күңелләрне әсир итә. Беренче хикәяләүче туган җирен сагынуын җиргә ятып күзәтсә, икенчесендә Нәсимә тургай сайравыннан туган җирнең беренче аяк баскан кара туфрак, беренче күз салган урын, зәңгәр күк, ак болытлар, җылы кояш, көмеш ай, яшел хәтфә булып җәелеп яткан чәчәкле болын, аллы-гөлле чәчәкләр икәнен аңлый.

Күрәбез: автор, геройның халәтен бирү өчен, төсләр белән дә оста файдалана. Ибраһим Газиның «Кояш артыннан киткән тургай» хикәясендә ашлыклар күкрәп үсеп утырган, кызарып җиләк пешкән чак сурәтләнә. Көн шундый кызу, хәтта тузанның кайнарлыгы аяк киеменең табаны аша сизелә, әйтерсең туган якны ярату хисе шулкадәр кайнар. «Күк йөзе зәп-зәңгәр, яп-якты. Ә болытлар кып-кызыл... Баягынак кар тауларыдай өелеп торган ак болытларга кинәт ут капты, болытлар ялкынланып яналар», – дип тасвирлый автор. Шулай итеп, автор, ярату хисенең кешегә табигатьтән күчкән байлык икәнен раслый.

Хикәяләрдә тирә-юнь кешенең кәефе, мөнәсәбәте аша тасвирлана, вакыйга ниндидер серле, сихри бер нур белән өртелә.

Фоат Садриев хикәяләрендә туган як табигате нечкә зәвыклы, матурлыкны аңлый белүче кеше (хикәяләүче һәм Нәсимә) күзләре аша тасвирлана; сурәтләү объекты булып хәрәкәттәге мизгел матурлыгы тора; сүзләр сайланышы ярдәмендә көй-халәт тудырыла. Шушы үзенчәлекләрдән чыгып, «Кояш артыннан киткән тургай» (И.Гази), «Тургай ни дип җырлый?» (Ф.Садриев) хикәяләрендә авторлар кеше психологиясен ачуда табигать мизгелләрен оста кулланган, дип нәтиҗә ясыйбыз.

Фоат Садриев балалар күңеленә туган җирне ярату орлыкларын кечкенәдән сала. Якташ язучыбыз Фоат Садриев әсәрләре әдәбиятыбызда тургай җыры булып яңгырасын.

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Гази, И. Әсәрләр: 1 том / төз. Ф. Миңнуллин / И. Гази. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 520 б.
3. Курбатов, Х. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х. Курбатов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.
4. Садриев, Ф. Аппаккай: балалар өчен хикәяләр, әкиятләр һәм сәхнә уеннары / Ф. Садриев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 95 б.



***Әлфия БАДРТДИНОВА,***

*Муса Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсенең*

*абонемент бүлеге мөдире*


## ЯМАШ ИГӘНӘЙНЕҢ «СӘФӘР ЧЫГАМ» ШИГЫРЬЛӘР ҖЫЕНТЫГЫНДА КУЗГАТЫЛГАН ТЕМАЛАР

*Ул – тургайлар нәселеннән иде,*
*Моңнар сирпеп очты йөрәге.*
*Җан өшеткеч заман җилләрендә*
*Ил – милләтнең булды терәге.*

*Ул айкады тормыш галәмнәрен,*
*Бәхет эзләп туган халкына.*
*Күңелләрдә аның шигырьләре*
*Былбыллардай әл дә талпына.*

*Мансур Сафин*

Әлеге сүзләр шагыйрь һәм журналист Ямаш Игәнәй турында яңгырый. Ул әдәбият дөньясына XX гасыр ахырында килеп керә.

Ямаш Игәнәй (аның тулы исеме Ананий Нестерович Малов) – шагыйрь һәм журналист. Ул Татарстанның Сарман районы Ләке авылында 1938 елның 10 гыйнварда дөньяга килә. 1955 елда ул Сарман урта мәктәбендә белем ала, аннан Лубян урман хуҗалыгы техникумына укырга керә. Анда өч ел буе белем ала һәм 1958 елда аны тәмамлап, Башкортстан якларына эш эзләп китә. Берничә вакыт әлеге төбәктә үз белеме буенча эшли һәм Совет Армиясе сафларына хезмәткә чакырыла. Ике ел Армиядә хезмәт итеп кайткач, үз районында Рантамак һәм Азалак авылы мәктәпләрендә балалар укыта, бер үк вакытта Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә читтән торып укый башлый. Анда ул журналистика һөнәренең нигезләрен өйрәнә. Әлеге белем һәм журналист һөнәре аны укытучы хезмәтеннән азат итә, һәм шул рәвешле ул 1965-1978 нче елларда Баулы, Мамадыш район газеталарында эшләргә алына.

КамАЗның кайнар төзелеш чорында ул Чаллыга күченеп килә. Монда татар телендә чыгып килүче «Кама таңнары» газетасында тәрҗемәче булып эшкә урнаша. Аннары, берничә ел Чаллы ит комбинатында инженер булып эшли. Бу вакытта ул тыныч кына ятмый, куен дәфтәренә тирә-яктагы күренешкә, күңел кичерешләренә карата үз каләмен тибрәтергә ашыга. Соңрак, әлеге җыелмаларны барсын да бергә туплап, нәшриятка тапшыра. Нәтиҗәдә, 1981 елда Татарстан китап нәшриятендә аның беренче китабы – «Сәфәр чыгам» шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Ул анда үзенең чын исемен куймый, туган авылының бер кыйпылчыгы халык теленә керсен дигән теләктә, Ләке авылы яныннан агып узган Иганә елгасының исемен, үзенә псевдоним итеп ала. Соңга таба әлеге елга исеме Ананий Маловның әдәби псевдонимына әверелә. Шуннан бирле ул халыкка Ямаш Игәнәй исеме астында таныла башлый.

«Сәфәр чыгам» шигырьләр җыентыгы Ямаш Игәнәйне тулысынча әдәбият дөньясына алып керүче, беренче адымы була. Ә инде 1982 елда аны СССР Язучылар Союзына әгъза итеп кабул итәләр.

Ямаш Игәнәйнең «Сәфәр чыгам» шигырьләр җыентыгын тематика ягыннан өйрәнгәндә, монда алдагы темаларны ачыклап үтәргә мөмкин.

**1. Чаллы шәһәре һәм КамАЗ тормышы**

Ямаш Игәнәй Чаллы якларында, Кама автомобиль гигантын төзүче һәм Яңа ак шәһәр салучылар арасында, шул гүзәл якта яшәүче һәм шул заводларда эшләүче замандашлар арасында



торып иҗат итә. Шуңа да инде табигый ки, аның шигырьләрендә дә Чаллы ритмы, Чаллы рухы киң чагылыш таба.

*Менә шушы якка таба*
*Барам мин, барасы бар:*
*Әнә шул офык ташыннан*
*Бер кала саласы бар!*

*Менә шушы якка таба*
*Барам мин, барасы бар:*
*Яшен чаткысын яшьлеккә*
*Өләшә аласы бар!*

Ямаш Игәнәй, КамАЗ һәм Чаллы сүзләренең ил күләмендә зур яңгырашка ия булуын тоемлап, шулар белән кирәкле-кирәксезгә сөрән салып, актуальлеккә омтылучы шагыйрь түгел. Ул “тыйнак һәм сабыр холыклы» автор. Ләкин шул ук вакытта, ул шигырьләрендә якташларының олы максатлыгын, шул максатларга ирешү юлында ныклы характерга ия булуларын түкми-чәчми җиткерергә омтыла:

*Әллә нинди сәер Ут-кешеләр*
*Гәҗәеп эшләр кыла монда, хәтәр.*
*Һәр мизгелгә… мәңгелеккә уя –*
*Һәйкәл булып туа яңа шәһәр.*

Чаллы тематикасына кагылышлы тагы ике шигырьне атарга була: «Таң шәһәре монологы», «Кырмыскалар». Беренче шигырьдә Ямаш Игәнәй әлеге шәһәрне төзүчеләргә дан җырлый, аларның батыр хезмәтенә соклана:

*Үзең салдың мине, Кеше,*
*Йөрәгең ялкынында чыныктырган*
*Офык-таштан, Таң ташыннан.*
*Шуңа исемем – Ак кала.*
*Менә хәзер Вакыт атлы дәрьяда мин,*
*Гомереңә, яшәвеңә һәйкәл булып,*
*Йөзеп барам кораб сыман*
*Мәңгелеккә таба…*

Ямаш Игәнәй замандашларының тырыш хезмәтен, булдыклы, эшчән халык икәнлекләрен «Кырмыскалар» шигырьендә дә ачык чагылдыра:

*Нинди көчле, нинди тырыш алар!*
*Әкият белән чынны бергә куйсаң –*
*Чын могҗиза үзе менә кайда!*
*Син зиһенең җыеп өлгергәнче –*
*Ялан кырда гигант шәһәр калка.*

Әлеге җыентыкка карата әдәби тәнкыйть мәкаләсендә, филология фәннәре кандидаты Әнвәр Шәрипов: «Шуның белән бергә, әлеге китапка КамАЗ темасы тирән һәм купкырлы чагылыш тапкан, дип әйтеп булмый әле. Бүгенге укучы Ямаш Игәнәйдән – үзен Брежнев шәһәрендә яшәп, КамАЗда эшли торган шагыйрьдән – әлеге теманы тагын да тулырак һәм тирәнрәк чагылдырган яңадан-яңа әсәрләр көтергә хаклы», – ди.

Алдагы елларда Ямаш Игәнәй кайбер тәнкыйтьләрне истә тотып, үзенең иҗатында әлеге тематиканы дәвам итә һәм аны эчтәлеге яңыннан баета. Мисал итеп «Яшьлек авазы» шигырен атарга була.

*Күкләрдән иңгән түгел бу,*
*Күкрәүдән килгән хәбәр.*
*Бүгенгә бездән һәйкәл ич*
*Үзебез төзегән КамАЗ,*
*Үзебез салган шәһәр!*

**2. Хезмәт тематикасы**

КамАЗ тематикасына тыгыз бәйләнештә һәм аның җирлегендә туган хезмәт тематикасын аерым карау, бу юнәлештәге шигырьләрне бер җепселгә тезү өчен уңайлы булыр. Әлеге бүлеккә «Игенче монологы», «Сабан монологы», «Нигәдер бу Чаллы күңелгә” кебек шигырьләрне кертергә була. Билгеле бер хезмәт хакында язылган шигырьләр дә бар. Алар арасында игенчеләр хезмәтен билгеләп үтергә була. Игенчеләр хезмәтенә багышлап язылган «Игенче монологы», «Кояш та ипигә охшаган», «Сабан монологы» кебек шигырьләр авторның уңышы булып санала.

Ә инде хезмәт темасының югары ноктасы бигрәк тә «Кырмыскалар» дигән шигырьдә күренә.

*Әнә берсе йөк күтәреп менә,*
*Тырыша-тырыша берәү балка тарта.*
*Карап торган менә шушы мәлдә*
*Болытларга тияр зур йорт калка.*



*Чал тауларны күчереп куя, әгәр*
*Бөтенесе бердәм тотынсалар!..*
*Өрсәң хәтта очып китәр төсле*
*Үзләре дә... әллә корыч алар?*

Монда ике тематиканың киселеш ноктасы да чагыла. Берсе – хезмәт, икенчесе – КамАЗ. Хезмәт темасы дип, юллар чатына чыгып яисә завод түбәләренә менеп уйлану, чаң кагу түгел бу. Боларның барысын күреп һәм үз җилкәсендә татып караган шәхеснең бераз читкә китеп, табигатьнең тыныч бер почмагында бер ялгызы калып хисләре белән уртаклашуы сыман.

Ләкин әлеге җыентыкта төгәл генә, ачыктан-ачык хезмәт темасына карата шигырьләр бик аз.

**3. Туган як тематикасы**

Беренче чиратта, шагыйрьне туган авылы, кырлары, дулкынланып торган арыш-бодай басулары сокландыра. Ул аларны рухланып тасвирлый.

*Кырык эшен ташлап,*
*Каршыма Кыр чыга.*
*Назланып һәм назлап,*
*Кочагыма чума.*

Шулай ук бу күренешне авыл кешеләренең мактаулы хезмәтләре белән органик рәвештә бәйләп тә бирә. «Бер трактор кырда җир сөрә... «шигырьендә, мәсәлән шагыйрь менә нинди күренеш тудыра:

*Офык чите. Тракторны кара:*
*Кояш уртасына кереп бара...*

Туган як темасы күбрәк авыл табигатенә булган мәхәббәт аркылы да тасвирлана.

*Уклар атып күк дөберди-яңгыр коя,*
*Гаскәр кебек горур басып тора урман.*
*Бар агачлар ботакларын күккә сузган –*
*Тоткан гүя җибәрмәскә болыт читен –*
*Туган җиргә күбрәк яусын, дигән сыман.*

Ямаш Игәнәй авылга булган хисен, тойгыларын, андагы күренешләрнең нечкәлекләре аша чагыштытып күрсәтергә омтыла.

*Һаваларда җылы якка*
*Китеп барган кошлар күче,*
*Тын итеп аяк астыма*
*Алтын тәңкә – яфрак төште.*
*Урамнарда – таба исе –*
*Кияү коймаклары пеште,*
*Нәкъ алтынсу яфрак төсле...*

Әлеге тематикага кагылган шигырьләр арасында авыл рухы, авыл һавасы һәм аның табигате бик үзенчәлекле урынны били.

**4. Балачак тематикасы**

Ямаш Игәнәй гомеренең өлгерлек чорында үзенең үткәнен, балачагын сагына. Һәм ул аның шигырьләрендә бик ачык чагылыш таба:

*Малай чакта тайлар көтә идем*
*Әрәмәдә, Ышна буенда.*
*Иярләгән акбүз аргамагым*
*Утлап йөрер иде болында...*

*Томырылып бер әйләним әле*
*Әнә теге офык турыннан, -*
*Диде язмыш, ярсу аргамагым*
*Алып киткән чакта кулымнан.*

*Кая инде ул әйләнеп килү...*
*Юкка гына булды көтүем.*
*Йөрәгемне ташка уя ул*
*Эзләп йөрим тайлар көтүен...*

Җыентыкны тулаем алганда, менә шундый тематикаларга тукталырга була. Китапта шигырьләрнең шактый өлешен кечкенә күләмле шигъри парча-миниатюралар да тәшкил итә. Аларда автор тормыш турында, яшәү мәгънәсе, аталар һәм балалар буыны, Җир шары, Галәм турында уйлана. Аның лирик герое бу парчаларда уйчан һәм борчулы, тыйнак һәм күпкырлы тормышның катлаулы мәсьәләләре борчый.

Шулай итеп Ямаш Игәнәй «Сәфәр чыгам» җыентыгына тупланган шигырьләрендә үзәк урынны тормышыбыз, яшәү мәгънәсе турындагы уйланулар алып тора. Күп бизәкле, мавыктыргыч шигъри образлар ярдәмендә укучы биредә кояшлы һәм бәхетле киләчәк белән очраша, тарихи үткәннәргә сәяхәт итә.



Язучы Ямаш Игәнәйнең – «Игелеккә төбәк» (1987), «Мин этигә охшаган» (1990) шигырьләр җыентыклар нәшер ителә. публицистик жанрда язылган «Бәддога» (1994) дигән китабы басылып чыга. Ул 1990-1991 елларның беренче яртысында «Чулман-Идел» (хәзерге көндә «Шәһри Чаллы») газетасында, 1991 елның икенче яртысында гомеренең соңгы көненә кадәр «Аргамак» журналында бүлек мөхәррире вазифасын башкара. 1992 елда Ямаш Игәнәй «Керәшен сүзе» гәзитенә нигез сала һәм аның беренче мөхәррире дә була. 1996 елда балалар өчен шигырьләр язуын дәвам итә һәм «Аргамак» журналында «Ике койрыклы төлке» шигырьләренең циклын бастыра. Шул ук журналда 1998 елны, әлеге тематиканы дәвам итеп, аның истәлегенә багышлап – «Песи нигә тирләми?» дигән балалар өчен шигырьләр җыелмасы басылып чыга. 1997 елда Ямаш Игәнәйгә «Һай бу адәмнәрнең кыйланмышы» исемле цикл өчен Саҗидә Сөләйманова исемендәге бүләк тапшырыла.

Кызганычка каршы ул безнең арадан бик иртә китә.

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Әдәби Чаллы: / [төз.: Р.Хәмидуллина, Ә.Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 171-173.
2. Игәнәй, Я. Сәфәр чыгам: шигырьләр / Я. Игәнәй, – Казан.: Татар. кит. нәшр., 1981. – 127 б.
3. Шәрипов, Ә. Нурлар өләшә шагыйрь / Ә. Шәрипов // Идел. – 1983. – №15. – Б. 87-89.



***Эльвина ЗАКИРОВА,***
*Чаллы шәһәренең муниципаль*
*гомуми белем бирү учреждениесе*
*«27 нче гомуми белем бирү мәктәбе»*
*10 нчы сыйныф укучысы.*
*Җитәкчесе Миннегалиева Л. С.*


## РАЗИЛ ВӘЛИЕВ – ҖЫРЧЫ ШАГЫЙРЬ

Разил Исмәгыйль улы Вәлиев 1947 елның 4 гыйнварында Татарстанның Тәбән Кама районы Ташлык авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне туган авылында алганнан соң, Шәңгәлчек, Түбән Каманың беренче мәктәпләрендә укый.

Разил Вәлиев кечкенәдән үк әдәбиятка гашыйк кеше. Башлангыч мәктәптә укыганда ук шигырьләр, хикәяләр иҗат итә. Үзенең иң беренче иҗат мәктәбе дип Чаллы район газетасы каршында эшләүче әдәби түгәрәккә йөргән елларын саный. Ул 1960-1965 елларда бу түгәрәктә чыныгу узган Мөдәррис Әгъләмов, Хәниф Хөснуллиннар белән аралашып, бер шигъри казанда кайнап яши.

Р.Вәлиев мәктәпне тәмамлагач Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга кирә. Ләкин күңеле каядыр талпына, нindидер яңалык эзли. Һәм ул икенче курста укып йөргән җиреннән университетны ташлый да, Мәскәүнең Максим Горький исемендәге Әдәбият институтына яңадан беренче курска бара.

Разил Вәлиевнең иҗаты Чаллы белән дә бәйләнгән. Чаллыда Язучылар оешмасы ачылгач, ул Э.Касыймовтан соң аның җитәкчесе итеп билгеләнә, һәм 1981-1984 елларда җитәкчелек итә.

Разил Вәлиевне бүген дә Чаллының әдәбият сөючеләре сагынып искә алалар. Ул эшләгән дүрт ел эчендә Чаллы Язучылар оешмасы ныклап аякка баса, монда яшәүче әдипләрнең дистәләгән китабы дөнья күрә, шәһәрдә һәм тирә-яктагы авылларда атна саен гөрләтеп әдәби кичәләр үткәрелә, ил күләмендә иҗади бәйгеләр, форумнар уздырыла. Чаллыда Разил җәмәгать эшлеклесе буларак та таныла. Монда эшләгәндә аны СССР Язучылар союзы идарәсенә әгъза итеп сайлыйлар, ә Чаллы сайлаучылары аңа шәһәр Советы депутаты мандатын ышанып тапшыралар.

Әдәбият институтында Разил Вәлиевнең киләчәк иҗатына юнәлеш бирүче кешеләрнең берсе атаклы шагыйрь Лев Ошанин була. Бөтен дөньяга танылган җырлар авторы белән биш ел буена аралашып иҗади бәйләнештә яшәү эзсез калмый. Разил Вәлиев үзе дә җырлар яза башлый.

Җыр аның кечкенәдән үк күңеленә кереп калган. Мәктәптә укыганда ул концертлар куеп йөри. Туганнары да җырлы-моңлы кешеләр, үзе дә гармун тартырга өйрәнә. Мәктәптә хорга йөри. Әнисенең үзе чыгарган бәетләрен тыңлап үсә Разил. Ләкин җыр иҗат итү мәсьәләсендә иң зур сабакны Илһам Шакиров бирде дип саный шагыйрь. Бу турыда ул үзенең истәлекләрендә дә әйтә: «Бер алманы бишкә бүләек» җырында «кар аклыгы гөлгә күчкән» диган юл бар иде. И.Шакиров бу шигырьне бик яраткан, тик бер юлының бик үк дөрес түгел, җырлаганда «караклыгы гөлгә күчкән» булып ишетелә» дигәч, «кыш аклыгы гөлгә күчкән" дип үзгәрттек. Иҗекләр, сүзләр яңгырашында бөтенләй көтелмәгән мәгънә бирә торган очраклар була икән. Илһам абый шулардан арынырга өйрәтте».



Атаклы җырчыбыз белән танышканнан соң, аның киңәше белән «Дулкын», «Таң җыры», «Бер алманы бишкә бүләек» кебек җырлары дөньяга килгәч, Разил Вәлиев җыр дөньясына кереп чума. Бу хакта ул үзенең әбисенә багышлап язган «Дисбе» шигырендә дә әйтеп үтә:

*Иген чәчмим, әби, ачуланма,*
*Бер «җилкуар» шунда, җыр язам.*
*Ә җыр язу шулкадәрле авыр,*
*Җибәрми ул, алса бугаздан.*

Р.Вәлиев җитди эчтәлекле, тормыш фәлсәфәсенә кагылышлы уй-фикерләр белән сугарылган романтик рухлы лирик поэзия тарафдары. Аның традицион халык җырлары рухында язылган бик күп шигырьләре музыкага салынган. Р.Вәлиев халык язмышы өчен янып яшәүче фидакарь язучы. Туган як, туган җир темасы да аның иҗатында кызыл җеп булып сузылган. («Бәхетем башкаласы», «Бер алманы бишкә бүләек», «Сөембикә» h.б.). Ә лирик мәхәббәт җырларында Р.Вәлиев кеше күңеленең иң саф, иң изге хисләрен тирән кичерешләр аша халыкчан моң белән үрелдереп бирә. Саф мәхәббәт, тугрылык, дуслык – аның мәхәббәт җырларының төп идеалы. («Зинһар өчен кермә төшләремә», «Таң җыры», h.б.).

Ничә еллар буена яратып җырлана торган «Ядкарь» җырының язылу тарихы бик кызыклы. Казанда һәр атнаны әдәбият белән кызыксынган яшьләр «Ядкарь» Актерлар йортына җыелып шигырьләр укып, җырлар җырлый торган булалар. Алар арасында Разил Вәлиев та була. Ә беркөнне Разилгә шушы клубның гимны булырдай бер җыр тексты язарга тәкъдим итәләр. Һәм ул тиз арада шигырь язып композитор Фасил Әхмәтовка бирә. Шулай итеп бер атна эчендә «Ядкарь» җыры туа.

«Бүгенге көндә халык күңеленә барып җитим дисәң, иң үтемле жанр – җыр. Җырны машинада да, ашап утырганда да тыңлап була» – дип яза шагыйрь үзенең истәлекләрендә. Чыннан да, Р.Вәлиевның җырлары үзенең тирән эчтәлеге, моңга бай булуы белән халык күңеленә үтеп керә. Яшәргә көч, тәрбия бирә. Р.Вәлиев җырлары туң йөрәклеләрне дә уятып, күзләреннән яшь чыгара.

Язучы, Татарстанның М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Рафаэль Мостафинның сүзләре белән әйтсәк: «Р.Вәлиев җырлары чишмә кебек иркен һәм талгын агышлы. Әйтерсең, алар каләм белән ак кәгазьгә язылмаган, ә йөрәктән саркып чыккан да, күңелләрдән-күңелләргә күчеп, һәркемне үз моңы белән моңландырып йөри. Тынгысыз күңелле, сизгер йөрәкле, олы җанлы шагыйрь генә халык күңеленә барып җитәрлек шундый җырлар иҗат итә ала».

Разил Вәлиев – күпкырлы талант иясе.Ул нинди генә жанрда иҗат итсә дә, һәрберсе югары дәрәҗәдә бәяләнә. Җырлары бүген дә популяр, радио-телевидениедән яңгырап торалар. Р. Вәлиевкә 1982 елда «Яшисе килә» повесте һәм популяр җырлары өчен М. Җәлил исемендәге Республика бүләге, 2007 елда проза әсәрләре җыентыгы һәм 200 ләп җыр кергән «Ядкарь» җырлары китабы өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге тапшырылды.

**ӘДӘБИЯТ:**

1. Журналның шагыйрь Разил Вәлиев иҗатына багышланган махсус саны // Мәйдан. – 2005. – №6.
2. Вәлиев, Р. Ядкарь: шигырьләр, җырлар / Р. Вәлиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.

***Илсияр ГАНЕЕВА,***
*Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының туган якны өйрәнү бүлеге китапханәчесе*

## АЙДАР ХӘЛИМ ИҖАТЫНДА СУГЫШ ТЕМАСЫ

Татар әдәбиятында сугыш темасын чагылдырган әсәрләр бик күп. Сугыш елларындагы ачлык, ялангачлык, сугыш кырларында ятып калган корбаннар, фашистлар тоткынлыгында хурлыклы һәм мәсхәрәле үлемен көткән әсирләр язмышы һәркемне уйланырга мәҗбүр итә. Сугыш темасы чагылган әсәрләрнең күбесе авыл халкы тормышын сурәтләүгә багышланган. Ул елларда кешеләр генә түгел, табигать тә зур югалтуларга дучар булган: урманнар янган, кырлар, таулар теткәләнеп беткән.

Бөек Ватан сугышы, бигрәк тә, проза һәм поэзиядә актив сурәтләнә. Сугыш афәтен кеше күңеленә тирән үтеп керерлек итеп сурәтләп бирү язучы Айдар Хәлимнең иҗатында да зур урын алып тора. Аның гаҗәеп бай рухи дөньясы укучыларны сокландырмый калмыйдыр.

Айдар Хәлимнең сугыш темасына мөрәҗәгать итүе кисәк кенә булмаган. Ул турыдан-туры фронтлардагы сугыш операцияләре турында язмаса да, сугыш темасы аның өчен һич кенә дә яңа түгел. Киресенчә, аның беренче шигырьләре, аеруча чәчмә әсәрләре, башыннан азагына кадәр сугыш ялкыны белән көйдерелгәннәр. Сугышның кайнар тыны Айдар Хәлимнең иҗатының җелеге аша үтә. Ул – сугыш баласы. Моның белән бар нәрсә әйтелгән. Ул туган таңда әтисе фронтка киткән. Өч ай тулганда әнисе аны Абдуллино станциясында фронтка китәргә җыенган эшелонга алып чыгып, әтисенә күрсәтә. Бу аларның беренче һәм соңгы кат очрашуы булган. Паровозның кайнар пар атомнары эчендә очрашу аның сабыйлык аңында мәңгелеккә сугыш ядкяре, сугыш хәтере белән сугарылган. Укучы белә, аның барлык сюжетлары ниндидер тамыр җебе белән барыбер сугышка барып төртелә.

Бөек Ватан сугышы бездән ераклашкан саен, аның кешелек җәмгыятен фашизм афәтеннән коткарудагы әһәмияте арта бара. Сугышның кырыс шартлары гади сугышчыдан алып маршалга кадәр һәркемне кыюлыкта гына түгел, бәлки гаделлектә, хакыйкатьнең йөзенә туры карый алуда да сынады. Берәүләр, аны намус белән үтеп, иле, халкы, үзе каршында батырлык һәм матурлык үрнәге булып танылса, икенчеләр, күбрәк үз мәнфәгатен кайгыртып рухи түбәнлеккә төште. Айдар Халимнең яңа китабы «Татар солдаты» әнә шул турыда. Әлеге роман Рейхстаг гөмбәзенә иң беренчеләрдән булып Җиңү Байрагы кадаган каһарман милләттәшебез Гази Заһитовның тормышын һәм данлы сугышчан юлын сүрәтләүгә багышлаган.

Иҗатында сугыш темасын ачканда да А. Халим «яраткан аты» публицистиканы бөтенләйгә ташлый алмый. Ташлый алмый гына түгел, ул аны еракка атып тидерә торган корал итеп куллана. Ул аны прозасының үтемлелеген көчәйтүгә, сүрәтләнгән вакыйгалар эчендә укучының җанын фактлар белән тетрәндерүгә җигә. Гази Заһитов һәм дусларының сугышчан юлы А. Хәлимнең күптөрле публицистик һәм фәлсәфи уйланулары караш – мөнәсәбәте белән кушылып бара. Автор һәрдаим сугышның ил – халык йөрәгендәге канлы яра булуын, аның миллионнарча кешененең гомерен алып китүен искәртеп бара. Кеше гомере берни белән үлчәнми торган кыйммәт булса да, төрле дәрәҗәдәге командирларның моңа игътибар итмәве, теге яисә бу сугышчан бурычның кирәкмәгән корбаннар хисабына яулануы турында җитди уйлана ул. Публицистик кайнарлык белән язылган юлларда кеше шәхесенең гаять түбән бәяләнүе, шундый ук мөнәсәбәтнең аерым милләтләргә карата булуы ачыла.

Ватан әдәбиятында «Бөек Ватан сугышы» дип исемләнгән сугышның нинди сугыш булуын ачыклау кирәк, дип белдерә автор. Мондый сугышның дөньяны империалистик бүлүдә Сталин, Гитлер кебек авантюристлар өчен бары тик бер спектакль булып хезмәт итүен сызык өстенә ала. Бу Ватан… безнең Ватанмы? Нәрсә ул Ватан? Бу сораулар татар матур әдәбиятында яңа герой концепциясе белән бергә яңа тарихи концепциясен дә алып килә.

Автор шәхес гармониясе – аның Ватанга булган мөнәсәбәте белән билгеләнәчәк, дигән идея үткәрә. Ватаннан Ватанны эзләп табу татар милләтенең гомуммилли һәм гомумкешелек мәгънәсенә әвереләчәк..

Язучының «Җиңелмәс ул чечен» китабы документаль материаллар нигезендә каһарман чечен халкының үз мөстәкыйльлеге өчен хәрби техниканың иң соңгы казанышлары белән коралланган «явызлык империясе»нең миллионлы армиясенә каршы бердәм рәвештә көрәшкә күтәрелүен, аны сугышта җиңеп чыгуын бөтен фаҗигале күренешләре белән күз алдына китереп бастыра. «Империяне үтерергә!» китабында да чечен халкының йөз илле елга сузылган азатлык көрәшенең күп кенә аспектлары яктыртыла.

Айдар Халимнең билгеле шәхесләр турында фикерләре, аларның сугыш мәсьәләләренә булган карашлары бөртерле генә кабул ителми. Әммә ул бу мәсьәләләрдә дә үз стилендә, үз юлында тугры булып кала. Ул укучыны битарафлыктан арынырга, үз хокукыңны, халкың хокукларын яклап көрәшергә чакыра.

Әлеге язмамны мин Айдар Хәлимнең үз сүзләре белән тәмамлыйсым килә: «Сугышның һәм тынычлыкның чырайлары төрле. Аларны бутамаска иде. Сугышның чырае – үлем, аның җанвари ыржаюы куркыныч. Ул йота гына белә. Ул безнең мәхәббәтебезнең гөлсәр вазасын челпәрәмә китерде. Ә безнең җиңүебез алып килгән тынычлыкның йөзе икенче – ул елмаю, тормыш һәм чәчкә аткан гөл. Һәм шул челпәрәмә китерелгән гөлсәрнең яңадан ябыштырылган вазасы. Сугыштан калган сагыш савыты. Яралы эзләрне саклаган савыты. Сугыш – үтерә. Тынычлык – тудыра, үстерә. Менә ни өчен без корбаннарны онытмаска тиешбез. Кайчандыр атаклы совет шагыйрәсе Ольга Берггольц «Беркем дә, бернәрсә дә онытылмады» дигән канатлы гыйбарә ычкындырган иде. Шулай булырга тиеш иде дә бит. Әмма, нишлисең, онытабыз. Күп нәрсәне оныттык та инде. Без сугыш чыраеннан кешелеклелек таләп итә алмасак та, тынычлык чыраеннан моны таләп итәргә бурычлыбыз» дип әйтә ул.

Әйе, әдәбиятыбызда сугыш темасына багышланган әсәрләр бүген дә туып тора. Чөнки теләсә нинди сугыш кешенең табигатенә каршы: анда кан коела, анда кеше гомере өзелә.

Без, сугыш афәтен, аның бөтен фаҗигасен язучыларыбыз, шагыйрьләребез язган әсәрләр аша, бабаларыбыз сөйләгәнне тыңлап кына күз алдына китерәбез. Әмма теләгебез бер: Бөек Ватан сугышы, Әфган, Чечня сугышлары кебек сугышлар безнең тарихта иң соңгы сугышлар булсын иде.



**ӘДӘБИЯТ:**


1. Шагыйрь, әдип, милләт хадиме // Казан утлары. – 2002. – №1. – Б. 82-83.
2. Юныс, М. Бәхетле мескенлек / М. Юныс // Казан утлары. – 2000. – №2. – Б. 167-172.
3. Вәли-Барҗылы, М. Әдәбият дөньясы / М. Вәли-Барҗылы // Ватаным Татарстан. – 2000. – 3 нояб.
4. Бәйрәмова, Ф. Ак һәм кара көрәше / Ф. Бәйрәмова // Казан утлары. – 2001. – №12. – Б. 119-128.
5. Сафин, Ф. Гыйбрәт алыйм дисәң / Ф. Сафин // Казан утлары. – 2002. – №9. – Б. 31-140.
6. Шәрәфиев, Р. Безме могҗизалар көтмәдек? / Р. Шәрәфиев // Мәдәни җомга. – 2000. – 12 май.
7. Әхмәтҗанов, М. Милләт каһарманы / М. Әхмәтҗанов // Мирас. – 2000. – №10. – Б. 54-62.
8. Рахмани, Р. Бара шагыйрь төпкә җигелеп / Р. Рахмани // Идел. – 2002. – №5. – Б. 60-65.
9. Фәтхерахманов, Р. Йөрәкнең җеназасы / Р. Фәтхерахманов // Казан утлары. – 2003. – №11. – Б. 132-138.
10. Рахман, Р. Айдар Хәлим белә кая барганны / Р. Рахмани // Мәгърифәт. – 2008. – 8 март.



***Эльвира ХӘЙРЕТДИНОВА,***
*Чаллы шәһәренең*
*муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе*
*«10нчы гомуми белем бирү мәктәбе»*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


## ФАКИЛ САФИН ИҖАТЫНДА АВЫЛ ТЕМАСЫ

Бүгенге көндә милләт буларак исән булуыбызның, туган телебезне саклап кала алуыбызның һәм башка бик күп яхшы сыйфатларыбызның да нигезендә авыл һәм аның әхлагы ята.

Соңгы чорда язылган әсәрләрдә язучылар милли көнкүрешебезнең нигезе булган авылның әхлакый һәм физик яктан югалуга таба баруын күрсәттеләр. Бу фикер Ә. Еникинең 1969 елда язылган «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә үк ачык күренә. Авыл турында А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, М. Мәһдиев һәм башка бик күп әдипләребез язды.

Яраткан әдипләребезнең берсе – Факил Сафин да әсәрләренә җирлек итеп авылны ала. Аның иҗаты 90 нчы елларда киң

җәмәгатьчелектә танылды. Шигърияттә һәм прозада җәмгыятебезне борчыган проблемаларны колачлап, укучыларның үзенә җәлеп итә алды ул.

Ф. Сафин татар авылларының язмышы турында «Кеше итсен безне бу тылсым» мәкаләсендә дә бик борчылып яза: «Бүгенге көндә бөтен Рәсәй буйлап сибелгән татар авылларының язмышы хакында уйлыйм да, йөрәк сулкылдап куя – авыллар бетсә, татар халкының тамыры корыячак, теле бетәчәк. Татарны халык буларак Татарстандагы милләттәшләребез генә саклап кала алмаячак» [6:20].

Аның «Гөлҗиһан» повесте авыл тормышы турында. Тормышчан образларга бай булган повесть хәзерге татар прозасының бер казанышы булып тора.

Әсәрнең үзәгендә – сугыштан соң авылда авыр тормыш кичергән, әмма рухи яктан көчле, сынмаган, сыгылмаган татар хатыны язмышы. Әсәрнең төп герое – Гөлҗиһан. Язучы кеше күңеленең матурлыгын, катлаулы вакыйгалар аша түгел, гади, тормышчан хәлләр аша ача. Ф. Сафин боларны Гөлҗиһан образы аша тагын да ачыграк, тагын да фаҗигалерәк яктырта. Ап-ачык итеп күрсәтеп, борчылып, татар авылына ниләр янаганын тасвирлый ул.

Гөлҗиһанның уңганлыгын, гадилеген, шаянлыгын сурәтләү белән бергә, язучы аны чолгап алган тискәре күренешләрне дә онытмый. Бу әсәрендә автор гади татар авылындагы әдәп, әхлак, гаилә проблемаларын да күтәрә. Гөлҗиһан кешеләрне, тормышны ярата, ярдәмчел, игътибарлы кеше ул.

Шәһәр алып килгән рухи ярлылыктан ерак булган ихлас, беркатлы, эшчән, тырыш, саф авыл хатыны үз эшен яхшы башкара. Шуңа күрә ул күңелдә ихтирам хисе генә уята.

«Берни белән дә башкалардан аерылып тормаган бу татар хатыны, нәкъ менә Татар хатыны, тормыш итәргә гаҗәп тә үҗәт, нинди генә югалтуларга да карамастан, ул яшәргә тырыша, үзеннән соң тамырлар калдырырга тели. Аңа яшәү көче, диннән килгән Коръәни сабырлык хас. Аларны саклап килгән көч тә шул дини тәрбиядер әле, мөгаен. Татар хатыны образы, шуның белән ул татар әдәбиятындагы Аналар образы галереясын тутырып тора», – дип яза Н. Гамбәр гади авыл хатыны турында [2:3].

Гөлҗиһанның хәтта исеме дә гади түгел. Җиһан гөле, дөнья гөле, ләкин каты кыраулар төшкән гөл ул.

Ниләр күрми бу Гөл: әнисен, әтисен, мәхәббәтен, ирен, абыйсын югалта; улы авыру, оныкны тәрбияләргә кирәк. Шулар өстенә әле кемнәр генә рәнҗетми аны! Шуларга карамастан, саф һәм яшәүчән булып кала Гөлҗиһан. Кайдан алырга була шундый көчне?



Язучы моңа үзе үк җавап бирә: «Көчне ул татар халкы әхлагыннан, аның гореф-гадәт, йолаларыннан, яшәү рәвешеннән, дин кануннарыннан ала. Татарның яшәүчәнлегеннән, бер сүз белән әйткәндә, Татарның татарлыгыннан!».

Үзәккә куелган герой – Гөлҗиһан – көчле рухлы, җаваплылыкны үз җилкәсенә алырга курыкмый торган хатын-кыз. Ул милли әдәбият өчен традицион, авторның уңай идеалы дәрәҗәсендә сурәтләнә. Язучы аның кызгана белү һәм гел яхшылык кына эшләү сәләтен калкытып куя.

Ф. Сафинның «Соңгы көз» повесте да авыл тормышын күп яклап колачлый. Ул 1992 елда аерым китап булып басылып чыга. Бу әсәрнең язылу тарихы, андагы прототиплар миңа бигрәк нык тәэсир итә, чөнки анда минем туган авылымда барган хәлләр, авылым кешеләре тормышы һәм язмышы аша хәзерге авыл әхлагы күрсәтелгән. Әсәр бер кешене дә битараф калдырмаган. Билгеле бер дәрәҗәдә тәрбия китабы ролен дә үтәгән ул авылдашларым өчен. Кемнәрдер аннан үзен таныса, кайберәүләргә авылдашлары алдында кызарырга да туры килгән. Бүген дә авыл халкының игътибар үзәгендә бу әсәр. Анда сурәтләнгән образларның күбесе безгә, яшь буынга таныш булмаса да, авыл язмышын хәл итүдә, авылның киләчәгендә бу әсәр зур роль уйный. Бирелә рәис тирәсенә укмашкан куштан белгечләр дә, райондагы һәм Казандагы элек сабакташ булган җитәкчеләр дә бар. Шулай ук гомер юлларын әле яңа гына башлаган яшүсмерләр дә һәм алар арасында Рәхилә дә. Бирелә колхоз рәисенең шома ерткычларына каршы торырга тырышкан, баш бирмәскә теләгән яшь мәктәп директоры да… Ә мәктәп директорының прототибы – Ф. Сафин үзе. Бүген дә сагынып искә ала авыл халкы гаделсезлеккә, деспотизмга, имансызлыкка, кешесезлеккә каршы чыккан кыю, үзсүзле, максатына ирешүчән мәктәп җитәкчесен. Монда икенче бер яшь түрә тарафыннан шактый гына «талкынган « кызны үзенә хатынлыкка алган авыл советы рәисе дә. Колхоз хуҗасының шәһәрдә аерым фатирда типтереп, юлдан язган үз малае да…

Автор заманча үткен мәсьәләләр күтәрә. Әсәр безнең тарафтан бик мавыгып, бирелеп укыла. Аның повестендагы геройлар тормышчан, җанлы-тере кеше сыман күз алдына киләләр. Әсәрнең сюжеты киң колачлы, аңа бик күп вакыйгалар сыйган. Төбәк сүзләре әсәр тукымасында табигый яшәү таба.

Язучының иҗади кыйбласы билгеле: ул – тормышта булган тискәре күренешләрне, бозык рухлы җитәкчеләрнең әшәкелеген дөнья күзенә күрсәтеп фаш итү, дөньяны андый күренешләрдән арындыру. Тимерхан Заманов – эшлекле, гаяр, хуҗалыкны алып

бара белә торган, кешеләрне эшләтеп, үзенә «каймагын» җыя белә торган җитәкче. Әмма романның үзәгенә ул куелмаган. Бередә шул сыйфатлары белән янәшә «азгынлык» куелган. Шул азгынлык корбаннары аша кеше таптау, шәхесне изү күрсәтелә.

Бу образ белән танышкач, ничәмә еллар буе бөтен ил халкы күз текәп торган колхоз, район, өлкә һәи ил җитәкчеләре күз алдына килә. Тимерхан әнә шул бөтен түрәләрнең бер җыелма образы буларак укучы хөкеменә чыгарылгандыр, мөгаен.

«Соңгы көз « үзгәртеп корулар алды елларындагы авыл тормышын сурәтли, совет хакимиятенең торгынлык, кризис атмосферасын тергезә. Язучы шул торгынлыктан чыгу юлы юклыгын искәртә, моның сәбәпләрен әлеге системаның нигезенә салынган кануннарның дөрес булмавы белән дәлилли.

Ф. Сафин «Биек тауның башларында» романында да бүгенге авыл тормышын сурәтли, электән килгән матурлыкның – кеше күңеле, әхлагы, холыгы, тәрбиясе гүзәллегенең, кешеләрнең көнкүрешендәге тәртипнең, үзара мөнәсәбәтләр чисталыгының, традицияләр, йолалар, гадәтләрнең югалмаганлыгын күрсәтә.

Язучы үзе: «Бу турыдан-туры халык өстенә ишелеп төшкән фаҗига гына түгел, ә Рәсәйдәге милләтара сәясәтнең ни дәрәҗәдә гарипләндерелгән булуы хакында. Һәм шул сәясәт аерым бер милләткә генә, бу очракта Рәсәйнең чечен халкына каршы алып барган сугышның кайтавазы гына түгел, ул башка милләтләргә дә йогынты ясый... Минем исә шушы сәясәтнең гап-гади татар гаиләсенә тәэсирен күрсәтәсем килде», – ди.

Романда егерменче йөзнең 90 нчы елларында халкыбыз җаны аша үткән гыйбрәтле хәлләр сурәтләнә. Әсәр җиңел укыла, бер утыруда укып чыгарга мөмкин. Әдип милли хисләрне, намусын саклаган, йөрәгендә олы мәхәббәт йөрткән геройларны үзәккә куя.

Шәфкать – гадел, тырыш һәм намуслы егет. Ватанга хезмәт итү, илгә тугрылыклы булу – аның өчен изге нәрсә. Ул Ватан белән намус төшенчәсен янәшә куярга өйрәнгән, тәрбияле, шәфкатле. Аның мондый сыйфатын исеме үк әйтеп тора. «Башка исем куйсалар, мин булмас идем», – ди ул үзе. Ләкин Шәфкать тормыш авырлыкларын, яшәү белән көрәшне ничек алып барырга кирәклеген аңлап җиткерми.

Ф. Сафинның әсәрләрендә вакыйгалар тормышның үзеннән алынган. Язучы иҗатының әхлакый кыйммәте зур. Ул халкыбызны дөрес яшәргә, әхлак кагыйдәләренә өйрәтә. Үзе дә авылдан чыккан язучы буларак, Ф. Сафинга авылның һәр сулышы, яшәеше, кешеләре, тарихы, гореф-гадәтләре – һәммәсе таныш. Шуңа күрә дә ул татар халкының яшәешен, тормышын авыл кешеләре аша сурәтли.



*Бер сагышка мең шатлыгын бирер,*
*Туган җирем – назлы бишегем.*
*Монда туып, монда үскәнгәдер*
*Җыр дөньясы ачты ишеген, –*

дип, туган җирен олылаган шагыйрь Ф. Сафин – бүген татар халкының яраткан әдибе.

Ф. Сафин бүгенге татар әдәбиятының абруйлы һәм әйдәп баручы прозаигы булып танылды. Күптән түгел генә басылып чыккан «Саташып аткан таң « роман-трилогиясе дә моны ачык раслый. Ул – татар прозасының иң зур осталары традицияләрен уңышлы дәвам иттерүче сирәк авторларның берсе.

**ӘДӘБИЯТ:**


11. Вәлиев, М. Яңа исемнәр, яңа әсәрләр / М. Вәлиев // Казан утлары. – 1994. – №1.
12. Гамбәр, Н. Талантлы син, Кеше туганым / Н. Гамбәр // «Саташып аткан таң» китабына кереш мәкалә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.
13. Сафин, Ф. Гөлҗиһан / Ф. Сафин. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1998.
14. Сафин, Ф. Саташып аткан таң: Роман-трилогия. / Ф. Сафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.
15. Сафин, Ф. Соңгы көз / Ф. Сафин. – Чаллы: «КамАЗ» кит. нәшр., 1992.
16. Сафин, Ф. Шигъри балкыш / Ф. Сафин // Мәйдан. – 2008. – №12.



***Фәния СӘМИГУЛЛИНА,***
*Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының*
*23 нче санлы китапханә мөдире*


## «ХИКМӘТЛЕ ДӨНЬЯ» ИЛЧЕСЕ
## (Заһирә Гомәрова шигъриятенә күзәтү)

Шигърият кеше күңелендә аерым һәм үзенчәлекле урын алып тора. Әле генә сөйләшә башлаган сабыйга без аның яраткан уенчыклары турында кыска гына юллы шигырьләр өйрәтәбез, аның сөйләм телен шомартабыз, шигырь юлларына салынган бишек жырларыбызны жырлыйбыз. Шулай итеп шигърият безне балачактан ук үзенең серле дөньясына бөтереп алып кереп китә. Ә ул серле дөнья белән бала арасында арадашчы булып язучы – шагыйрь тора. Матур итеп рифмага салынган, юмор белән язылган, сине борчыган сорауларга кыска итеп, тиз генә җавап бирүче шигырьләрне укуы нинди рәхәт!

«Юк, күңеле тупасланганнар, һәрнәрсәдә ачыш ясап, кызык табып яшәмәгәннәр бик теләсә дә сабыйлар өчен иҗат итә алмаячак. Моның өчен Заһирә ханым кебек гомер буе сабый булып калырга кирәк», – дип язган язучы Рәшит Бәшәр балалар өчен иҗат ителгән 16 проза һәм шигырь китаплары авторы Заһирә Гомәрова иҗатына сокланып.

Заһирә апа 1985-2002 елларда Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итте. 1995 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булды. Аның шигырьләре ихласлыгы, җылылыгы белән балалар күңелендә тиз истә кала. Гади, шаян сүзләр белән, ул, балаларның үз телендә, табигатьнең матурлыгын, серләрен аңлата, туган якка мәхәббәт, дуслык-туганлык сыйфатлары тәрбияли.

*Кимемәс матурлык,*
*Артыр ул кабаттан –*
*Илеңне, җиреңне,*
*Хезмәтне яратсаң –*

дип яза шагыйрә үзенең «Ул синең иркеңдә» дигән шигырендә.

Кем ничектер, мин үзем берәр язучының иҗат җимеше белән танышсам, аның талантының «чишмә башы» белән дә кызыксынам. Шагыйрәнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүдә миңа Яр Чаллы шәһәре үзәкләштерелгән китапханәләр челтәренең М. Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсе бастырып чыгарган «Чаллы язучылары» сериясеннән Заһирә Гомәрова турында библиографик күрсәткеч булышты. Күрсәткечнең «Кушымта» өлешендә язучының төрле елларда татар матбугаты битләрендә басылган һәм шәхси архивында сакланган кайбер фотосурәтләре бирелгән.

Заһирә апаның тормыш юлы белән танышкач аның күпкырлы шәхес булганы беленә: талантлы укытучы, балалар шагыйрәсе, хикәяләр язу остасы, шахматчы, мандолиначы, музыкант, оста оештыручы һ.б. Ә «чишмә башына» килгәндә. Заһирә Әбүбәкер кызы Гомәрованың 1930 елның 12 апрелендә Татарстан Республикасы Арча районы Чөмә-Елга авылында туа. Аның шигырьләр белән мавыгуы алтынчы сыйныфта укыганда башлана. Ул үзенең шигырьләрен, кәгазь булмау сәбәпле, иске китап битләренә яза. Бик тә тыйнак булу аркасында аларны бер кешегә дә күрсәтми, укымый.

Әле мәктәпне тәмамлап, Арча педагогия училищесында белем ала, 1948 елда Масра авылында укытучы булып хезмәт юлын башлый. Аннан Саба районы (ул чорда Чуриле районы) Эзмә авыл



мәктәбенә эшкә урнашкач кына, ул Саба район газетасына үзенең шигырьләрен юллый. Шагыйрәнең беренче шигырьләр китабы «Яшьлек таңы» (1964) дип атала. Аның чәчәкле, баллы җәйләр, алтын яфраклы көзләр, «Карлы – бозлы» карбызлар, «Борын очы сипкелле» песиләр, «Кар иләген селкеткән» кышлар, «Оялудан кызарган помидорлар» тасвирланган шигырьләре укучылар күңеленә бик хуш килә. Китапханә эшләү дәверендә, татар балалары һәм аларның әти-әниләре арасында: «Шәһәребездә яшәп иҗат иткән нинди әдипләрне беләсез» – дигән темага сорау-опрос уздырды. Җавaплардан күрергәнчә күп кенә балалар һәм әти – әниләр башка язучылар белән бергә Заһирә апа Гомәрованы да атадылар. Димәк шагыйрәнең үз укучылары бар. Ә аның китапханә фондында сакланган ике «Бабай балы» һәм «Хикмәтле дөнья» китабы иң күп укылган, китаплар исемлегендә булды.

Шагыйрәнең «Хикмәтле дөнья» дигән китабына кырык еллык иҗат тормышында язылган һәм моңа кадәр дистәдән артык китапларда дөнья күргән шигырьләре тупланган. Китапның аталышы нәрсәне аңлата, «Хикмәтле дөнья» нидән тора соң?

*Кердем мин серле дөньяга,*
*Һәр тарафы өр – яңа;*
*Атлап киттем гаҗәпләнеп,*
*Юллардан, сукмаклардан…*
*Бу дөньяда күпме кояш,*
*Күпме шатлык, күпме күз яше*
*күреп мин хәйран калдым.*
*«Китап» дигән бу дөньяны*
*Кибеттән сатып алдым, –*

дип безнең сорауга аңлатма бирә шагыйрә үзенең «Хикмәтле дөнья» шигырендә.

«Хикмәтле дөнья» китабы биш бүлектән тора. Беренче бүлек «Мин җаваплы барысы өчен» дип атала. Анда урнашкан шигырьләрдә, җир йөзенең матурлыгына сокланып, сугышлар булдырмыйча тыныч тормышларда яшик дигән тема яңгыралыш алган.

*Сабый бала*
*Гел елмайсын,*
*Көлсен өчен.*
*Үлем тулы*
*Коралларны*
*Юк итәрбез.*

*Тыныч булсын,*
*Имин торсын*
*Планетабыз.*

*(«Мин җаваплы»)*

*Гел елмай, Кояшым,*
*Табигать куансын.*
*Кара төн булмасын,*
*Яшь гомер сулмасын...*
*Шат тормыш гөрләсен,*
*Кайгылар килмәсен, –*

дип борчыла Заһирә апа үзенең «Кояшым» дигән шигырендә.

*Гел эштә янарга –*
*чын бәхет шушында.*
*Янмасын беркем дә*
*Тик сугыш утында, –*

дип тели ул.

*(«Ул синең иркеңдә»)*

Бу бүлеккә урнашкан шигырьләрдән башлангыч сыйныф укучылары белән Җиңү бәйрәменә шигъри монтаж әзерләргә була. Бу бүлеккә нәтиҗә ясап шуны ишеттерәсе килә: Шагыйрә үзенең иҗатында сугышка каршы теманы күтәреп чыга. Укучының игътибарын тормышның гүзәл якларына юнәлтә. «Нәниләр почмагы» дигән бүлеккә кергән шигырьләрнең нәни геройлары «Ни өчен? » дигән сорауга җавап эзлиләр. Автор балалар күзлегеннән чыгып, җылы, тапкыр сүзләр белән җавабын бирә.

Монда һәрбер шигырь героеның исеме бар. «Күлмәген юды Гөлли...” («Буем җитми»), «Алмаз йокыдан торды... » («Төш»), «Врач булды безнең Мансур, курчакларны дәвалый...» («Үзем врач»), «Кызык малай ул Хикмәт...» («Кар малай»), «Азатның ботинкалары, сүз тыңламый башлады...” («Ботинкалар”), «Иртән торгач Әлфия...” («Күз нигә тия соң ул?»), «Чыкты бакчага, нәни Кифая.. » («Чәчәкләр кая?») һ.б. Бу шигырьләрне балалар бакчасында тәрбиячеләр татар исемнәре буенча берәр чара уздырганда куллана алалар. Шигъри тәлгәшләре белән автор сабыйларны тәүфыйклы булып үсәргә, хезмәтне яратырга өнди.

«Мин мәктәпкә барам» дигән бүлектә шигырьләр башлангыч мәктәп тормышына багышланганнар.



*Башлангыч мәктәбем,*
*Калсаң да еракта,*
*Син мәңге күңелдә,*
*Йөрәктә, йөрәктә, –*

дип искә ала уку елларын.

«Класста», «Тактада ике сан», «Икеле алгач», «Рәсем ясый Марат», «Башваткыч», «Күчердем дә күчердем», «Без йөгерешкә барабыз», «Эзе кала», «Балыкта» шигырьләрендә шагыйрә балаларны мәктәп тормышы белән таныштыра, иптәшләрен, укытучыларны хөрмәт итәргә өнди. Аларны укыгач мәктәпкә барасы килә башлый, чөнки автор дәресләр, тәнәфесләр, җәйге яллар, дежур торулар, походларга барулар турында шундый мавыктыргыч итеп яза. Алай гына да түгел мсәктәпкә барып «өчкә икене» кушкач ничә буласын белмәгән Хисамга булышасы («Тактада ике сан»), Рәсимгә («Барган җирдә озак торсам») мәктәп тәртипләрен өйрәтәсе, Фәнискә («Исем бирдек») алдашу матур түгел икәнне аңлатасы килә. Бу шигырьләр «Белем бәйрәме» уздырганда куллану өчен менә дигән материал. Шагыйрә иҗатында: әхлаклы, әдәпле, тырыш булган балалар укуда да, киләчәктә дә сынатмаячаклар дигән фикер яңгырый.

Тулы гаилә ничә кешедән тора? Моны һәм нинди гаилә бәйрәмнәре уздырып булганын беләсегез килсә, китапның «Безнең гаилә» дип аталган бүлегенә мөрәҗагать итә аласыз.

*Без бер өйдә сигез кеше,*
*Төрле яшьтә төрлебез.*
*Спорт ярышы булдымы,*
*катнаша һәрберебез, –*

дип яза автор «Бер өйдә сигез кеше» шигырендә.

Бу бүлектә күп кенә шигырьләр кадерле әниләргә багышланган. Автор матур, җылы сүзләр белән әниләрнең балалар өчен иң якын кеше булуын тасвирлый. Әни юатучы да, киңәшче дә, матур курчак та алып бирүче, тәти күлмәк тә тегүче, тәмле ашлар да пешерүче. Болар «Минем әни», «Бүләк», «Доктор абый», «Әниснең әнисләре», «Иске ел кая китә?», «Иртән», «Минем бүләк» дигән шигырьләрдә аеруча чагыла. Бу бүлеккә кергән шигырьләрне Әниләр көнен, Гаилә бәйрәмен уздырганда кулланырга мөмкин. Заһирә Гомәрова үзенең иҗатында, бар нәрсә гаиләдән башлана, бабай, әби, әти, әни, абый, апалар үрнәк булган гаиләдә рухи яктан камил балалар үсәчәк дигән фикерне раслый.

Бишенче, «Табигатьне яратабыз» дигән бүлеккә тупланган шигырьләрнең темасы аталышыннан үк күренә. Автор бу шигырьләрдә балаларга «табигатьне яратыгыз» дип турыдан – туры әйтмичә генә, аның «тылсымлы җәймәләре», «мамык сыман аксыл болытлары», «данлыклы елга»лары, «ямь – яшел келәмнәре», «ак чәчәктәй вак йолдызлары» булган җәен, «баланлы, миләшле» көзен, «боз – толып»кигән елгалы, «Суык бабайлы», «Кырауҗанлы» кышын, «сыерчыклы» язын гади, балалар өчен аңлаешлы телдә сүрәтләп бирә, шул рәвешле сабыйларга табигатебезнең кабатланмас гүзәллеген күрсәтеп, алар күңелендә туган якны ярату хисе уята.

*Яшәү гел дәвам итә:*
*Җәе, көзе, кышлары*
*Кайта да тагын китә.*
*Тагын яшәрә тугай.*
*Мин тугайда бер Тургай –*

ди, шагыйрә «Тургай» шигырендә.

Тәрбиячеләргә, башлангыч сыйныф укытучыларына, китапханәчеләргә экологик сәгатьләр, чәчәкләр бәйрәме, ел фасыллары буенча чаралар уздырырга кирәк булса, рәхим итеп китапның шушы бүлегенә мөрәҗәгать итәргә киңәш итәр идем. Авторның бу бүлеккә кергән шигырьләре балаларны тирә – як мохитка карата күзәтүчән булырга, һәр ел фасылының матурлыгын күреп, сокланып яшәргә чакыра, табигатьне яраткан, аңа сак караган баланың күңеле һәрчак яхшыда була дигән фикерне алга куя.

Заһирә Гомәрова утыз биш ел гомерен балаларга багышлый. Ул укытучы, шуңа күрә балалар телен, алар психологиясен тирәнтен белгән шагыйрә. Заһирә Әбүбәкер кызы үзе дә өч бала үстергән ана. Аның иҗатында һәрвакыт актуаль булган әхлакый тәрбия, табигатьне саклау, дуслык – туганлык хисләре, Туган якка мәхәббәт кебек темалар чагылыш тапкан. Чаллы төбәгендә яшәп иҗат иткән язучы Заһирә Гомәрованың иҗатына һәрдаим мөрәҗәгать итегез, чөнки аның яшь буынны тәрбияләүдә роле зур.

**ӘДӘБИЯТ:**

1. Заһирә Гомәрова: Биобиблиографик күрсәткеч / Чаллы шәһәре. М.Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсе / төз. Р.Г. Хәмидуллина. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2000. – 43 бит. – (Чаллы язучылары иҗаты).
2. Гомәрова, З. Хикмәтле дөнья: хикәяләр / З.Гомәрова. – Чаллы: «КАМАЗ» нәшр., 1997.



***Фирдая ЗИГАНШИНА,***
*Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының*
*1 нче санлы китапханә мөдире*

## МАНСУР САФИН ИҖАТЫНДА ТУГАН ЯК ЧАГЫЛЫШЫ

Туган як! Туган җир! Туган туфрак! Туган төбәк! Һәрбер кеше өчен нинди газиз, тирән мәгънәле сүзләр! Нинди генә язучылар, шагыйрьләр аны зурламаганнар, күкләргә чөеп мактамаганнар. Алар һәркем йөрәгендә яши һәм вакытлар үтү белән тагын да тулылана гына бара. Һәрбер иҗат кешесе, үзенең иҗатында туган якның табигатен, дөньядагы иң изге, иң матур, күңелгә үтеп керә торган саф сүзләр белән тасвирлый. Якташ язучыбыз Мансур Сафин да үзенең иҗатында бу темага зур урын бирә. Аның бала һәм үсмер чаклары Татарстанның иң матур якларында, Мамадыш шәһәрендә уза. Урман-суларга бай табигатьле як, үсеп килүче яшь егет күңеленә лирик шагыйрь, язучы булып формалашуына нигез сала. Үзе әйткәнчә: «Мамадыш якларында үскән күңелем шагыйрь булмыйча булдыра алмады». Туган ягын өзелеп сөйгән шагыйрь М. Сафин «кече Ватаны» Мамадышка багышлап татар һәм рус телләрендә 200 дән артык шигырь иҗат итә. Аның «Туган якка мәдхия» шигыре үзе генә ни тора!

*Нократ –ярга бассам, Бәйҗан тавы*
*Шанлы җанны бәйли үзенә:*
*Китә алмыйм аннан аерылыплар,*
*Егылып елыйм җылы эземә!*

*Бу күкләргә күз нурларым сеңгән,*
*Бу кырларга хисләр таралган.*
*Шушы Бәйҗан тавы күкрәгендә*
*Хыял канатларым яралган.*

Мансур Сафинның туган якка багышланган тагын бер шигыре – ул «Мамадыш таңнары»

*...И, туган як таңнары!*
*Бөдрә-бөдрә таллары.*
*Балачакның бәхет серен*
*Ачасы иде бары. –*

автор туган ягының нечкәлекләрен шулай дип тасвирлый.

Туган җир сүрәтен тудыруда шагыйрь пейзаж лирикасына киң таяна. Лирик пейзаж үзенең буяулары, төс-төсмерләре, гүзәллеге белән шигырь юлларына үрелә, авторның кичерешләренә, әйтәсе сүз-фикерләренә нәфис бизәкләр өсти.

*Әллә каян килеп, төшкә керә*
*Туган якның изге чишесе!*
*Болыннарда йоклыйсылар килә,*
*Әремнәрен килә иснәсе...*

*(«Туган ягым»)*

Туган якның елгалары, күлләре, агачлары, гөлләре, кошлары – барысы да шагыйрьнең тасвирлавында «менә нинди ул безнең як!» дигән соклану тудыралар. «Мамадыш язы», «Уйчан өянкеләр», «Таң мизгеле», «Яз. Былбыллар» шигырьләрендә бу бик ачык күренәләр.

*Бездәге һәр өянкенең*
*Болыттай ябалдашы,*
*Бездәге һәр чишмә-инеш*
*Аһири авылдашым!*

*(«Гыйшык сихере»)*

Чишмәләр... Кемнең генә күңеленә илһам салмый да, кемгә генә канат куеп, хыялларын үстерми икән соң алар?! Шагыйрьнең бу темага багышланган шигырьләре дә бик күп.

*Бәллүр чишмә моңнар сирпи*
*Инешләр үзәненә*
*Сөенечле аһәң табып*
*Җир-ана үзәгеннән.*

*Былбыллар белән ярыша,*
*Гөлләр белән серләшә.*
*–Хәерле киләсең дускай! –*
*Диеп, назлы эндәшә.*

*(«Бәллүр чишмә»)*

Аның бу шигырен укыганда синең алдыңда чылтырап аккан чишмәләре белән бөтен бер дөнья ачыла. «Илһам җыры тулы бу киңлектә...» шигыренә игътибар итик:



*Туган ягым! Күңел балкышыма*
*Синең шәфакъ моңы кушылган.*
*Әмма минем язмыш тынычлыгын*
*Вакыт дигән күчмә кош алган.*

Ә менә «Туган якның әсире мин» шигырен тыңлап узыйк:

*Сатып алдың мине,*
*Сатып алдың,*
*Таң алтыны – күл көмешенә,*
*Табигатьнең могжизалы, серле,*
*Миңа дигән мул өлешенә.*

*Сатып алдың мине, сатып алдың*
*Тәүге чыкның энҗеләренә,*
*Гәрәбәле әбиләр чуагы,*
*Изге чишмә – кизләүләренә.*

*Сатып алмасаң да, сихерләнә*
*Үзем бирелергә әзер мин, –*
*Туган якның назлы куенында*
*Гомер-гомергә бер әсир мин!*

Шагыйрь туган ягын җаны-тәне белән яратмаса, мондый юлларны яза алыр идеме?

Туган җиргә мәдхия һәм мәхәббәт М. Сафинның махсус рәвештә аерым авылларга («Көмеш күлгә мәдхия», «Комазан чишмәсе», «Калатау җыры», «Сарбаш сагышы») багышлап язылган шигырьләренең төп мотивын тәшкил итә.

*Көмеш Күл – алтын балачак,*
*Изге дастаннар иле!*
*Могҗизалы мизгелләрдән*
*Тукылган Вакыт җиле!*
*Алнурлы, Шәйхи Маннурлы*
*Хатирәләр төбәген,*
*Туганнарча мамадышлап,*
*Мәңге назлый йөрәгем.*
*Көмеш Күл, Тулбай, Комазан –*
*Шәҗәрә тамырлары:*
*Безнең якта бал – тамчылы*
*Фатиха яңгырлары*

*(«Көмеш күлгә мәдхия»)*

Туган ягына мәхәббәт хисе шагыйрь шигырьләрендә үткән балачагын сагыну хисе белән дә үрелеп бара:

*Балачакның агач аты*
*Тәүге урамнан чаба,*
*Тәүге ядкарьләр яңгырый*
*Сагыш чатында таба.*
*Шул яңгырның тере суын*
*Куш учлап эчәм әле-*
*Сабый чагым мизгеленә,*
*Дәртләнеп кучәм әле!*

*(«Балачакның агач аты»)*

Мансур Сафинның шигырьләрен укыган саен укыйсы килә. Аның һәр шигырендә туган җиребезнең моңы, җылысы, шул җирне бизәүче хезмәт кешесенең сулышы тоела. Язмамны танылган профессиональ журналист, язучы, шагыйрь, тәрҗемәче Мансур Сафинның «Кайтырга язсын» шигыре белән тәмамлыйсы килә. Бу шигыре күңел кылларын чиртеп кенә түгел, елатып та ала.

*Мамадышта хәрбер кошчык*
*Сандугач булып сайрый.*
*Мамадышта хәрбер көчек*
*Елмаеп, сөенеп карый.*

*Гөрли гөлестаннар булып,*
*Мамадышым – туган ягым!*
*Үз теләгем белән монда*
*Кайтырга язсын тагын...*

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Мгновения Вечности = Мәңгелек мизгелләре / сост. Р.Г. Хамидуллина. – Казань: Редакционно-издательский центр "Школа", 2015. – 364 с.
2. Мансур Сафин: Биобиблиографик күрсәткеч // төз. Р.Г. Хәмидуллина. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2007. – 144 б. – (Чаллы язучылары иҗаты).
3. Сафин, М. Йөрәк тамыры: шигырьләр / Мансур Сафин. –Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 79 б.
4. Сафин, М. Ода Мамадышу = Мамадышка мәдхия / Мансур Сафин. – Наб. Челны, 2007. – 103 с.





***Резеда АСЫЛГАРАЕВА,***
*Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының*
*23 нче санлы китапханәнең бүлек мөдире*


## КҮПКЫРЛЫ ШӘХЕС (Шагыйрь, прозаик Мансур Сафин иҗатына күзәтү)

*Тукай-Пушкин – ике изге канат*
*Алып менде шигъри галәмгә.*
*Мине дәген, тургайларга тиңләп,*
*Коендырды илһам, белемгә.*

Минем чыгышым, сезнең барыгызга да таныш булган, Россия Язучылар бүлеге сәркатибе, Россия һәм Татарстан Язучылары берлеге әгъзасы, Россиянең журналистлар союзы әгъзәсы, отставкадагы мойор гвардии, СССР һәм Россиянең автомобиль гаскәрләре хәрби музее директоры, шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче Мансур Габдулла улы Сафин турында. Аның дүрт дистәдән артык шигырь һәм проза җыентыклары, тәрҗемә китаплары бар.

Мансур Сафин – күпкырлы шәхес.

**1. Мансур Сафин – шагыйрь.**

Әлбәттә, ул беренчедән: туган телен, туган илен, туган төбәген һәм Чаллы шәһәрен яратучы киң күңелле, талантлы шагыйрь!

*Татар илем – Ватаным да,*
*Татар илем – даным да!*
*Тәүге җирем – соңгы җырым,*
*Соңгы тамчы каным да! –*

дип яза автор «Туган илем» шигырендә.

Ә менә «Мой город» шигырендә Яр Чаллы шәһәренә мәдхия җырлый:

*Слушая старинные преданья –*
*Познаю булгарские Чаллы.*
*Часто вижу в розовом тумане*
*Город добатыевой поры.*

Мансур Сафинның «Чаллы мои былинные» поэмасы, «Челнинка, Мелекеска и Шильна» шигыре дә күпләргә таныштыр.

Мансур Сафин шигырьләрендә үзе белән бергә әдәбият мәйданында булган шагыйрь һәм язучыларга дә мәдхия җырлый. Аның Эдуард Касыймов, Фаяз Дунай, Кадыйр Сибгатуллин, Михаил Гоголев, Борис Казаков, Евгений Кувайцев, Николай Алешков һәм башкаларга багышланган шигырьләре бар. Әйтергә кирәк, бу язучының киң күңелле, эчкерсез кеше булуы турында сөйли. Автор шигъриятында Сара Садыйкова, Марина Цветаева, Пушкин һәм Тукаебыз да үз урынын тапкан.

Мансур Сафинның балалар өчен чыккан китаплары да игътибарга лаек.

*Кар сулары көн-төн агып,*
*Кайларга барып җитә?*
*Эрегән кар суын алып,*
*Гөрләвек кая китә?*

*Диңгезләргә китә ул, дип*
*Апам миңа аңлата...*
*Карлар ядкаре булып,*
*Бакчалар чәчәк ата!*

Мансур абый шигырьләр белән генә чикләнеп калмый, нәниләр өчен табышмаклар да иҗат итә.

*Тавышсыз, кулсыз булса да,*
*Күп сүзле, күп рәсемле.*
*Нинди тылсымлы әйбер ул?*
*Дускай, син беләсеңме?*

*(«Китап»)*

Иң сөендергәне – Мансур Сафинның шигырьләре белән рус телле укучыларыбыз да таныша ала. Чөнки ул – ике телдә дә бик матур шигырьләр тудыра.

*И волшебстовом поэзии хранимой,*
*Я потому живу в своих стихах.*
*На русском и татарском, мной любимых*
*На двух родных, священных языках.*



**2. Мансур Сафин – җырлар авторы**

*Җырлыйк әле, дускай, илһамланып*
*Күкрәкләрдә моңнар агылганда.*
*Җырлар өчен җырлар табылганда –*
*Чын йөрәктән бергә җырлыйк әле!*

*(Салават Аюлы «Дустым Мансурга»)*

Мансур Сафин сүзләренә татар һәм рус телләрендә 20 дән артык җыр язылган. Аның шигырьләрен Зиннур Мөхәммәтдинов, Людмила Ткачук, Рәхим Гайсин, Рубис Зарипов, Рәсим Корбанов, Евгений Прохоров, Александр Попов, Валерий Манкушев, Евгений Кузнецов кебек композиторлар көйгә сала. «Туган ягым», «Мамадыш таңнары» җырларында автор туган ягына мәдхия җырласа, «Әбиләр чуагы”, «Әнкәй күңеле» кебек җырлары белән әниләребезне зурлый. Ә инде «Ак каеным», «Сагыш моңы», «Сыерчык бураннары» җырлары безне хисләр дөньясына алып керә. Әлбәттә, моңсыз шигырьләрдән җырлар туа алмый. Димәк, Мансур абыйның шигырьләре күңел түреннән чыккан «чын” шигырьләр! Һәм бу шигырьләр җыр булып татар телендә генә түгел, рус телендә дә яңгырый. «Школьная любовь», «Марш Камазовцев», «Песня о Челнинском комсомоле», «Как боязно сжигать мосты», «Романс о любви» – Чаллы халкы яратып җырлаган бу җырларның сүзләрен Мансур Сафин язган.

**3. Мансур Сафин – тәрҗемәче**

Мансур Сафин – ике телле әдип, ул татар һәм рус телләрендә иҗат итә. Шуңа күрә, тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. Рус телендә ул Зыя Ярмәки, Эдуард Касыймов, Гамил Авзал, Риза Шифа, Ибраһим Салахов, Газиз Кашапов, М. Насыйбуллин, Гәрәфи Шәрәфи, Нәҗип Мәдияров, Рәшит Бәшәр, Айдар Хәлим, Заһирә Гомәрова, Нур Баян һәм башка язучыларның әсәрләрен; ә татар теленә Марина Цветаева, Николай Рубцов, Владимир Высоцкий, В. Хлебников, Борис Пастернак, Александр Блок, Анна Ахматова, Иван Бунин, Федор Тютчев, Михаил Лермонтов, Афанасий Фет кебек танылган әдипләрнең әсәрләрен тәрҗемә итә.

*Бабичларга, Мусаларга тиңдер*
*Высоцкийның ярсу йөрәге.*
*Ничәмә ел, ничәмә чорлар ул*
*Хөрриятка безне өндәде! –*

бу шигырь юллары М. Сафинның «Высоцкий истәлегенә» дип аталган багышламасыннан. Алай гына да түгел, Мансур Сафин Высоцкий исемендәге йолдыз барын искә алып, аның шигырьләре һәм көйләре барлык җиһан өчен әһәмиятле дигән фикер дә әйтә.

*Күпер янган, кичү тирәнәйгән.*
*Юллар кысан, юлларда сөяк.*
*Чыгу-керү урыннары бәйдә,*
*Мин дә – көтүдәге бер көек...*

*Сукыр атлар кебек, бу дөньяның*
*Кысанлыгын кабат исбатлап,*
*Бер түгәрәк булып чаба көтү,*
*Сукмак-гомерен битараф атлап.*

*Ага рәссам кулындагы буяу,*
*Хәвеф яңгырына эләгеп:*
*Төсләр, исләр, көйләр*
*юк буладыр –*
*Кислородсыз калса тереләк.*

*Бу дөньяның торышларын һичбер*
*Дуамаллык, илһам тыялмас.*
*Шушы түгел микән мәңге алга*
*Омтылучы юллар тулы яз?*

*(В. Высоцкий «Мосты сгорели, углубились броды...»)*

**4. Мансур Сафин – тәнкыйтьче һәм публицист.**

Мансур Сафин, чын мәгънәсендә, тел белгече дә әле. КДУның физика факультетында укыган вакытта ул журналистика һәм әдәбият теориясе буенча да белем ала. Борма-борма юллар аша Мансур Сафинның язмышы Чаллы педагогия институтының татар филологиясе кафедрасына мөгаллим итеп алып килә. Шул чорда Мансур Сафин профессор Т.Галиуллин җитәкчелеге астында «Татар поэзиясендә пейзаж образлары системасы» дигән темага кандидатлык дессертациясе һәм күп санлы фәнни эшләр яза. Әлбәттә, бу аның алдагы эшчәнлегендә дә нык чагыла. Мансур Сафинның газета-журналлар битләрендә урын алган йөзләп әдәби тәнкыйть мәкаләләре билгеле. Бу мәкаләләр «Литературная Россия», «Советская Татария», «Нур», «Якты юл», «Шәһри Чаллы», «Мәдәни җомга», «Мәгърифәт» газеталарында; «Аргамак», «Мәйдан», «Новый мир», «Научный Татарстан» журналларында басыла. Алар арасында Шәйхи Маннур, рәссам Эрот Зарипов, гарәп коллиграфиясе язуы остасы Нәкыйп Нәккаш, галим, әдәбиятчы профессор Леонид Арсланов һ.б шәхесләр турында язылган мәкаләләр бар. Мансур абыйның төрле өлкәдә хезмәт куючы кешеләр турында язуы, әлбәттә, аның киң эрудицияле кеше булуын ассызыклый.

**5. Мансур Сафин – төбәкне өйрәнүче белгеч.**

Мансур Сафинны «галим шагыйрь» дип атасак та, ялгыш булмас. Чөнки аның шигырьләре хис белән генә түгел, фактларга нигезләнеп языла. Чаллы турында язылган шигырьләр циклына игътибар итсәк тә, аерым кешеләргә багышлап язылган шигырьләрне карасак та шуны күрәбез. Ә инде «Край былинный, Мамадышский» китабы моңа дәлил булып тора. Мамадыш төбәге турындагы бу китап – «краеведческий сборник». «Челны мои былинные» китабына шигырьләр һәм поэмалар тупланса да, фәнни хезмәт итеп карарга була, минемчә. Чөнки алар күбесе фактларга нигезләнеп язылган һәм үзендә укучы өчен яңалык алып килә. Бу китапта әле Мансур Сафин 1992 елда профессор Евгений Петрович Казаков җитәкчелегендә узган археологик экспедиция нәтиҗәләрен дә бастыра. Экспедициядә язучы үзе дә катнаша.

Мансур Сафин, чын мәгънәсендә, күпкырлы шәхес, талантлы, тынгы белмәс йөрәкле, югары эрудицияле кеше. Аның үзе турында да күп җылы фикерләр әйтелгән, шигъри теләкләр язылган. Язмамны Госман Садәнең Мансур Сафинга багышлап язылган шигырь юллары белән тәмамлыйсы килә.

*Мансур туганкай!*
*Хаклардан алгансың фатыйха –*
*Абынма!*
*Ач күзең, әйт сүзең:*
*Иҗади бәрәкәт алдыңда...*
*Билләһи! Чыгарсың*
*Алдынга!*

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Мансур Сафин: Биобиблиографик күрсәткеч / төз. Р. Г. Хәмидуллина. Чаллы, 2007.– 144 б.
2. Мгновения Вечности = Мәңгелек мизгелләре / сост. Р. Г. Хамидуллина. – Казань: Редакционно-издательский центр «Школа», 2015. – 364 с.
3. Сафин, М. Ода Мамадышу = Мамадышка мәдхия / М. Сафин. – Наб. Челны, 2007. – 103 с.
4. Сафин, М. Йөрәк тамыры: шигырьләр / М. Сафин. –Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 79 б.

***Айсылу НИГМӘТҖАНОВА,***
*Чаллы шәһәренең*
*муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе*
*«5 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*8 нче сыйныф укучысы.*
*Җитәкчесе Галимуллина Кадрия Йосыф кызы*

## ТЫЙНАК МАТУРЛЫК
## (Мансур Сафинның әдәбиятта тоткан урыны)

*Җырлыйк әле, дускай, илһамланып*
*Күкрәкләрдә моңнар агылганда,*
*Җырлар өчен җырлар табылганда –*
*Чын йөрәктән бергә җырлыйк әле!*

*Салават Аюлы*

Шагыйрь һәм тәрҗемәче Мансур Габдулла улы Сафин (әдәби тәхәллүсе – Мансур Булгари, Михаил Загорский) 1949 елның 11 маенда Кемерово өлкәсенең Анжеро-Судженск шәһәрендә шахтер гаиләсендә туа. Балачак һәм мәктәп еллары Мамадыш шәһәрендә уза.

Әтисе-Габдулла ага, Мамадыш районы Түбән Ошма авылында туган. Бөек Ватан сугышы ветераны, фронтовик. Әтисе легендар разведчик булганга күрә, М. Сафин Мамадышта ун сыйныф тәмамлагач, 1966 елда Оренбургка китеп Зенит артиллериясе училищесында хәрби белем ала һәм армия сафында офицер булып хезмәт итә башлый. Ләкин, күп тә үтми, гаилә хәлләре аркасында, әнисе Әминә апа фабрикада эшләгәндә инвалидлыкка дучар булу сәбәпле, ул армиядән китәргә мәҗбүр була. 1970 елда кыска вакытлы педагогик курслар тәмамлап, Мансур берникадәр вакыт мәктәптә физкультура укытучысы булып эшли, аннары Казан дәүләт университетына укырга керә. Студент елларында матбугатта беренче мәкаләләре, әсәрләре, татар шагыйрьләре иҗатыннан рус теленә шигъри тәрҗемәләрен күренә башлый.

1975 елда университетны тәмамлагач, М. Сафин Казанда – инженер-геофизик, Мамадышта партия райкомы инструкторы, Сергиев Посадта – рота һәм батальон командирының сәясәт буенча урынбасары, Чаллыда КамАЗ заводларында штаб башлыгы булып эшли. Берничә ел Чаллы дәүләт педагогия институтының татар филологиясе факультетында укыта. Сиксәненче-туксанынчы елларда Язучылар берлегенең Чаллы бүлегендә матур әдәбиятны пропагандалау бюросы җитәкчесе, «Аргамак» әдәби-нәфис журналының баш мөхәррир урынбасары, «Бизнес-класс» газетасының мөхәррире дә була. Ул «КамАЗ төзелеше ударнигы» дигән мактаулы исем йөртә. Хәзерге вакытта М. Сафин профессионал язучы, фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Әнисе Әминә апа тырыш, уңган, сабыр, тыйнак, зирәк, акыллы, җор сүзле хатын була, гаиләдә 4 бала тәрбияләп үстерәләр.

Мансур Сафин татар һәм рус телләрендә яза, тәрҗемә өлкәсендә актив эшли. Ул – ике дистәдән артык шигырь һәм проза җыентыклары, тәрҗемә китаплары авторы. Алар арасында «Мамадыш таңнары» (1992), «Хәерле иртә» (1994), «Надежда, Вера и Любовь» (1994, рус телендә) исемле лирик шигырь тупланмалары, тәрҗемә башында рус шигъриятеннән М. Цветаева һәм Н. Рубцов җыентыклары бар. Татар әдипләренең әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү юнәлешендә ул аеруча нәтиҗәле эшли. Көндәлек матбугат битләрендә, үз вакытында бигрәк тә «Аргамак» журналы сәхифәләрендә (русча өлешендә) аның тәрҗемәсендә Кол Шәриф, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Габделҗәббар Кандалый, Зыя Ярмәки, Нур Баян, Гамил Афзал, Нәҗип Мадьяров, Газиз Кашапов, Габдулла Шәрәфи, Гакыйль Сәгыйрев һ.б. каләм ияләре иҗатыннан күп кенә тезмә һәм чәчмә әсәрләр, ә Эдуард Касыймов, МәгъсүмНасыйбуллин, Заһирә Гомәрева, Рәшит Бәшәр, Галимҗан Гыйльмановларның аерым китаплары басылып чыга.

Язучы газета-журналларда, күмәк җыентыкларда, махсус басмаларда дөнья күргән төбәк тарихына, археологиягә, әдәби процесска кагылышлы язмалары, әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре, очерклары белән дә укучыларга яхшы таныш. М. Сафин – 1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

М. Сафинның өлкәннәр һәмбалалар өчен дә китаплары чыгып тора, аның шигырьләренә язылган җырлар яңгырый. Ул бигрәк тә яратып балалар өчен иҗат итә. «Ручеек», «Сербакчага сәяхәт» (1997) исемле китаплары Татарстан Милли китапханәсе уздыра торган «Ел китабы» бәйгеләрендә призлы урыннар яулый, 2000 елда балалар әдәбияты өлкәсендәге уңышлары өчен Ш. Маннур исемендәге әдәби бүләккә лаек була. Шулай ук аның иҗаты Э. Касыймов һәм Е. Уткин премияләре белән һәм хөкүмәт тарафыннан «Хезмәт ветераны»(«Ветеран труда»), «Гражданнар оборонасы отличнигы», «КамАЗтөзүчеләр ударнигы»(1988) почетлы исемнәре һәм сигез медаль белән бүләкләнә.

Мансур Сафин шагыйрь генә түгел, шулай ук ул прозаик та, журналист та, тәрҗемәче дә.

Шагыйрь Зиннур Мансуров үзенең бер язмасында, Мансур Сафинның әдәби эшчәнлеген бәяләп, түбәндәгечә яза: «Син инде беләсең, безнең халыкта әдәбият атамасы «Әдәп» сүзенә нигезләнеп ясалган, диләр. Бу чыннан да чынлыкка охшый. Каләм әһеле иң беренче чиратта үзенең күңел байлыгына таянып иҗат итә. Һәм ул, әлбәттә, әдәпле, зыялы, игелекле, ихлас булырга тиеш. Синдә менә шушы мөһим сыйфатларның барысы да бар. Һәрвакыт шулай әдәпле, зыялы, игелекле, ихлас булып кал. Шушы сыйфатларның әҗерен күрергә язсын».

Чыннан да, Мансур Сафин әдәпле, зыялы, игелекле, ихлас кеше. Нәкъ менә балалар әдәбияты өлкәсендә шушындый сыйфатларга ия кеше генә иҗат итә ала һәм, нәтиҗәдә, аеруча зур уңыш казанды да. Мансур Сафинның шигърияте башка авторлар иҗатыннан аерылып тора. Бу үзенчәлек шагыйрьнең чынбарлыкны баланың садәлеге һәм хыялыйлыгы белән бәйләп бирүендә, нәниләр өчен образлы фикерләүгә, шигъри фантазиягә юл ачуында, баланы кызыксындыру максатыннан төрле формаларга мөрәҗәгать итү һәм мавыктыргыч ачышлар ясавында, шулай ук, әлбәттә, гади хәл-вакыйгада балаларча күтелмәгән мәгънә яки кызык табуында һ.б. Мәсәлән, шагыйрьнең «Кәнфиттән дә тәмлерәк" китабын искә алып үтик. Китап балалар өчен зур бүләк. Бу китапка табигать күренешләреннән, үсемлек, хайваннар дөньясыннан бик кызыклы һәм тапкыр, әле моңа кадәр телгә алынмаган мизгелләр, детальләр кертелгән. Автор аларны бик урынлы тотып алып, ачык, матур тел белән, балаларча шаянлык аша, уйланырлык итеп тәкъдим итә белгән. Шуңа күрә, бу китап, балаларны табигатьне күзәтергә өйрәтергә тиеш.

Мансур Сафин – нәниләр өчен чын күңелен биреп иҗат итүчеләрнең берсе. Аның әсәрләре үзенең тема төрлелеге, үзенчәлекле стиле, оригиналь юмор хисе белән аерылып тора. Балалар өчен язылган әсәрләрендә Мансур Сафинның осталыгы, таланты аеруча ярылып ята. Мансур Сафинның шигырьләрен мин үзем дә яратып укыйм. Безнең белән шигърият телендә иң табигый һәм үз булып сөйләүче шагыйрьләрнең берсе булганга, үзенчәлекле булып аерылып торганга, аның иҗаты мине үзенә җәлеп итте. Яраткан шагыйребезнең күп кенә шигырьләре тәрбияви әһәмияткә ия булуы да безнең өчен бик мөһим.

Мансур Сафин күпкырлы талантларның берсе. Ул русча да, татарча да, балалар өчен дә, олылар өчен дә яза. Аның тормыш тәҗрибәсе бай. Шуңа күрә әсәрләре тормышчан һәм халыкчан.



Табигатьне өйрәнүе, аның гүзәл сыйфатларын берөзлексез күңеленә җыюы язучыга иҗат эшен уңышлы дәвам иттерергә уңайлык тудыра. Үз әсәрләрендә автор өлкәннәрне дә уйландырырлык фикерләр әйтә. Бу әсәрләрдә хикмәт тә, гыйбрәт тә бар. Шагыйрь үзе дә бүгенге көндә балаларны һәрьяклап белемле, тәртипле, тәрбияле итү юнәлешендә иҗаты белән уңышлы адымнар ясый.

Күптән түгел генә үзәк китапханәдә Мансур Сафин белән очрашу кичәсендә булырга туры килде. Ул кичәдә М. Сафин шигырьләрен укыдылар, М. Сафин да чыгыш ясады, үз шигырьләрен укып, безне көлдерде, тормышка башкача карарга ярдәм итте. Аның шигырьләренә язылган җырлар җырладылар: «Әбиләр чуагы», «Ак каеным», «Яшьлегемнең моңсу яктысы», «Мамадыш таңнары», «Туган ягым», «Сагыш моңы», «Әрнүле җыр», «Әнкәй күңеле» һщм башкалар.Аларны профессиональ һәм үзешчән җырчыларыбыз бик яратып башкара.

Мансур Сафинның әсәрләрен күпләр укый һәм белә. Мансур Сафинның мәхәббәт, туган як, туган җир, табигать лирикасы, әниләргә, туган халкына багышланган кешелекле, игелекле әсәрләре бик тә популяр.

Туган җир һәм газиз ана. Бу ике төшенчә – шигъриятнең терәк нокталары, төп темалары ул. Әнкәй белән туган җир, туган туфрак бер-берсеннән аерылгысыз булып бәйләнгән төшенчәләр. Туган туфрак һәм иң кадерле кеше – ана турында язмаган шагыйрь юктыр. Мансур Сафин туган якны сөеп, туган телнең ләззәтен тоеп иҗат итә. Аның әсәрләре күңел кичерешләре, шанлы татар тарихын мәңге үз итү, дөньяга ихласи тугрылык белән сугарылган. Гомумән, Туган ягын, чордашларын ярату хисе аның күңел түрендә һич сүнмәс-сүрелмәстәй төстә ялкынланып тора:

*Татар илем – Ватаным да,*
*Татар илем – даным да!*
*Тәүге җирем – соңгы җырым,*
*Соңгы тамчы каным да.*

*Изге туфрак мизгелләрдә*
*Мәңгеләшкән җаным да:*
*Татар илем, туган илем –*
*Горурлыгым, шаным да!*

*«Туган илем»*

Шагыйрь халык, ил, җир хакында заман проблемалары зурлыгын тоеп фикер йөртә. Мансур Сафин – бүгенге чор шагыйре буларак, үз иҗатында заман рухын, үзенчәлекләрен аерым бер осталык белән тасвирлый. Мансур Сафинның шигырьләре әчтәлеге ягыннан гыйбрәтле. Алардагы туган җиргә, туган халкына, әти-әниләргә һәм якыннарына мәхәббәт, дуслык, намус, хезмәт сөю, батырлыкка омтылыш кебек әһәмиятле төшенчәләр бүген дә бик актуаль.

Мансур Сафинның таланты күпьяклы: ул Мамадыш төбәгенең тарихын өйрәнеп, «Край былинный, Мамадышский” китабын чыгара; бер-бер артлы татар һәм рус телләрендә шигъри җыентыклары дөнья күрә. «Аргамак»журналында аның мәкаләләрен укыйбыз. Рус шагыйрьләрен татарчага, татар шагыйрьләрен русчага да ул бик уңышлы гына тәрҗемә итә.

Мансур Сафинның иҗатын бик күпләр чиксез ихтирам итәләр. Язучыга булган хөрмәтен күренекле язучы, эзтабар Шаһинур Мостафин болай белдерә:

*...Бәхетле бул, Тәхетле бул,*
*Йөзеңдә торсын Кояш!*
*Дөньялар ямьләнеп китә*
*Син шулай балкып торгач!*

Мансур Сафин хәзерге көндә Чаллы шәһәрендә яши һәм иҗат эше белән шөгыльләнә. Мансур Сафинга – халкыбызның талантлы һәм күренекле улына мин дә изге теләкләремне юллыйм: сәламәтлек, гаилә бәхете, озын гомер, иҗади уңышлар телим.

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Әсәнов, Г. Унөч сорау Мансур Сафинга / Г. Әсәнов // Заман. – 2002. – №1 (гыйнв.).
2. Газизов, М. Өлгер каләм иясе / М. Газизов // Аргамак. – 1995. – №8. – Б. 113-115.
3. Гомәрева, З. Чаллы язучысы бенефисы / З. Гомәрова // Шәһри Чаллы. – 1996. – 20 дек.
4. Сафин, М. Край былинный, Мамадышский: краеведческий сборник. – Вып. 1. / М. Сафин. – Наб. Челны, 1994. – 64 с. – 2000 экз.
5. Сафин, М. Мамадыш таңнары: шигырьләр / М. Сафин. – Мамадыш, 1992. – 46 б. – 4000 д.
6. Мансур Сафин: Библиографик күрсәткеч/ Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсе; төзүче: Р. Г. Хәмидуллина. – Яр Чаллы: 2007. – 144 б.
7. Сафин, М. Сербакчага сәяхәт: табышмаклар / М. Сафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 24 б.
8. Сафин, М. Сыерчык бураны: шигырьләр, табышмаклар / М. Сафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 48 б.
9. Сафин, М. Хәерле иртә: шигырьләр / М. Сафин. – Чаллы: КамАЗ, 1994. – 64 б.



***Илсия МӨХӘМӘДИЕВА,***
*Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының туган якны өйрәнү бүлеге библиографы*


## МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ
## (Амур Фәләх әсәрләренә нигезләнеп)

Бүгенге көндә дә татар милләтенең торышы – актуаль мәсьәләләрнең берсе булып санала.

Амур Фәләх милли рух һәм халыкчанлык белән сугарылган әсәрләренең үзәгенә милләт язмышы мәсьәләсен куеп, әлеге проблеманы төрле яссыллыкта яктырта. Бер төркем әсәрләрендә ул, милләтне инкыйраздан саклап калу максатында, укучының игътибарын халыкның милли яшәешенә, милли колоритына, күркәм гореф-гадәтләренә, милли йолаларына, нәселнәсәбәсенә, борынгы тамырларына юнәлтә.

Амур Фәләх – тәүге әсәрләреннән үк милләт язмышын алгы планга чыгаручы реалист язучы. Аның һәрбер әсәренең нигезенә милли идея салына. Дине, теле, мәдәнияте, гореф вә гадәтләре бер булган кешеләрдән барлыкка килгән җәмгыяткә (халыкка) милләт диләр. Милләт өчен аеруча әһәмиятле булган мәсьәләләр – үз динен һәм мәдәниятен саклаудыр. Бу мәсьәләләргә җитәрлек игътибар бирелмәсә, халык югалыр.

Бүгенге көндә дә татар милләтенең торышы – актуаль мәсьәләләрнең берсе булып санала.

Амур Фәләх милли рух һәм халыкчанлык белән сугарылган әсәрләренең үзәгенә милләт язмышы мәсьәләсен куеп, әлеге проблеманы төрле яссылыкта яктырта.

Фәләхов Амур Нур улы 1965 елның 10 сентябрендә Татарстанның Мамадыш районы Яңа Комазан авылында дөньяга килә. 1972-1982 нче елларда Көек-Ерыкса урта мәктәбендә белем ала. Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый.

1992 елның ноябреннән «Яңарыш» газетасында махсус хәбәрче булып эшли башлый. Бераздан җаваплы сәркатип итеп билгеләнә. 1997-1999 нче елларда «Яңарыш»ның баш мөхәррире вазифасын башкара. Амур Фәләх – бихисап публицистик мәкаләләр, актуаль мәсьәләләр күтәрүче, милли тормышны пропагандалаучы язмалар авторы.

1998 елда ул Россия журналистлар берлегенә кабул ителә. 2001-2008 нче елларда Чаллыда чыгып килүче «Мәйдан» әдәби-нәфис, иҗтимагый журналының җаваплы сәркатибе, публицистика бүлеге мөдире, бүлек мөхәррире вазифаларын башкара. Чаллы шәһәре инвалид спортчыларның «Идел-Урал» хәйрия фонды матбугат үзәгендә эшли.

Хәзерге вакытта – «Безнең фикер» газетасының оештыручысы һәм баш мөхәррире.

Публицистик язмалар белән беррәттән әдәби әсәрләр дә иҗат итә. Язмалары матбугатта Амур Фәләх, Әмир Ханов, Нур Әхмәт, Фәләх Комазани псевдонимнары белән нәшер ителә. «Таш бәгырь» җыентыгы (2004) һәм «Мәйдан» журналында басылып чыккан тарихи-публицистик язмалары өчен 2007 елда Шәйхи Маннур исемендәге премиягә лаек була. 2010 елда Татарстан китап нәшриятында «Зимагур» дип аталган әсәрләр җыентыгы дөнья күрә. 2015 елда Удмуртия һәм Татарстан Язучылар берлекләренең Риза Шәфи исемендәге әдәби премиясенә лаек була.

Китапның исеме беренче карашка укучыны сискәндереп җибәрсә, икенче яктан кызыксыну уята. «Зимагур». Без яшьтән үк ишетеп үскән: «зимагур бит ул, аңа ышаныч юк», сүзе колак төбемдә яңгырагандай булды. Чит җирләрдә авылын, туганнарын да онытып йөргән, ышанычсыз кешеләргә әйтелә иде бу сүз. Ә автор бер дә шикләнүсез тулы бер җыентыкны «Зимагур» исеме белән чыгара. Һәм дөрес эшли, шул рәвешле, китап укучыда кызыксыну уята. Китап «Зимагур» повесте белән башланып китә. Автор повестьны озак еллар авылдан читтә яшәгән Харис гаиләсен тасвирлаудан башлый. Монда аны белүче дә, танучы да сирәк, көтүче дә юк.

Үзе дә белми торган бер матур мөнәсәбәткә өметләнеп кайткан Харисның бер мизгелдә барлык өметләре юкка чыга: «Нишләп йөрим инде мин? Нәрсәгә өметләнәм?», – дигән сорауларны үзенә еш бирә. Ләкин инде олыгаеп бара, яңа корган гаилә учагында да тынычлык таба алмый. Туган яктагы гаиләсенә, яшьтән бергә булган кешесенә өметләр баглап, янәдән кайта. Сөйләшер, уртак шатлыклар юклыгын күрешкәч аңлый: “Ике дистә ел чамасы элек бар нәрсәгә кул селтәп, үзем китеп барган идем бит.



Туган җирен язмыш кочагына ташлап качкан адәмне авылдашлары ничек кичерсен инде?! Хыянәт иттем ләбаса, хыянәт иттем...» – үзен-үзе юату юлларын таба.

Бу сүзләрдән аңлашылганча, әле кылган гамәлләренә үзе җавап бирә ала торган, ул кадәр үк түбәнчелеккә төшмәгән кеше булуы аңлашылып китә. Харис яшьтән үк белемгә омтылып үскән, тырыш, гади крестьян баласы. Менә шул тырышлык, омтылулар аны шул хәлгә китерә дә. Аның тормыш юлында һәр кылган гамәленә дөрләтеп, очкын өстәп торучы кешеләре дә табылып тора. Автор «Зимагур» повестенда тасвирлаган Харис образы аша, 30 нчы еллар шаукымына эләгеп үз йөзен, туган илен, яраткан кешесен, гаиләсен югалткан, гомумән, үзен югалткан бик күпләрнең образын тудыра.

Китапка кергән «Сабантуй» хикәясе истәлекләр белән үрелеп бара. Төп герой булган Әхәт балачак елларын, яшьлеген сагынып, туган якларына Сабантуена кайта. Ул бәйрәм итеп үскән Сабантуеның әсәре дә юклыгына кайтып-кайтып исе китә.

Авторның «Өмет» хикәясе белән тагын бер кат: «Әдәм баласының соңгы көненә кадәр нәрсәгәдер өметләнеп яшәвенә инанасың». Тормыш көзендә бер ялгызы калган Фәриткә кыен, бик кыен. «Дөрес әйткәннәр, әй: хатын-кыз, ялгыз калса, ничек тә түзә, тырышып-тырышып яшәргә маташа әле ул, ә менә ир-ат... Караңгы базда берүзе калган чебен кебек-тегендә барып бәрелә, монда барып сугыла...» – дип аның халәтен тасвирлап яза.

Фәрит наз, үз җылысын бирергә теләп, ятимнәр йортыннан бала алырга тели. Юк шул, юк, язмаган. Хикәяне укып танышканнан соң, каты авыру аның соңгы өметен дә сындыруы ачыклана.

Амур Фәләхнең «Сукбай» хикәясе аша, янәшәбездә яшәгән битараф яшьләрнең кылган гамәлләре аркасында, вакытлыча йортсыз, гаиләсен «онытκан» Хәниф абый тасвирлана. Без көн дә күреп, инде күнеп беткән, үзебез яшәгән подъезд сукбайларының, төп геройның кичергәннәрнең, үз җилкәләрендә кичермәгән, – диеп кайсыбыз әйтә ала. Сукбай тормышына калу тиз икән, моннан бер кемдә гарантияләнмәгән. Хикәяшуңа ишарә.

«Бәхет пилмәне» хикәясе, темасы таныш булса да, берәүне дә битараф калдыра алмас. Минневафа апа, Санияләр язмышы сугыш елларында һәркемне һәр җирдә сагалап кына тора. Сания бала вакыттан күңеленә сеңеп калган «Бәхет пилмәне»ннән курка. Төп герой татыган «бәхет пилмәне» башка, үзгә шул, ул аны беркемгә дә ашатасы килми.

«Таш бәгырь» повестында төп герое – Әмир. Ул автор тарафыннан үрнәк герой буларак тәкъдим ителә: туры сүзле, дусларына ярдәмчел, әти-әнисе, энесе-сеңлесе өчен җан атырга әзер. Шулай да җитәрлек дәрәҗәдә көчле түгел, дусты Азатка да, энесе Хәмиткә дә, сеңлесе Ләйләгә дә ярдәм итә алмый, чөнки җәмгыять үзе шундый. Шуңа күрә дә Әмирнең үлеме котылгысыз, хакыйкатьне ачып салырга батырчылык иткән шәхесләр ялганга, акчага, вәхшилеккә корылган җәмгыять тарафыннан юк ителүгә дучар.

Повестьта таш символик образы игътибарны җәлеп итә. Әлеге образ әсәр исеменә дә чыгарылган. Әсәрнең композициясе дә шушы таш тирәли эшләнгән кебек: беренче мәртәбә укучы Әмир белән аның мәйдан уртасындагы зур ташка сөялеп, уйланып утырган чагында очраша, төп геройның гомере шушы таш янында өзелү исә әсәрнең тәмамланганын хәбәр итә.

Таш символы горурлык мәгънәсенә дә ия: «...мәйдан уртасында горур кыяфәттә торучы зур ташка барып сөялде». Әлеге образның тагын бер мәгънәсе үлем: Әмир базда саташып яткан вакытта Азат өстенә таш килеп төшүен күрә, төп геройның гомере дә таш янында өзелә.

Повестьнең сюжетын традицион өлешләргә бүлеп карарга мөмкин. Экспозиция өлешендә автор укучыны төп герой белән таныштыра, кыскача гына аның сугышка килеп эләгү тарихын бирә, мондагы хәлләргә, «комендант сәгате», «чистарту» кебек күренешләргә мөнәсәбәтен белдерә.

Чечен сугышына һәм, гомумән, җәмгыятькә яңа бәя бирү-авторның зур табышы. Төп хакыйкать тормышка деконструкция ясау, яңа сурәтләү яссылыгы табу аша тәкъдим ителә. Бу очракта авторның яңа-постмодернистик алымнарны куллануы, безнеңчә, аның уңышы дип саналырга хаклы.

Амур Фәләхнең хикәяләре тормышның үзеннән алынган, ул һәркем өчен таныш, якын.

**ӘДӘБИЯТ:**

1. Фәләх, А. Зимагур: повесть, хикәяләр / А. Фәләх. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 174 б.
2. Фәләх, А. Таш бәгырь: повесть, новелла, хикәяләр / А. Фәләх. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 127 б.
3. https://tt.wikipedia.org/wiki/Амур_Фәләх
4. http://matbugat.ru/news/?id=14178
5. http://adiplar.belem.ru/falah.htm



***Ләйсән ХӘЕРТДИНОВА,***
*Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының*
*8 нче санлы балалар китапханәсе мөдире*

## «БИКЛӘН» АВЫЛЫ БИКЛӘНГӘН, ТИК ЙӨРӘГЕНЕҢ ТҮРЕНӘ (Рәзинә Сәетгараева иҗатына багышлана)

*Бер нәни кыз урам буйлап атлый,*
*Җитәкләгән сукыр әтисен.*
*Я, ходаем, бер мизгелгә генә,*
*Ал син аның кара пәрдәсен.*

*(«Күңел күзе»)*

Күңелләрне тетрәндерерлек итеп язылган әлеге сүзләрнең авторы кем икән дигән уй кердеме? Сукыр кешенең авыр тормыш юлы үтүен тасвирлаган һәм сабый баланың кичерешләрен кем әйтеп бирә алды икән? Чыгышымны әлеге шигырь юллары белән башлавымның төп сәбәбе шул. Автор шигырьне үзенең газиз әтисенә багышлап яза. Безгә шигъри юллар белән гөлләр, җырлар өләшеп Тукай районының ямьле Биклән авылында яшәп иҗат итүче, Татарстан Журналистлар союзы һәм Татарстан Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы Рәзинә Габделбәр кызы Сәетгәрәева белән таныштырасым килә. Күңеле тулы моң Рәзинә Сәетгәрәева әдәбиятта гына түгел, ә сәнгать өлкәсендә дә ачылып килүче иҗат кешеләренең берсе: ул җырлар да иҗат итә. Аның җырлары Венера Ганиева, Резедә Шәрәфиева, Әлфинә Әзһәмова, Индива, Илнар Сәйфиев, Ринас Әхмәтов һәм башка җырчылар тарафыннан башкарыла.

Рәзинә ханым Биклән авылында ишле гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килә. 1976 елда урта мәктәпне тәмамлап, Бөгелмә исәп-хисап мәктәбендә укып, авыл хуҗалыгы бухгалтеры һөнәрен үзләштерә. Бик күп еллар туган авылының колхоз идарәсендә икътисадчы булып, хисапчылык өлкәсендә хезмәт куя.

1980-1984 нче елларда туган авылы мәктәбендә китапханәче вазифасын башкара. Нәкъ менә шул елларда үзен шигъриятта сынап карый. Кичә, бәйрәмнәрне үз шигырьләре белән бәйләп алып бара. Тора бара бу шигырьләр китап булып дөнья күрәләр. Алар «Моң чишмәсе», «Күңел сандыгы», «Күңелем догалары» һәм «100 бүләккә – 100 теләк» шигырь җыентыклары...

Иҗат җимешләре, көйгә салынып, «Сабыр итәм» һәм «Күңел күзе» дип исемләнгән музыкаль дискларда урын ала. Шигырьләреннән җанына дәва алганнан соң, аның тагын бер сәләте ачыла. Ул, бер нота танып белмәсә дә, күңеленнән көйләр чыгара башлый. Ул иҗат иткән җырлар «Татар радиосы» һәм «Күңел» дулкыннары аша еш яңгырый.

Бу өлкәдә аның иң зур уңышлары: көен дә сүзләрен дә үзе язган «Тукай исеме – бөек исем» дип аталган Тукай районы гимны. 2014 елдан район Сабантуе шушы гимн белән ачыла.

«Үземнең тормышымны туган авылым, аның кешеләреннән башка күз алдына да китерә алмыйм», – ди ул һәм бүгенгәчә аларга тугры булып кала бирә. «Туган якның тугры кошы» нәкъ менә Рәзинә Габделбәр кызына атап әйтелгән кебек.

*Туган якның язы матуррак!*
*Йөрәктә үк ата бөресе.*
*Умырзая чыккан мизгелләрне*
*Язлар саен килә күрәсе.*

*Туган якның кары йомшак, җылы!*
*Бураны да куәт, көч бирә.*
*Туган җирнең һәр почмагы гүзәл,*
*Һәр фасылы якын күңелгә.*

*(«Туган як»)*

Үзәкләргә үтеп керердәй итеп язылган «Бикләнем» җырының көен дә ул үзе язып, әлеге җырның клибын төшергәндә режиссерлык эшен дә үз өстенә алып, уңышлы гына башкарып чыга. «Бу хыялым инде күптәннән яши иде. Шөкер, горурланыр кешеләребез, авылдашларым бар», – дип куана ул.

Рәзинә Сәетгәрәеваның шигъри осталыгын күреп алып, аны «Якты юл» район газетасының хатлар бүлегенә эшкә чакыралар. Шулай ук ул редакциясе каршында укучылар өчен оештырылган «Каурый каләм» әдәби түгәрәген җитәкли. Анда эшләгән дәвердә ул үзенең яңадан яңа укучыларнын таба, зур тәҗрибә туплый. Һәм үзен шигъриятә генә түгел прозада да сынап карый.

Шулай итеп 2014 елда Татар китап нәшриятында Рәзинә ханымның «Түз, йөрәгем, түз… » («Терпи, мое сердце, терпи…») дип исемләнгән китабы дөнья күрде.

Бу әсәр тетрәндергеч, реаль вакыйгаларга нигезләнеп язылган. Монда ул 65 яшенә җитеп бер рәхәт тә күрмәгән, тол калып, ялгызы устергән ике газиз баласын югалткан гади татар хатыны – бертуган апасы Рәсимә образы гәүдәләндерелгән. Ул аны вакытсыз дөньялыктан киткән бертуган балалары Айрат белән Гөлнараның якты рухларына багышлап чыгарган. Әлеге әсәр күп басмаларда: Тукай районы газетасы – «Якты юл» да, «Акчарлак», «Безнең фикер» газеталарында, «Мәйдан» журналында басылып чыгып, үз укучыларын тапты, тетрәндерде, уйландырды.

«Бу китапка нинди исем бирер идегез?», – дип сорасалар, шәхсән мин бер дә уйламыйча «Татар хатыны ниләр күрми», – дияр идем.

Рәзинә апа үзенең биографиясенең иң якты бите – «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә килеп керүем», – дип белдерә. Урау юллар аша үзен табып, бүгенгесе көндә шагыйрьлеккә укый һәм композиторлык серләренә төшенә.

Жанр буенча карасак, Рәзинә ханымның иҗатында түбәндәге төрләр бар: пейзаж лирикасы, гражданлык лирикасы, күңел лирикасы, мәдхия, мөнәҗәт, бәет, багышлаулар. Багышлаулары үзенчәлекле: кешенең биографиясен шигырь юллары белән яза, аның уңай сыйфатларын күрсәтә. Тагын очерк, мәзәк, репортаж, котлаулар иҗат итә.

Тематик яктан караганда шигырьләрендә әйдәп баручы төп темалар булып: туган як, ата-ана кадере, яшәү мәгънәсе, мәхәббәт, тарихи шәхесләргә багышланган шигырьләр тора.

Кешеләргә изгелек, яхшылык кылу аның канында, җанында. «Көн саен ун рәхмәт ишетмәсәм, йоклый алмыйм», – дип шаярта ул.

Рәзинә апа Габделбәр кызы – тырыш, хыялый кыз бала сыман, самими, эчкерсез, иҗаты белән бәхетле шагыйрә дип саныйм мин. Иҗатының татлы җимешләрен тоеп яшәү аңа көч, илһам өсти.

*Әллә инде әтинең дә күзен,*
*Миңа бирден, күпне күрәмен!*
*Әниемнең хыял канатларын,*
*Хискә манып иңгә тегәмен…*

– дип яза ул үзенең «Я, бер Аллам, сина ышанам» дигән шигырендә.

**ӘДӘБИЯТ:**

1. Сәетгәрәева, Р. Күңел сандыгы: шигырьләр / Р. Сәетгәрәева. – Казан: «Идел-Пресс», 2009. – 304 б.

2. Сәетгәрәева, Р. Күңелем догалары: шигырьләр / Р. Сәетгәрәева. – Казан: «Идел-Пресс», 2013. – 376 б.
3. Сәетгәрәева, Р. Түз, йөрәгем, түз...: Бәян / Р. Сәетгәрәева. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2014. – 63 б.

***Резеда ГАЙНЕТДИНОВА,***
*Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге мөдире*

## ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЫ
## (Зифа Кадырова иҗатына нигезләнеп)

Соңгы вакытта татар әдәбиятында хатын-кыз язучыларның активлашып китүе күркәм күренеш. Мәсәлән, өлкән прозаик Ләбибә Ихсанова, фикерләү пөхтәлеге, кеше күңеленең бик тирәндә яткан кичерешләрен нәфис итеп бирә белү белән аерылып торучы Мәдинә Маликова, үзенә генә хас үзенчәлекле язучы буларак килеп кергән һәм «Тулгак» повесте белән зур популярлык казанган Гөлчәчәк Галиева. Әсәрләрендә хатын-кыз күңеленең, җанының иң ачы, авыр газапланулы якларын ачып сала алган Фәүзия Бәйрәмова, сәнгатьчә матур образлар, мавыктыргыч сюжетлар, борынгы мифологик мотивлар аша хатын-кыз образларын чагылдырган Нәбирә Гыйматдинова кебек язучыларыбыз хәзерге татар прозасы күгендә әдәбиятыбызны, культурабызны үстерүдә зур өлеш керттеләр.

Хатын-кыз проза иҗаты мәйданында Зифа Кадырова да үз урынын алды.

З. Кадырованың кулына каләм алып әсәрләр яза башлавына бик аз гына вакыт булса да, аның «Сагынырсың мин булмам», «Язмыш сынавы», гомер буе кемне дә булса көтеп яшәргә мәҗбүр Фатыйма, каты авырудан һәм хыянәт ачысыннан сыгылып төшәргә ашыкмаган Рушания, чәчләренә чал төшкәнче тәүге мәхәббәтен уйлап яшәгән Асылгәрәй язмышын бер китапка туплаган «Көтеп узган гомер», «Бәхеткә юл кайдан?», күптән түгел генә дөнья күргән «Синсез килгән язлар» повестьлары укучылар тарафыннан яратып кабул ителде.

Әлеге әсәрләре белән ул зур популярлык казанды. Хатын-кызның кичерешләрен сирәк ир кешеләр генә аңлый, әдәби әсәр аша тәңгәл җиткерә, әнә шуңа күрә әдәбиятыбызның үзәккә кеше язмышы, хисләре куелган һәр китабын диярлек татар укучысы үз итә.



Әдәбият сөючеләрнең күпчелеге хатын-кыз булу бәхәс уятмыйдыр дип беләбез. Ә хатын-кыз исә үзенә якынны, чын тормышны реалистик буяуларда чагылдырганны яратарак төшә. «Аның «Сагынырсың мин булмам», «Язмыш сынавы», «Көтеп узган гомер» дигән китапларын татар укучылары инде менә ничә ел кулларыннан төшермиләр. Автор тормышның бик авыр, четерекле катламнарына кыю үтеп керә һәм шул катламнарны бер генә урыннан түгел, ә бәлки озын гомер юллары, дәверләр масштабында әйләндереп сөреп бирә. Аның әсәрләрендә башларны югалтырлык кайнар мәхәббәт, көтелмәгән хыянәт, тормыш юлларындагы ялгышлар, тетрәнүләр, газаплар, ачы югалтулар һәм татлы күз яшьләренә манчылган бәхетне табу мизгелләре...

Зифа Кадырова кеше язмышларын аяусыз тикшерә, геройларын утлар-сулар аша кичереп, һәркайсына үз хөкемен чыгара. Китапларының яратып укылуының да сере шундадыр», дип яза Фоат Садриев.

З. Кадырова әсәрләрендә укучыны үз бәхетең өчен гомер буе көрәшергә кирәк дигән максат куеп яшәргә, кичерә белергә, үчләшмәскә өнди.

«Хатын-кызның тормышны җигелеп тартуы, ләкин бервакыт тәмам алҗып егылуы, кайбер әзмәвердәй ир-атның хатынының арык җилкәсе артына гына ышыкланып яшәве, аларның көчсезлеге борчый мине. Тормыш дилбегәсен ирләр каты кулларында тотарга, ә хатын-кыз сабыр акыллы һәм зирәк булырга тиеш дип чаң сугам әсәрләремдә. Китапларымны укыган һәркем үзенә сабак алсын, башкалар ялгышы гыйбрәт булсын, язмыш сынауларына бирешмәсен иде дигән максат куеп язам», – ди язучы.

Хатын-кыз... Нечкә билле, сылу гәүдәле, кыйгач кашлы, кара күзле, озын толымлы татар хатын-кызлары... Кем генә сокланмый аларга! Матур булуларына карамастан, үтә тыйнак, җыйнак, сабыр, түземле, кунакчыл, сынмас рухлы, батыр йөрәкле, үзенең милләте, дине өчен гомерен дә кызганмаган хатын-кызларның язмышлары кемнәрне генә кызыксындырмый да, кемнәрне генә борчымый?!

Шул исәптән З. Кадырова әсәрләрендә дә хатын-кыз сабырлыгы, сынауларга дучар ителгән яралы язмышлар, шатлыгын да, газабын да үзенә сыендырган мәхәббәт – төп темаларның берсе булып тора. Язучы һәрдаим уй-тойгыларын, әйтергә теләгән фикерен образлы, үтемле яңгыратырга омтыла. Сызлану, ачыну аша яхшылыкка, бер-береңне аңларга чакыра, бу чакыру сүз-текст аша гына түгел, бәлки җан тирбәлешенә корылган ачыну, моң аша алып барыла. Ул әсәрләрен фәлсәфәгә кормыйча, табигать күренешләрен сурәтләү белән мавыкмыйча,

тел сурәтләү чараларына тирән кереп китмичә, гади, аңлаешлы итеп яза, шул ук вакытта, хатын-кыз тормышын чагылдырган әсәрләргә сусаган укучының күңелен тибрәтә, китапка карата кызыксындыру уята. Автор образларны, вакыйгаларны сиземлерәк итеп сурәтли, аларга үзенчәлекле төс кертә, әсәр теленең халыкчанлыгын, гадилеген, аһәнле яңгырашын тәэмин итә. Үзәк героиня образларын тудырганда З.Кадырова үзен оста портретчы итеп тә таныта, героиняларын гомумән татар кызларына хас күркәм сыйфатлар белән күз алдына бастыра: «Сөмбелдә әллә нинди яшерен сөйкемлелек бар, кыйгачланып киткән калын кара кашлы шаян күзләр һәрвакыт елмаеп тора кебек: ул көлгәндә, аның күзләре дә көлә».

З.Кадырова үзенең иҗатында баштан үткән яки бүтәннәр тормышыннан алынган гыйбрәтле хәлләргә таянып эш йөртә. Әдәби белеме булмаса да, укучыларны кызыксындыра алырлык борылышлар ясый белә. Һәркемгә үтә таныш хис-тойгыларны үзәкләрне өзәрлек итеп тасвирлап, бик күпләрне үзенә әсир итә: хата-ялгышларыңа да башка күздән карыйсың, Аллаһы Тәгалә бүген сиңа биргән һәр нәрсәгә шөкер итәргә кирәклеген тоясың, оялып куясың, чистарынасың. Үз чиратында, авторның рухи агарту көч-кодрәтенә ия икәненә инанасың.

Әдәбият белгече, язучы Галимҗан Гыйльмановның сүзләре урынлы килә: «Зур әдәби мәктәбе булмаса да, интрига, укучыларны тота алырлык борылышлар ясый белә. Елый-елый укыганнарын беләм, үз күзләрем белән күрдем. Ләкин әле, әлбәттә, үсәсе бар. Мин аңа сокланам һәм уңышлар телим. Ул – гади укучылар өчен бик зур ачыш. Аларның гамен, борчуын, омтылышын, хыялларын язганга якын, укучыларга тормыш серләрен ача. Соңгы вакытта хатын-кыз образын тудыручы язучылар юк иде, аның әсәрләре бу бушлыкны да тутыра», – ди ул.

Язучы бәхете менә шул буладыр инде ул. Кайбер әдипләр халык китап укымый дип чаң сукканда, гади халык әсәрләреңне көтеп алып, китабыңны бер төндә күз яшенә буылып укып чыгып, аны башкаларга тәкъдим итә, китапханәләрдәге китабыңны кулдан-кулга йөртеп, туздырып бетерәләр икән, каләм остасы өчен моннан да зур бәхетнең булуы мөмкин түгел.

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Зарипова,Р. Кичерә белегез, үчләшмәгез / Р.Зарипова // Әгерҗе хәбәрләре. – 2013. – №10. – 8б.
2. Кадырова,З. Көтеп узган гомер. / З.Кадырова – Казан: «Идел-Пресс» нәшр., 2011. – 368б.





3. Кадырова,З. Сагынырсың, мин булмам. / З.Кадырова – Казан: «Идел-Пресс» нәшр., 2011. –304б.
4. Кадырова,З. Язмыш сынавы. / З.Кадырова – Казан: «Идел-Пресс» нәшр., 2012. – 336б.
5. Кадырова,З. Бәхеткә юл кайдан? / З.Кадырова – Казан: «Идел-Пресс» нәшр., 2013. – 256б.
6. Хәлиуллина,З. Укучылар төзүчене ярата, ә язучылар? / З.Хәлиуллина // Шәһри Казан. – 2012. – №2. – 20б.



***Зөлфия ШӘКҮРОВА,***
*Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының*
*12 нче санлы китапханәнең бүлек мөдире*


## СИРЕНЬ ЯКУПОВА ИҖАТЫНДА ТУГАН ЯК МОТИВЛАРЫ

Сирень Мөхиббулла кызы Якупова 1961 елның 26 августында Татарстан Республикасының Әлмәт районы Түбән Абдул авылында туа. 1978 елда Елховой урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Әлмәт төзелеш техникумында белем ала. Нәкъ шул елларда районның «Хезмәт байрагы « газетасында аның беренче шигырьләре дөнья күрә. Хезмәт юлын Әлмәт шәһәрендә башлап җибәрә.

1982 елда Сирень Якупова Чаллы шәһәренә килә һәм, башта КамАЗның агрегат, аннан соң кече литражлы автомобильләр җыю заводларында эшли. Шушы елларда аның шигырьләре, язмалары КамАЗның «Нур « газетасында даими басылып килә.

Туксанынчы еллар азагында Сирень Якупова «Ләйсән» әдәби-иҗат берләшмәсенә йөри башлый. 2003 елда «Йолдызлы уйлар» исемле тәүге китабы чыга. 2006 елда шагыйрә «Шәһри Чаллы» газетасы редакциясенә эшкә килә һәм 2013 елга кадәр шунда хезмәт куя. Шул чорда шәһәр һәм республика матбугатында аның бик күп кенә шигырьләре, хикәяләре, язмалары дөнья күрә, китаплары чыга. «Җирдәге җан ияләре берсен-берсе кабатламый. Уникаль дисәләр дә, мин үзем бик иртә дөньядан киткән әти-әниемнең турыдан-туры дәвамы, кабатланмышыдыр, ахрысы. Мәрхүм әтием бик оста рәсем ясаган булса, әнием җор телле, нечкә күңелле, шигъри җанлы иде. Сурәт белән язу осталыгына ия булуым белән мин тулысынча аларга бурычлы» – дип искә ала шагыйрә.

Сирень Якупова – 2011 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Хәзерге көндә Чаллы язучылар оешмасында эшли.

Шагыйрә Сирень Якупова зәвыклы, затлы шигъриятне үз итүчеләргә ят исем түгел. «Йолдызлы уйлар», «Ике гасыр баласы мин», «Яшәү сере», «Өстәгеләрдән дә өстә» китаплары, матбугатта даими дөнья күреп килгән шигырь-хикәяләре һәм үз фәлсәфәсе, гаҗәеп табышлары белән укучылар күңелен күптән яулады. 2014 елда, укучыларын сөендереп, «Кар юлы» шигырьләр җыентыгы Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. 2015 елда «Кар юлы» шигырьләр җыентыгы өчен Сирень Якупова бик зур мәртәбәле бүләккә – Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премиягә лаек булды.

«Йолдызлы уйлар» – беренче җыентыгы Яр Чаллы нәшриятында 2003 елда басылды. Шигырьләрендә авторның дөньяга, тормышка карашы, кешеләргә һәм туган җиргә мәхәббәте чагыла.

*Туган җиргә – үз җиремә кайттым.*
*Рәхәтлеге шушы кайтуның!*
*Арган йөк атыдай, тугарылып,*
*Болын түшәгендә ятуның!*

*Җанны ярып үлән исе керә,*
*Чәчәк төсе тула күзләргә.*
*Җилфер-җилфер күбәләкләр куна*
*Чыктан юешләнгән тезләргә.*

*(«Кайту»)*

Һәр шагыйрь үз иҗатында үткәнне, бүгенгене, киләчәкне чагылдырырга омтыла, чын шигърият шулай гына яши ала, шуның белән генә кадерледер ул. Сирень Якупова шигърияткә зур җаваплылык белән килә, укучы кабул итәрлек әсәрләр генә иҗат итәргә тиешлеген аңлап эш итә. Ул туры фикерле, гадел шагыйрә, ул күңеле кушканча яза, иҗат итә.

*Уйламыйча әйткән чагым бардыр,*
*Уйламыйча язган чагым юк.*
*Әйткәннәрне кире ала алсам,*
*Язганнарны кире алу юк! –*

дип яза ул үзенең шигырендә.

Сирень Якупова – үзенчәлекле шагыйрә. Сәясәт, сугыш, гомумән, заманның караңгы яклары турында язарга яратмый ул.



Шагыйрә шигырьләрендәге ихласлык, тормышка, туган якка мәхәббәт хисләре тирәннән тибеп чыккан, шуңадырмы, алар һәр йөрәккә барып җитәрдәй көч-кодрәткә ия. Бу шигырьләр ышандыра, тулысы белән биләп, үзләренә тартып торалар:

*Язгы иртә, ә мин гүя сабый,*
*Таң җиленнән үргән бишектә*
*Имеп ятам сөтле яшеллекне,*
*Кош сайравын гына ишетеп.*

Шагыйрә һәр сүзнең тәмен, ямен тоеп, ихлас яза. Бүгенге кырыс заманнан яктылыкка, сафлыкка омтыла.

Гасыр чиген атлап XXI гасырга аяк басканда, Сирень Якупованың «Ике гасыр баласы мин» дип аталган яңа китабы аваз сала. Әлеге исем астында чыккан китабы язучы һәм шагыйрь, Абдулла Алиш исемендәге бүләк иясе Рәшит Бәшәрнең сүз башы белән дөнья күрә. «Сирень Якупова шигырьләре ирләрчә кырыс. Яшь түгү, уфтанулар юк аларда. Ул шигырьгә охшаш такмаклар түгел, шигъри мәрҗәннәр тезә. Җанны җылыта торган, сулышны иркенәйтә торган чын шигъри мәрҗәннәр… Ул, минемчә, рухы белән урыс шагыйрәсе Анна Ахматовага якын… ».

«Яшәү сере» – шагыйрә Сирень Якупованың Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән беренче китабы. Язмыш җилкәне ак шикәрдән аклы, хыяллары таулардан да биек шагыйрә укучыга бер-бер артлы яшәү серен ачарга керешә.

*Сандыгымда өч күлмәк,*
*Өчесе дә ап-актан.*
*Ак киләвем, туй күлмәгем,*
*Ак кәфенлек… азактан.*

*(«Сандыгымда өч күлмәк»)*

«Сандыгымда өч күлмәк» шигыре кешенең туганнан алып соңгы мизгеленә кадәр яшәгән гомере өч күлмәккә сыеп беткәнен аңлап язылган. Шигырьне укыгач гомер көзенә кергән һәр кеше туу, яшәү, үлем, аклык, караңгылык төшенчәләре турында тирәнтен уйлана башлый.

Хисләрнең төзек хәрәкәттә, эзлекле булуы шигырьне җегәрле итә. Беренче шигырьдән башлап, китап ахырына кадәр укучыны шушы төзеклек, хисләрнең чынлыгы озата. Бу шигырьләр ышандыра, тулысы белән биләп, үзләренә тартып торалар.

Яшәүнең сере нидә? Яшәү сере шигырьдән шигырьгә ачыла бара. Сирень Якупова исә кабаланмый, каударланмый һәм иң мөһиме-кабатланмый сер чишә дә чишә. Татар халкының бүгенгесе һәм киләчәге, туган тел, ил язмышы турында уйланганда шагыйрә үзенең гүзәл холыклы, бу мәсьәләдә үз үлчәме, үз фикере булган, милләтне чын күңелдән кайгыртучы шәхес икәнен күрсәтә.

Язучы, шагыйрь, Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе Факил Сафин китапка бәяләмәсендә мондый сүзләр яза: «Сирень Якупова тормышка, уйлап тапкан шигъри дөньясына кечкенә итеп уйган тәрәзә аша түгел, кайнап торган тормышка зур тәрәзә-үзе күргән, үзе кичергәннәр аша карый белә. Дөнья кеше алдына нинди генә сынаулар китереп куйса да, ул кеше биеклегендә кала алырга тиеш…». «Әйе, дөнья кырыс. Безнең пәрдәсез күңелләргә, ялангач җаннарга замананың күзе дә тия, сүзе дә тия. Йөрәкләр тоташ яра дисәк тә ялгыш булмас. Ләкин, шулай да, мин үземне тормыш сынауларын сынмый-сыгылмый үтәрлек көчле шәхес дип саныйм. Ни дисәң дә, мишәр кызы бит.. ».

*Гөрләп торган Биләр ягыннан мин,*
*Җырлап торган мишәр ягыннан.*
*Булыр микән миндәй шушы якны*
*Янып сөйгән, өзелеп сагынган.*
*Булыр микән миндәй горурланган,*
*Мишәрчә сүз укып шигырьдә.*
*Кандалыйлар, Туфаннарга якташ*
*Мишәр кызы бит дип үзем дә, –*

дип яза С. Якупова «Ана телем» шигырендә. Шагыйрә йөрәгендә кайнарлыгы сүрелмәс газиз, тылсымлы бер урын бар. Ул әти-әнигә, туган якка, туган нигезгә булган изге хисләрдән кабынган мәңге сүрелмәс учакны хәтерләтә.

*Кычыткан өзәм даруга,*
*Кулым түзә чагуга.*
*Бармаклар ни, йөрәгемнең*
*Уттай янган чагы ла…*
*Туган авылым кычытканы,*
*Пешер җанымны, пешер*
*Ялантәпи балачакны*
*Елатып искә төшер.*

*(«Кычыткан»)*



Язмышын шәһәр белән бәйләгән авыл кызы, балачагын, яшьлеген, туган авылын сагынып, юксынып шигырьләр иҗат итә.

*Авылыма алып кайтыр юл –*
*Юлларның юлыдыр ул.*
*Һәр чокыры мөлдерәмә*
*Сагыну тулыдыр ул.*

*(«Авылыма алып кайтыр юл»)*

Шәһәрдә торса да, җаны белән авылда ул. «Таш пулат бар, корыч ат бар, ә күңел-ярлы, ятим», дип моңланган авыл агайлары, авыл апалары янында аның күңеле.

*Шәһәр урамнары төз дә соң,*
*Күңел урамнары сагышлы, –*

дип җырлаган шагыйрә өстәгеләрдән дә өстәге Ходайга таяна, шул аңа яшәргә көч, язарга илһам бирә.

Туган як, туган җир дигәндә ни өчендер шәһәр түгел, ә авыл һәм аның бер өлеше булып торган табигать күз алдына килә. Һәрберебезнең дә тамырлары барыбер авылга барып тоташа. Авылның иң күркәм сыйфаты булып аның табигатьтә урнашуы тора. Һәр кешенең үз ягын, аның матур табигатен, суларын, күлләрен мактарлык җирләре күп.

*Туган йортым…*
*Менсәм аның түбәсенә,*
*Бер шигем юк, түбәм күккә тиясенә..*

*(«И түбәннән агылалар бу болытлар»)*

«Туган йортым» дигән шигырендә дә шагыйрә туган авылының матурлыгына мәдхия җырлый.

*Бу кадәрле якын булыр икән*
*Гади генә авыл ызбасы!*
*Туган йортым,*
*Син – Мәккәсе җанның,*
*Күңелемнең изге кыйбласы….*
*Бар хисләрем, бар рәхмәтем сиңа,*
*Туып үскән нәни бер оям.*

*Киң дөньялар кысан, тар чагында*
*Сиңа әле һаман мин сыям.*

*(«Туган йортым»)*

«Ике меңгә якын йортлы авылыбызны урталай бүлеп аккан тирән сулы, тиз агышлы Шушма елгасы, шомыртлы әрәмәләр, болыннар, Хөббәт бабам юлын ачкан Олы болын чишмәсе – бар да күңелгә якын, кадерле», – дип яза Сирень Якупова.

*Туган җирнең төтене дә татлы...*
*Минем өчен*
*Бу сүзләрдә булгандыр ла хаклык...*
*Учаклар сүнмәгән,*
*Мичләр сүтелмәгән,*
*Самавыр гөрләгән чакны...*

*(«Туган җирнең төтене дә татлы... »)*

2011елда С. Якупованың «Өстәгеләрдән дә өстә» дигән китабы басылып чыкты. Китапка шигырьләр, хикәяләр, эсселар тупланган. Шагыйрә бу китабында үзенең күңеленә якын булган бер теманы да читләтеп үтми. Шәһәрдәге күптөрле проблемалар турында язамы шагыйрә, бүгенге яшәешебез хакында уйланамы, каләмдәшләре иҗатын бәяләп сүз әйтәме – һәр сүзе, һәр гамәле халык язмышына килеп бәйләнә. Уйландыра, битараф булмаска чакыра.

**Шагыйрә турында иҗатташ дуслары:**

«...Сирень Якупованың шигырьләрендә мин шактый микъдарда серле табышларга тап булдым дип әйтә алам. Нинди куаныч! Ниндидер бер шәһәр-төбәкнең шагыйрьле булуы – ул серле булу, бәхетле булуга тиң. Андый каләм ияләре белән аерым йорт, аерым гаилә тәрәзәсе генә түгел, барлык шәһәр, хәтта милләт яктыра. Милләт җылына.», – дип яза язучы Айдар Хәлим.

«...Сирень Якупова – шигърияттә үз урынын тапкан талант иясе. Аның иҗатында күтәрелгән төп мәсьәлә – ил һәм халык язмышы. Ул шигырьләрендә -авылга, кешеләргә, дөньяга һәм туган җиребезгә булган мәхәббәтен чагылдыра, язмышка, җәмгыятькә үз карашын белдерә, шуны тормышчан дөреслек белән, кырыс һәм төгәл детальләр аша табигый итеп сурәтләргә омтыла», – дип тасвирлый шагыйрә Әлфия Ситдыйкова.



Ә ветеран укытучы Зәбир Хәлимов «Сирень Якупова шигырьләрендә никадәрле фәлсәфи фикер, һәр күңелне тырнап ала торган темалар! Шагыйрә иҗатының киңлегенә, аның күңел диңгезенең тирәнлегенә сокланмый мөмкин түгел. Ул һәр яңа көнгә, мәхәббәткә мәдхия җырлый, туган якны, әниләрне сагынып елый, туган теле өчен кайгырып уфтана, вакыт-гомернең кыскалыгына аһ ора, милли гореф-гадәтләребезнең юкка чыгуына сызлана, яшьлеген уйлап газаплана. Җиребезне кадерсезләгәнгә борчыла...», – дип үз фикерен җиткерә.

Безнең 12нче санлы татар китапханәсендә дә шагыйрәнең иҗаты белән таныштыру, укучыларга җиткерү буенча аның иҗатына багышланган бик күп матур әдәби чаралар уза. 2013 елда китапханәдә «Ак җилкәнле шигырьләр» дип исемләнгән шигърият кичәсе, 2015 елда 60 нчы мәктәпнең югары сыйныф укучылары өчен «Шигырь белән тулган барлык җиһан « дип аталган әдәби кичә, 2016 елда «Серле тормыш бары җирдә генә» дип аталган шигъри – музыкаль кичә үткәрелде.

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Әхмәтгалиева, А. Серле тормыш бары җирдә генә: [иҗаты турында] / А. Әхмәтгалиева // Шәһри Чаллы. – 2014. – 24 окт.
2. Бәшәр, Р. Сүз бәясе: [шагыйрәнең «Өстәгеләрдән дә өстә» китабы турында] / Р. Бәшәр // Шәһри Чаллы. – 2011. – 18 май.
3. Гасыймова, Р. Яңа гына ачтым күземне...: [гаиләсе, иҗаты турында] / Р. Гасыймова // Шәһри Чаллы. – 2000. – 13 май.
4. Журналның Сирень Якупова иҗатына багышланган махсус саны // Мәйдан. – 2014. – №9.
5. Сафин, Ф. Ак җилкәнле шигырьләр: [«Яшәү сере» китабы хакында уйланулар] / Ф. Сафин // Шәһри Чаллы. – 2009. – 4 март.
6. Ситдыйкова, Ә. Шигырьләрендә җан авазы: [иҗаты турында] / Ә. Ситдыйкова // Шәһри Чаллы. – 2006. – 20 дек.
7. Хәлим, А. Шигърият сере: [«Яшәү сере» шигъри җыентыгы хакында] / А. Хәлим // Шәһри Чаллы. – 2010. – 15 дек.
8. Якупова, С. Яшәү сере: шигырьләр / С. Якупова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 127 б.
9. Якупова, С. Өстәгеләрдән дә өстә: шигырьләр, хикәяләр, эсселар / С. Якупова. – Яр Чаллы, 2011. – 168 б.
10. Якупова, С. Кар юлы: шигырьләр / С. Якупова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 223 б.

*Нәҗибә ЗАРИПОВА,*
*Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының*
*3 нче санлы китапханә мөдире*

## ДЕТЕКТИВ ЖАНР
## (Шамил Шәйдуллин иҗатына нигезләнеп)

Шәһәребездә озак еллар яшәп иҗат иткән язучы Шамил Шәйдуллинның исеме күпләргә таныш. Шамил Нәфигулла улы Шәйдуллин 1939 елның 13 мартында Яңа Чишмә районы Сөлчәбаш авылында дөньяга килә. Башлангыч һәм урта белем ала, кичке урта мәктәпне тәмамлый. Шуннан соң милиция һәм закон саклау оешмаларында хезмәт итә, комсомол юлламасы белән Төркестанның Ислотань шәһәре милициясенә оператив эшкә җибәрелә. 1974 елда, КамАЗ төзелеше башлангач, Шамил Шәйдуллин Татарстанга кайта, Чаллы шәһәрендә эчке эшләр бүлегендә җинаять эшләрен тикшерү җитәкчесе, Алабуга шәһәрендә милиция штаб башлыгы, Менделеевск шәһәрендә район милициясе башлыгы булып хезмәт итә.

Шамил Шәйдуллин исеме әдәбиятта 70 нче елларда күренә башлый. Милиция хезмәткәре буларак ул, үзе күргән-кичергәннәрне яза. Үзе эшләгәндә, җинаятьчеләр белән көрәшкәндә аның гаделлекне гәүдәләндергән «Көтелмәгән очрашулар» исемле юрист язмалары (1988), «Алтын үрмәкүч тозагында», «Кара эзләр кая илтә?», «Сөембикә шәмдәле эзеннән» исемле романы (1992), «Кляп из ваучеров», «Упкын өстендә», «Вөҗдан газабы» һ.б. әсәрләре укучылар күңеленә тиз арада барып ирешә. Ике телдә язучы әдип әдәбиятны детектив жанрда язылган әсәрләр белән баета.

Әдәбиятта һәркем тарафыннан да укылган, яшь аермасы белән хисаплашмыйча үзен яраттырган бер өлкәсе бар, ул – детектив жанрда иҗат ителгән әдәби әсәрләр. «Детектив» – инглиз сүзе, «шымчы» мәгънәсен белдерә. Детектив жанрда язылган әсәрләр нигезендә нинди дә булса җинаятьне ачуга ирешкән зирәк шымчының гамәлләрен тасвирлауга корылган кискен сюжет ята.

Татар әдәбиятында детектив сюжет алымнарына беренчеләрдән булып Закир Бигиев мөрәҗәгать итә. Аның 1887 елларда дөнья күргән «Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә», «Зур гөнаһлар» исемле романнарын күрсәтергә була. Әдәбиятыбыз классигы Г.Ибраһимовның 1928 елда «Тирән тамырлар» исемле романы басыла. Детективның мөстәкыйль жанр буларак чыгыш ясый



башлавы 1960 елларга туры килә. Соңгы елларда бу жанрга А.Расих, Р.Ишморатова, Т.Әйди, М.Насыйбуллин, З.Фәтхетдинов, М.Маликова, Т.Галиуллин мөрәҗәгать итәләр.

Шамил абый Шәйдуллин безнең Чаллы төбәге язучыларыннан иң беренче детектив жанрга канат куйган язучы. Ул бу жанрга килгәнче, нәкъ менә милиция сафларында эшләп, аның бөтен ягын эчтән белеп язучылар юк иде дияргә була. Шамил абый үзенең бөтен гомерен менә шушы детектив жанрга, кешеләргә әхлакый, эстетик тәрбия бирүгә багышлаган мәгърифәтче кеше иде. Ул СПИД, наркотиклар афәтен әсәрләрендә чагылдырып, җәмгыятебезне сафландыруга омтылган романтик күңелле ихлас язучы иде. Ул шулар арасында яшәде, шул җинаятьчеләр белән көрәште, аларның психологиясен өйрәнде.

*«... Билгесез ир кеше мәете табылган яланга килеп җиткәндә, кояш күтәрелеп кенә килә иде әле. Биек агачларның җиңелчә чайкалып торган башлары ниндидер серне саклау турында сүз куешкандай, алтын нурларда коенып утыралар. Ләкин бөтен бу күркәмлекне табылган мәетнең имәннеч күренеше томалый. Мәет күкрәгенә кадәр кадәр чуерташ өеменә күмелгән. Юл читендә яндырылган чит ил машинасы тора. Үлгән кешенең авызында келәп-һәм гади генә түгел, аны төрле кыйммәттәге иске акчалардан укмаштырып ясаганнар. Арада күбрәге иллелекләр, берничә Америка доллары һәм хәтта ике КамАЗ акциясе бар».*

*«Иблис «оҗмахы» повестеннән өзек*

Автор үзенең әсәрләрендә җинаятьченең кыяфәтен, холык-фигылен, кылган җинаятен тасвирлап кына калмый, әлеге адәм баласын җинаять юлына илткән сәяси, икътисади, социаль-иҗтимагый шартларны, хәвефле хәлләрне дә яктыртып, сурәтләп дәлилләргә тырыша. Чөнки бер генә адәм баласы да анасыннан җинаятьче булып тумый, нәселдән килә торган чир дә, йола да түгел ул җинаять. Аны фаш итүләре никадәр кырыс, дәлилләре никадәр хак булмасын, Шамил Шәйдуллин әсәрләрендә вөҗдан, гаделлек, шәфкатьлелек, миһербанлык, намус төшенчәләре башыннан ахырына тикле кызыл җеп булып сузыла. Аның эзләнү рәвешендә, документаль базага нигезләнеп язылган әсәрләре зур әһәмияткә ия.

Шамил Шәйдуллин белән булган бер әңгәмәсеннән соң журналист Зөбәер Мифтахов болай яза: «... язучылар күп булып та, детектив язучыларның әз булуы гаҗәп түгел. Башкасы гаҗәп – андый сирәк талант ияләренең берсе үзебезнең Чаллыда яши,

татарча язучы татар кешесе икән. Һәм француз яки инглиз детективчылары кебек ике кулына бер каләм тотып курортта да утырмый, ә көн саен үзе җинаятьчеләр белән шөгыльләнеп, шулардан бушаган арада гына язучы «гади» милиция майоры икән».

Китап укучылар белән үткәрелгән очрашу-чараларга бик теләп килде Шамил ага, аның укучыларына әйтер сүзләре дә күп була иде. Җиңел чандыр гәүдәле, җитез хәрәкәтле, көлсу-бөдрә чәчле язучыны күпләр бүген дә хәтерлидер.

Шундый очрашуның берсендә шәһәребезнең ЗЯБ бистәсендә урнашкан 21 нче мәктәбе югары сыйныф укучылары белән Шамил Шәйдуллинның «Сары әҗәл» повесте буенча китап укучылар конференциясе уздырдык. Әсәр – җирле вакыйгаларга корылып язылган җан өшеткеч замана афәте – наркомания турында. Укучылар әлеге әсәр турында фикер алыштылар, образларны ачып бирделәр, повестьтан "наркотиклар колы» дигән өзек күрсәттеләр. Әдәби кичә соңында балалар Шамил абыйларына күп сораулар бирделәр, иҗат планнары белән кызыксындылар. Язучыны наркоманиянең азуы, алар арасында фаҗигале үлемнәр саны артуы, эчкечелек, фәхишәлек борчыды. Аның өмете – асылыбызга кайту, татар милләтенең милли аңын, горурлыгын уяту иде. Мондый истәлекле очрашу-кичәләр китапханә, тулай торак, мәктәпләрдә күп уздырылды. Үзенең милиция өлкәсендәге эшчәнлеге, язучылык иҗатына тартылуы, шигърияте турында дулкынланып сөйләде язучы. Язганнарын дога итеп укып йөрүче, саф күңелле Шамил абыйның иҗаты матур булды. Зур күләмле әсәрләрендә, шигырьләрендә булсын, ул намус, гаделлек, миһербанлылыкка тугры калды.

Язучы, шагыйрь, милиция майоры, хезмәт ветераны Шамил Шәйдуллин 1995 елдан Рәсәй һәм 1996 елдан Татарстан язучылары берлеге әгъзасы иде.

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Дунай, Ф. Шинель кесәсендә – шигърият: Язучы Шамил Шәйдуллинга 65 яшь / Ф. Дунай // Мәйдан. – 2004. – №5. – Б. 22-26.
2. Хәмидуллина, Р. Г. Китапханә сәхнәсе: Китапханәчеләргә, балалар бакчалары тәрбиячеләренә, сыйныф җитәкчеләренә ярдәмлек. 1 нче чыгарылыш / Роза Хәмидуллина. – Казан: Редакционно-издательский центр, 2012. – Б. 94-100.
3. Шамил Шәйдуллин: биобиблиографик күрсәткеч / Чаллы шәһәре, М. Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсе. Әдәбият тарихы музее. Төзүч.: Р. Г. Хәмидуллина, Ф. Х. Хамматова. – Алабуга: «Андерсен», 2011. – 188 бит.
4. Шәйдуллин, Ш. Вөҗдан ярасы: шигырьләр / Ш. Шәйдуллин. – Чаллы: "КАМАЗ" нәшр., 1995. – 43 бит.
5. Шәйдуллин, Ш. Иблис «оҗмахы»: Детектив повесть / Ш. Шәйдуллин. – "Ак бит" нәшр., 2002. – Б. 53-54.
6. Шәйдуллин, Ш. Көтелмәгән очрашулар: Юрист язмалары / Ш. Шәйдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 88 бит.
7. Шайдуллин, Ш. Кляп из ваучеров: Детективная повесть / Ш. Шайдуллин. – Набережные Челны: Газетно-книжное издательство «КАМАЗ», 1993. – 130 стр.





***Валентина ИБРАҺИМОВА,***
*Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының*
*13 нче санлы китапханә мөдире*


## ВАХИТ ИМАМОВ ИҖАТЫНДА ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ РУХИ МИРАСЫ – ТАРИХНЫҢ АЧЫЛМАГАН ЯҢА БИТЛӘРЕ

Язучы – прозаик, тарихи романнар авторы, Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның Атказанган мәдәният хезмәткәре, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, «Мәдәни Җомга» газетасы мөхәррире Вахит Шәйхенур улы Имамов тарих белән кызыксынучылар йөрәгенә юл тапкан күренекле каләм иясе.

Вахит Имамовның иҗат юнәлеше – тарих, тарихи чыганакларны өйрәнү, халкыбызның гыйбрәтле үткәненә, данлы да, бер үк вакытта фиҗигале дә язмышын ак кәгазь битләрендә, киләчәк буыннарга мирас итеп калдыру. Язучы бүгенге көндә егерме бер әсәр язган. Журналист буларак, матбугат битләрендә төрле темаларга язылган меңләгән мәкаләләре дөнья күргән.

Һәр әсәрендә, архивларда эзләнеп, бөртекләп җыйган тарихи темага яңа фикер, яңа мәгълүмәт, халык, кешеләр язмышы, бу язмышлар хакында тирәнтен уй-фикер йөртү.

1988 елда яшь прозаикның тугыз хикәясен һәм бер повестен эченә алган «Ир канаты» исемле мөстәкыйль китабы басылып чыга, өч елдан ике яңа повесте («Күке», «Нәзер») һәм унлап хикәясе тупланган «Нәзер» җыентыгы дөнья күрә. Бу әсәрләрендә авторның яшьлегенә туры килгән торгынлык чорының һәлакәтле күренешләре, нигездә авыл чынбарлыгын үзәккә алып, төрле язмыш сынауларына дучар ителгән кешеләрнең тормышчан образлары бирелгән.

«Нәзер» повесте һәм «Өмет» хикәясе буенча Татарстан телестудиясе, соңыннан кыска метражлы нәфис фильмнар төшереп, аларны телевизор экраннарыннан күрсәтә килә.

КамАЗ төзелеше белән бәйле вакыйгалар барышында, зур бер төбәкнең табигый мохите бозылуын, йөзьяшәр авылларның җир белән тигезләнүен күрсәткән «Могикан” (2001) повесте да, әдип иҗат колачының киңлеге турында сөйли.

Әдәби иҗатта В. Имамовка киң танылу китергән өлкә – тарихи әсәрләр. 1982-1994 еллар дәвамында ул, даими рәвештә төрле шәһәрләргә барып, архивларда сакланып яткан документлардан татар халкының үткән тарихын җентекләп өйрәнә, тарих чоңгылларына чумып, хәтер хәзинәләрен актара.

1993 елда «Яшерелгән тарих» исемле беренче документаль әсәрен яза. Татар халкының XVI – XVIII йөзләрдә алып барган милли-азатлык көрәшен һәм яуларын чагылдырган бу тарихи повестьның басма китабы бөтен Россия киңлекләренә таратыла. Әсәр рус телендә “Отечественная история татар» исеме астында басылып чыгып, инглиз, француз, немец, төрек, әзербайджан телләренә тәрҗемә ителә.

«Сәет Батыр» әсәре – олы шәхесләребезнең әдәби образларына мөрәҗәгать итү, халкыбызның фидаи уллары хакында киләчәк буыннарга язып калдыру. Архив документларын калкытып гаҗәеп чынбарлык ачыла: Пугачев кузгалышының төп көчен татарлар тәшкил иткән бит! Пугачев янәшәсендәге бригадир дәрәҗәсенә ирешкән Канкаев, Усаев, Кадырмөхәммәтовлар булган икән. Полковниклар да кырыклап, старшиналар йөз илледән арткан! Бу әсәрне укып, без шундый мәгълуматлар белән танышабыз.

«Тозлы яра» әсәрен язучы коллективлаштыру елларында корбан булган бабасы (әнисенең әтисе) Әмир Нәгыймовның якты истәлегенә багышлап иҗат иткән. Автор 1933 елгы коточкыч ачлыкны тетрәндергеч язмышлар аша укучыга җиткерә. Узган гасырның егерме-утызынчы елларында булып узган шаукымлы вакыйгаларның, крестьян хуҗалыкларын көчләп күмәкләштерү, төрле репрессив ысуллар белән халыкның җегәрле катлавын җинаятьчел бер эзлеклелек белән юк итү сәясәтенең нинди афәтләр китергәнлеген тарихи реаль кеше образларында калку итеп тасвирланган романда.

Ә «Татар яугирләре» [Татарлар Пугачев явында] дигән әсәр язучының бөтен бер тарихи эзләнүләренең чишмә башы. Әсәр халыкның азатлыкка, мөстәкыйльлеккә омтылышы, каһарманлыгы белән үрелеп бара.



Әдәби иҗат эшчәнлегенең тарихи юнәлешен дәвам итеп, В. Имамов халкыбызның язма хәзинә булып сакланган тарих кешеләнә чума, һәм Казанның 1000 еллыгына бүләк булып «Казан дастаны» әсәре дөнья күрә. Тәүге тарихи романда Казан каласына нигез салынган вакыйгалар зур осталык белән сурәтләнгән.

Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган «Утлы дала» романы – җәмгыятьтә дә, фәнни дөньяда да вакыйга буларак кабул ителә. Монда сурәтләнгән тарихи вакыйгаларның географиясе гаять киң – Монголия далаларыннан башлап, Хәрәзем дәүләтен, Болгар илен һәм рус кенәзлекләрен кертеп, Карпат тауларына кадәр.

Бу яңа романда Вахит Имамов халкыбыз тарихының яңа катламнарына үтеп керә. Исемнәре бөтен дөньяга билгеле Чыңгызхан, Колгали, Юрий Долгорукий, Андрей Боголюбский образлары аша рус һәм Болгар дәүләтләре, татар, Монгол һәм кыпчак халыкларының XII – XIII гасырдагы тормышы сәхифәләрен ачып сала.

Утлы дала кайный, эре һәм вак кабиләләр генә йөзләгән. Алар әле генә кан коеша, әле генә дус яши, әле генә килен – кәләш алмаша. Бу – урта гасырлар җәмгыятенең яшәү рәвеше. Русларның XII гасырда башланган феодаль таркаулык чоры. Ә галимнәр Болгар илен 12 нче гасырда иктисади яктан көчле, бердәм, үзәкләштерелгән дәүләт рәвешендә күз алдына китерәләр. Яңа кала – крепостьлар салына, сәүдә чәчәк ата. Биләр амбарларында археологлар әле бүген дә капчык – капчык бодай, арпа, борчак бөртекләре җыеп алалар.

Яңа әсәр буларак, роман күңелләрдә кызыксыну уятмый калмый! Язучыдан ныклы ихтыяр көче, сабырлык, тынгысыз һәм йокысыз төннәр таләп иткәндер бу романны язу.

Өченче меңъеллыкка аяк бассак та, халыклар бердәмлеге иң актуаль темаларның берсе булып кала.

Романда әдәби геройлар булып дөнья тарихында калырлык дәүләтләр белән идарә итүче Болгар дәүләте ханнары, рус дәүләте кенәзләре тора. Монда гыйбрәт алырлык вакыйгалар башыннан ахырына кадәр бер-берсе белән үрелеп бара. Ул заманда дан тоткан дәүләт башлыклары, гаиләләр исемнәре белән китерелгән. Тарихи фактларга бай сюжетлар хәтердә тирән эз калдыра.

Борынгы гасырлардан ук рус, болгар, кыпчак һ.б. халыклар бер-берсе белән бәйләнгән. «Утлы дала» романын укыгач кына, Юрий кенәзнең хатыны кыпчак икәнен, ягъни безнең борынгы бабаларыбыз нәселе, ә улы Андрей кенәзнең хатыны болгар кызы – Байгөл, Мәскәү ярында яшәп ятучы Кучкәй батыр кызы икәнлеген беләсең. Андрей кенәзгә Боголюбский исеме ничек бирелүе хакында да әдәби итеп, кызыклы язылган.

Андрей кенәзнең Болгарга сәяхәтен язучы бик матур итеп тасвирлый: Болгар җиренә аяк басуга Андрей кенәзне илнең мул иген кырлары, төзек шәһәр-авыллары, һөнәр мастерскойлары, мал тулы базарлары, сәүдәгәрләре таң калдыра. Авылларның гүзәллеге, чисталыгы, йортларның ныклыгы, халкының кунакчыллыгы да рус кешесе өчен яңалык була. Болгар җирендә кунакта булганда, урамнарда кораллы бер генә кеше дә очратмый ул, хан булуның берсеннән берсенә сугышсыз күчүе, илне аерым гаскәрләр саклавы да аны гаҗәпләндерә. Болгарда кунакта булып кайтканнан соң, Андрей тормышын тамырыннан ук үзгәртә. Ташлардан шәһәр төзетә, ныгыта. Аның тагын нәрсәләр эшләткәне, нинди өлкәләрдә үзгәрешләр керткәне, Байгөлнең һәм аның улларының киләчәк язмышы – романда барысы да язылган. Алып укыйсы гына кала.

Искиткеч вакыйгалар, бер китапта да язылмаган яңа мәгълүмат-фактлар! Тарих чылбырын үреп бара язучы. «Утлы дала» ның болгарларга багышланган бүлекләрендә күңелгә якын һәм гаҗәеп дәрәҗәдә оста сурәтләнгән Кол Гали образы бирелгән. Аның турында без бик аз беләбез. «Кыйссаи Йосыф» та китерелгән кыска белешмә, халык телендә сакланып калган риваятьләр. Таҗетдин Ялчыгөлнең язган риваятендә сөйләнгәнчә, Кол Гали болгар иленең асыл шаһзадәләреннән берсе саналган Мирхаҗи бәкнең улы була. Батыйның Биләргә һөҗүме вакытында бөек Кол Гали вафат була. Шул легендага таянып, язучы Кол Галинең гаҗәеп тормышчан, тулы образын тудырган. Безнең күз алдына бөек шагыйрьнең туганнан алып, каһарманнарча үлеменә кадәр бөтен тормышы күз алдына килеп баса.

Чыңгызханның атасы кем? Безнең татар баһадиры – Ясүгәй, әнисе – кыпчак кызы Айлыбикә. Әсәрнең монголлар тормышын, яшь Тимучинның гайрәтле Чыңгызханга әверелүе һәм дистәләгән дәүләтләрне басып алу тарихына караган бүлекләр маҗаралы вакыйгаларга бай, бу вакыйгалар борынгы документларда чагылыш тапкан. Романда халык легендаларын ничек оста файдалана автор.

«Утлы дала» романы, һичшиксез, көчле тәэсир калдыра. Башкарылган хезмәт олы, асыл, ул хезмәттә никадәр чынбарлык, бөртекләп җыелган мәгълүмат сыйган.

Вахит Имамовның әдәби иҗаты турында матбугатта басылган фикерләр шактый. Бер-икесенә тукталып үтәсе килә:

Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов: «...Безнең әдәбиятка соңгы елларда яңа бер талантлы, табигатьне, кешеләр зарын, тормышның катлаулыгын күңел күзе белән күрә ала торган автор килде», дип бәяли.



Әдәбият галиме, тәнкыйтьче Рифат Сверигин: «...Вахит Имамов яңа гасыр бусагасыннан иң кыю һәм актив әдипләребез рәтендә атлап керде. Ул XI – XII гасырларда булып узган вакыйгаларны, шул чордагы болгар, магул, рус хөкемдарларының сарай һәм гаилә интригаларының гаять катлаулы һәм мәкерле чәбәләнешләрен киң географик һәм тарихи үлчәмнәрдә әдәбиләштереп чагылдырган күләмле әсәренең беренче китабын тәмамлады. Халыклар тарихы белән якыннанрак кызыксынучылар «Утлы дала» дип исемләнгән бу романнан искиткеч күп һәм бай мәгълүмат алырлар. Элек бозып күрсәтелгән яисә махсус рәвештә караңгылыкта тотылган тарихыбызны булганынча яктырту мөнәсәбәтеннән генә бәяләсәң дә, Вахит Имамов башкарган титаник хезмәтне танымыйча, билгеләмичә үтү зур хаксызлык булыр иде», – дип, үз бәясен бирә.

Гаяз Исхакый премиясе лауреаты, язучы Факил Сафин: «...Вахит Имамов әдәби мәйданда киң колачлы әсәрләр язу остасы буларак танылды. Әмма без укып күнеккән гади тормыш вакыйгаларыннан укмаштырган һәм әдәби чаралар ярдәмендә сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән романнар түгел, бәлки гаять дәрәҗәдә зиһен, акыл, тырышлык һәм үҗәтлек, физик көч таләп итүче өлкәне – тарихи әсәрләр язуны үз итте ул. Шундый әсәрләрнең иң күренеклесе, әлбәттә, «Утлы дала» романы булды», – дип бәяли.

«Алышларда бирешмәслек, ярый әле илдә ирләр бар!», – дип әйтәсе килә, Вахит Имамов иҗаты белән танышканнан соң.

**ӘДӘБИЯТ:**


1. Ахунов, Г. Киләчәк – һәркемнең үз кулында / Г. Ахунов // Казан утлары. – 1987. – №5. – 102 б.
2. Вәлиев, М. Тукай яшен узганда / М. Вәлиев // Казан утлары. – 1989. – №6. – 156-166 б.
3. «Аргамак» бездә кунакта: В. Имамов белән әңгәмә // Шәһри Казан. – 1991. – 16 окт.
4. Галиев, М. Ак юл сиңа, Вахит батыр! / М. Галиев // Шәһри Казан. – 1994. – 28 июнь.
5. Галиев, М. Өч баһадир / М. Галиев // Мәйдан. – 2002. – №6.
6. Фәрит Габдрәхим. Татар тарихына сәяхәт / Ф. Габдрәхим // Кызыл Таң. – 1994. – 5 июль.
7. Әнәс Хәсән-Кырымлы. Күңелләрне тетрәндергеч китап («Сәет батыр» романы турында) / Ә. Хәсән-Кырымлы // Шәһри Казан. – 1994. – 30 авг.
8. Абдуллин, З. Утлы дала җилләре («Утлы дала» романы турында) / З. Абдуллин // Шәһри Казан. – 2000. – 4 авг.
9. Ахунов, Г. Саллы прозаик килә / Г. Ахунов // Мәйдан. – 2002. – №6.

*Алмазия ШӘИХОВА,*
*Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының*
*12 нче санлы китапханәнең бүлек мөдире*

## МОҢ ИЯСЕ
## (Әлфия Ситдыйкова иҗатына багышлана)

Әлфия Мирзанур кызы Ситдыйкова (Хаҗиәхмәтова) 1957 елның 14 августында Татарстан Республикасының Актаныш районы Күҗәкә авылында дөньяга килә. Туган авылында сигезьеллык, Пучы авылында урта мәктәпне тәмамлый. 1975 елда данлыклы КамАЗ төзелешенә эшкә килеп, егерме елга якын гомерен заводта эшли. 2000 елда аны «Чаллы-ТВ» телерадиокомпаниясенә эшкә чакыралар. Музыкаль редактор, корреспондент, өлкән корреспондент булып эшләү дәверендә, журналистлык һөнәрен тирәнтен үзләштереп, әдәбият-сәнгать кешеләре турында йөзгә якын гамьле әңгәмә кора. «Әдәби учак», «Илһам нуры» дип исемләнгән тапшырулар эшләп «Күңел» радиосы аша халыкка җиткерә. 2003-2008 нче елларда читтән торып Чаллы педагогия институтының филология факультетында белем ала.

Шагыйрә Әлфия Ситдыйкова турында Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь Рәдиф Гаташ: «...Шагыйрәнең шигырьләре күбесе үзен үстергән матур табигатьле, бик күп талантлы кешеләр бишеге – Актаныш белән бәйләнгән. Аның авыллары, елга-чишмәләре, урман-кырлары белән... Шул як кояшы, ае белән туган аның шигырьләре, аларда – гөлләрнең хуш исе, әрем тәме катнаш моң һәм бабайлар васыять иткән туган туфракка тугрылык, нигезне изге санау кебек әдәп-әхлак иманы.

...Мәңгелек Моң... Актаныш ягында канатланган шигъри күңел тәрбиясе! Бөтен авыл атамаларын да җыр итү теләге дә сизелеп куя... Әмма тулаем күңел эзләнүләрендә ул әнә шул ихлас җыр-моң белән еш кавыша, үзе дә сизмәстән, канатлана, оча, яңача яңгырый ала. Димәк, шагыйрәдә җырга якынлык табигый рәвеш тә бар, ул көй сорап яши, дәвам итә. Шул юлга тугры булуын теләргә генә кала» –дип яза.

Балачактан ук әдәбиятка гашыйк Әлфия Ситдыйкова, Чаллы шәһәрендә 1963 елдан эшләп килгән «Ләйсән» әдәбият иҗат берләшмәсендә каләмен чыныктыра. 1977 елда аның матбугат битләрендә беренче шигырьләре күренә башлый. 1979 елда дүрт шигыре «Яшьлегем Чаллы» күмәк җыентыгында басылып чыга.



Әлфия Ситдыйкова, гаиләдә балалар үстергән вакытта, иҗаттан бераз читләшеп торса да, 2000 еллар башында кабат каләмен кулга ала. 2003 елда Чаллыда ЖЧЖ «Газета-китап нәшрияты»нда беренче мөстәкыйль шигырьләр китабы басылып чыкканнан соң, бер-бер артлы шигырь китапларын укучыга тәкъдим итә башлый. Башкаларның иҗатына карата да үз фикерләрен белдерүдә каләм көчен сыный. Тирән эчтәлекле мәкаләләре, нәсер-парчалары, күләмле генә поэмалары да төрле басмаларда урын ала.

